# БАЛАЛАРГА ҮГЕТ-НӘСЫЙХӘТ

# Балаларга үгет-нәсыйхәт



Яңартылган
икенче басма

КАЗАН
«ДОМ ПЕЧАТИ» НӘШРИЯТЫ
2002

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫНЫҢ
ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ

**Китапны әзерләделәр:**

Нурислам Ибраһимов, Әдип Мадияров.
Камил Бикчәнтәев, Азат Низамиев.

**Бәяләмә бирүчеләр**

Хуҗиәхмәтов Ә.Н. – педагогика фәннәре докторы, КДПУ профессоры, академик;
Маһиярова З.Г. – педагогика фәннәре кандидаты, КДТУ доценты.

Китап Ризаэддин бине Фәхреддин, Госман Исхакый һәм Габдрахман Кая әсәрләренә нигезләнеп, балаларга бик кирәкле үгет-нәсыйхәтләрне үз эченә кертеп эшләнде. Әлеге әсбап мәктәп, мәдрәсәләргә дәреслек буларак тәкъдим ителә.

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

*Бисмилләhи-р-рахмәни-р-рахим*

# ТӘРБИЯЛЕ БАЛА

❁Ата-ана өчен тәрбияле баладан да зур байлык булмас. Тәрбияле бала дөньяда җанга шатлык китерсә, ахирәттә йөзгә аклык китерер.

❁Тәрбияле баланы hәркем яратыр, әмма тәрбиясез баланы беркем дә яратмас, бәлки хурларлар вә кимсетерләр.

❁Тәрбияле бала булу нинди зур хәзинә булса да, аңа ирешү бик җиңел. Атам, анам шатлансын, кешеләр дә миңа рәхмәт әйтеп, мине яратсыннар дигән hәрбер баланың тәрбияле бала булырга көче җитә.

❁Тәрбияле бала әллә кайдан күренеп тора, чөнки аның сөйләгән сүзләре, эшләгән эшләре аның тәрбияле бала икәнлеген күрсәтеп торалар.

❁Тәрбияле балалар ни рәвештә булырга тиешләр соң? Моңа җавапны кулыгыздагы бу китаптан укып белерсез hәм үзегезне тәрбияле балаларның күркәм сыйфатлары белән зиннәтләрсез.

❁Тәрбияле бала иң беренче шушы рәвештә булыр: ул иртән йокысыннан олы кешеләр белән бергә торыр. Алардан элек тә тормас, шулай ук соңга да калмас. Кешеләр торып беткәннән соң йоклап яткан балага ялкау, йокы чүлмәге диярләр. Йокысыннан торгач та ул хаҗәтханәгә барып килер hәм салкынчарак су белән тәhарәт алыр. Тәрбияле баланың үзенә аерым бит, кул сөртә торган сөлгесе,

шулай ук тарагы булыр. Үзенең сөлгесенә генә сөртенер һәм үз тарагы белән генә чәчен тарар.

❁Тәрбияле бала үзенә әзерләнгән чәйне әдәпле генә утырып эчәр, икмәкне дә кадерләп кенә ашар. Аяк өсте ашап йөргән кешенең икмәк валчыклары җиргә төшәр, һәм алар аяк белән таптальр да гөнаһ булыр. Шуның өчен тәрбияле бала һичбер вакытта аяк өстендә ашап йөрмәс. Тәрбияле бала көндезге киемнәрен үзе урыныннан алып кияр, пычракларын үзе чистартыр. Әгәр үзенең генә көче җитмәслек эшләре булса, олыларга әйтер.

❁Чәйдән соң вакыт булса, мәктәпкә барганчы бер читкә утырып, үзенең дәресләрен карар. Сабагын аңлап, күңеленә салыр.

❁Тәрбияле бала мәктәпкә барырга чыккач та әдәп, инсаф белән йөрер. Каршы очраган кешеләргә сәлам бирер.

❁Тәрбиясез балалар кебек эт, мәчеләргә таш яки башка нәрсәләр атмас. Җыелып торган сулар эченнән чәчрәтеп йөрмәс, мәктәп балалары белән яман сүзләр әйтешеп, сүгенеп йөрмәс.

❁Мәктәпкә кергәннән соң аяк киемен билгеле урынына куяр һәм үз эше белән мәшгуль булыр.

❁Мәктәптә балалар өчен ял итәргә һәм уйнарга да бераз вакыт була. Шул вакытта балалар укытучыларның рөхсәте белән уйнарлар, ял итәрләр. Ләкин тәрбияле балалар тиешсез нәрсәләр белән уйнамаслар. Уйнаган вакытларында иптәшләрен рәнҗетмәсләр.

❁Тәрбияле бала ручка-каләм, төрле буяулар кебек буяла торган нәрсәләр белән уйнамас. Шулай ук шырпы, пычак, без, кадак, урак, чалгы, пәке кебек нәрсәләр белән, пыяла һәм таш савыт

кисәкләре, тузан-туфрак һәм балчык белән һичкайчан уйнамас. Бакчаларда булган агачларны сындырмас, гөлләрне йолкымас, чәчәкләрне өзеп ташламас.

❁Тәрбияле бала иптәшләренең сумкаларын, китап, дәфтәрләрен актармас, ертмас. Аларның да һәм үзенең әйберләрен дә пычратмас, югалтмас.

❁Балаларның барлык эшләрен укытучылары һәрвакыт белеп, күзәтеп торалар. Шуның өчен тәрбияле бала үзенең иптәшләренең гаепләрен белсә дә, укытучыларга әйтмәс. Бәлки һәрвакытта үз эше белән генә шөгыльләнер, башкалар эшенә катышмас.

❁Мәктәптән кайтканда да әдәп белән генә кайтыр. Кайтып кергәч тә ата-анасы һәм башка туганнары белән исәнләшер, дәресләрен тыңлатыр, ата-анасын куандырыр һәм аларның хәер-дога һәм рәхмәтләрен алыр.

❁Тәрбияле баланың китап, дәфтәр һәм каләм куя торган билгеле урыны булыр, ул аларны дәрестән кайткач шунда куяр һәм кирәк булганда шуннан алыр. «Китапларым, каләмнәрем кайда?» – дип башкалардан кычкырып сорап йөрмәс.

❁Дәресләрен әзерләп бетергәннән соң балаларның буш вакытлары да була. Шул вакытта, әгәр йорт эчендә хезмәт булса, зурлар кушканны эшләрләр. Әгәр эш булмаса бакчаларда, ишек алларында иптәшләре яки дуслары белән уйнарлар.

❁Тәрбияле баланың яхшы холкы зурлар һәм кечкенәләр белән аралашуында күренә. Мәсәлән, ул үзеннән кечкенәләргә карата миһербанлы була, аларга һәрвакыт туганым, кардәшем дип кенә эндәшә, шулай ук үзеннән зурларга, ата-анасына, укытучы һәм остазларына, үзенең тәрбиячеләренә,

һәм үзеннән олы яшьтәгеләрнең барчасына да һәрвакыт хөрмәт күрсәтә, аларның хәтерләрен калдырмаска тырыша.

❁Тәрбияле бала, ата-анасының күңелләрен калдырырлык һичбер эшне эшләмәс, ата-анасы «ул эшне мин яратмыйм» дисә, тәрбияле бала ул эшне эшләү түгел күңеленә дә китермәс. Йомыш булган чагында, торган җиреннән кычкырмый гына яннарына барып ачык кына итеп сорар. Аларның кушкан йомышларын теләп башкарыр. Әгәр үзеннән берәр нәрсә сорасалар, ачык йөз белән җавап бирер. Йорт эчендә кунак булса, ата-анасы кушканча кунакка хезмәт һәм хөрмәт күрсәтер. Йорт эчендә кунак балалары булса, алар белән бергә булыр, алар белән шауламый, кычкырышмый, бәлки бертуганнар кебек уйнар.

❁Баланың тәрбияле икәнлеге ашарга утырганда бик беленә. Ул зурлар күрсәткән урынга гына утырыр, терсәкләре белән таянмас, ашарга бирелгәнен сабырлык белән көтәр. Нәрсә бүлеп бирсәләр шуны ашар, кирәк булса яхшы гына итеп сорар, кирәк булмаса комсызланып янә салдырмас. Аз-аз гына кабып, яхшы чәйнәп ашар. Олыларның сүзләренә үзлегеннән катышмас.

❁Тәрбияле бала ашаганда һич ашыкмас. Икмәк валчыкларын коймас. Ашны ашъяулыгына да, үзенең киемнәренә дә түкмәс.

❁Әгәр кешеләр белән бер табактан ашарга туры килсә, ул вакытта кулын үз алдына гына сузар, кеше алдына сузылмас, акрын гына ашар. Мондый балаларны һәркем яратыр һәм мактап сөйләр.

❁Тәрбияле бала аш яныннан торгач майлы кулы белән бернәрсә дә тотмас, кулын киемнәренә дә сөртмәс. Бәлки яхшылап сабын белән юар,

авызын чайкар. Олылар бар вакытта аларның юынып бетергәннәрен көтәр, үзенә чират җиткәч юар.

❁Аш ашагач тәрбияле бала зурлар янында утырмас. Бәлки бераз үзенең дәресләрен карап утырыр.

❁Ятарга рөхсәт бирелгәч тәрбияле бала олыларга хәерле төн теләп, йокларга әзерләнер. Хаҗәтханәгә барып килер. Көндезге киемнәрен салып, барысын да бик яхшы итеп төрер дә билгеле урынга куяр. Әгәр киемнәре арасында юеш һәм пычранганнары булса, аларын башка нәрсәләр арасына ташламас. Чөнки юеш һәм пычрак киемнәр бергә куелса, башкалары да кадерсезләнер. Шуның өчен юешләрен кибәр өчен асып куяр, ә пычракларын селкеп яки юып чистартыр. Соңыннан урынына барып ятар.

❁Тәрбияле бала ялгышлык белән тиешсез бер эш кылган булса, аның ярамаганлыгын кешеләрнең күз карашларыннан ук белеп алыр. Әгәр берәрсе үзенә нәсыйхәт итсә, аңар һич тә каршы әйтмәс, бәлки нәсыйхәт итүчегә: «Бу эшем тиешсез икәнлеген үзем дә аңладым, моннан соң икенче мәртәбә эшләмәм, рәхмәт сезгә! Сездән Аллаһ разый булсын!» – дияр. Тәрбиясез бала исә, үзенең хатасын аңламас, кимчелекләрен төзәтү түгел, хәтта үзенә нәсыйхәт бирүчегә каршы яман сүзләр белән җавап бирер.

❁Тәрбия, әдәп кебек кешеләргә сөекле күренгән нәрсә дөньяда юктыр. Шулай ук тәрбиясезлек, әдәпсезлек кадәр дошман күренгән нәрсә дә юктыр. Тәрбияле бала никадәр ямсез булса да, тәрбияле булганга күрә аны һәркем яратыр һәм хөрмәт итәр. Әмма тәрбиясез бала никадәр матур булса да, аны беркем дә яратмас, ул үзенең киеме

яки матурлыгы белән генә кешеләрнең игътибарын яулый алмас. Тәрбияле баланың үскән саен игътибары һәм хөрмәте арта гына барыр, ә тәрбиясез бала никадәр зур үссә дә, кадер-хөрмәте булмас, бәхетсезлеге көннән-көн арта гына барыр.

❁Бу урынга кадәр язылганнар, ир һәм кыз балаларның барысы өчен дә иде. Әмма кыз балаларның үзләренә генә аерым әдәпләре дә бар. Хәзер шуларга күчәбез:

❁Тәрбияле һәм әдәпле булу ир балалар өчен никадәр тиеш булса, кыз балалар өчен бигрәк тә тиеш. Чөнки кайбер кимчелекләр ир балаларда булганда бик зур күренмәсә дә, кыз балаларда бик зур гаепкә саналыр. Мәсәлән, кием-салым керле һәм ертык булу, ир балалар өчен дә гаеп эш булса да, кыз балалар өчен бигрәк тә гаеп эш булыр. Шуның өчен пакьлек, чисталык кызларга бигрәк тә тиеш нәрсә. Үзенең өс-башын яхшы карамаган кыз баланы һәркем тәрбиясез дияр.

❁Уен уйнау турысында да кыз балаларның ир балалардан аермалары бик зур. Мәсәлән, туп уеннары ир балалар өчен яхшы булса да, кыз балалар өчен бик яхшы түгел.

❁Кыз балаларның үзләренә хас булган уеннары: курчак, йорт, бакчалар ясап уйнау, шунда ук аш-су хәзерләү кебек уеннардыр. Аналар үзләренең кызларына энә, җеп һәм ситса кисәкләре бирерләр дә, кызлар үзләренең курчакларына күлмәкләр, калфаклар тегеп кидерерләр.

❁Тәрбияле малайлар оятсыз, әдәпсез сүзләрне сөйләмәсләр; әмма кыз балалар андый сүзләрне бигрәк тә сөйләмәсләр. Үзләре сөйләү түгел, тәрбиясез балалардан төрле яман сүз ишетсәләр дә, оялырлар һәм ишетмәс өчен бер читкә китәрләр.

❁Кайвакытта кыз балалар үзләренең аналарына ияреп кунакка, мәҗлесләргә баралар. Кыз балаларның тәрбиялесе һәм тәрбиясезе шунда беленә. Тәрбияле кызларның аналары балалары өчен шатланып торырлар, әмма тәрбиясез кызлар башкалар алдында аналарының йөзләрен кызартырлар.

❁Тәрбияле кызлар мәҗлесләрдә аналарыннан күмәч, май, ит, бал, җимеш, төш һәм башка нәрсәләрне һич сорап йөдәтмәсләр, чөнки болай сорау гаеп эштер. Әгәр аналары үзләре бирсә, ул вакытта рәхмәт әйтеп алырлар. Майлы нәрсәләр булса, үз киемнәренә дә, кеше киемнәренә дә сөртмәсләр, бәлки су, сабын белән юарлар.

❁Ир балалар белән уйнау, сүз әйтешү, йөгерешеп, куышып йөрү кыз балалар өчен килешми. Тәрбияле кызлар бу эштән бик сакланырлар.

❁Тәрбияле балалар яхшы белән яманны аера белү хакында бик игътибарлы булырлар, яхшы холык һәм яхшы эшләрне белеп аны үзләренә гадәт итәрләр, ә яман холык белән яман эштән ерак булырлар. Чөнки бүген сигез-ун яшендә булган бала җиде-сигез елдан соң зур кеше була. Бала чагында алган тәрбия чәче агарганчы аның үзе белән бергә була. Бала чагында алынмаган тәрбияне соңыннан бөтен дөнья халкы да өйрәтә алмас.

❁Газиз балалар! Әгәр бу нәсыйхәтләрне кабул итсәгез файдасы үзегезгә булыр. Кабул итмәсәгез, зарары да үзегезгә булыр. Яхшы нәсыйхәтләрне кабул итмәгән балалар соңыннан үкенерләр. Әмма эш үткәч үкенүдә файда булмас.

❁Әгәр әдәп, әхлак орлыкларын бүген ихлас мәхәббәт белән чәчсәгез, киләчәктә файдалы җимешләрен үзегез үк җыеп алырсыз. Халкыбыз: «Ни чәчсәң шуны урырсың», – дип бик дөрес әйтә.

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

***Бисмилләәhи-р-рахмәәни-р-рахиим***

# АТА - АНА

❁ И, газиз балалар! Ата-аналарыгыз сезгә иң авыр һәм мәшәкатьле хезмәтләрне кылдылар һәм алар сезгә хезмәт итүдә һәмишә дәвам итәләр, һәрвакыт сезнең өчен тырышалар. Аллаhы Тәгаләгә ялварып сезнең өчен догалар кылалар. Инде сез дә аларның бу яхшылыкларын һәм бу хезмәтләрен камил кылып кайтарыгыз, көчегездән килгәнчә һәмишә аларга чын күңелдән хезмәт итегез һәм хөрмәт күрсәтегез! Аллаhы Тәгалә дә ата-анага яхшылык кылырга кушкан. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм дә: *«Ата-аналарын риза кылучы балалардан Аллаhы Тәгалә дә риза булыр»,* – дигән.

❁ Ата-аналарыгыз киләчәк көндә сезнең хөрмәтле һәм файдалы булуыгызны өмет итеп, Аллаhы Тәгаләдән ялварып сорыйлар. Инде сез дә мондый игелекләргә каршы явызлык кылучылар булмагыз, аларның үгет-нәсыйхәтләрен алардан куркып һәм өркеп түгел, бәлки яратып кабул итегез. Чөнки алар күп тәҗрибә аркылы бу дөнья хәлен һәм аның серләрен сездән күбрәк беләләр.

❁ Сезгә иң якын кешеләр ата-аналарыгыз. Шуның өчен аларга һәрвакыт итагатьле булыгыз, эштә һәм сүздә аларга каршы килмәгез. Шул вакытта аларның да һәм үзегезнең дә күңелләрегез рәхәт табар, тормышыгыз гүзәл булыр.

❁ Ата-аналарыгыз алдында әдәпле булыгыз, аларның сүзләрен яхшы тотыгыз. Алар белән кычкырмый гына, әдәп белән ачык итеп сөйләшегез. Алар аяк өстендә торганда сез утырып тормагыз.

❁ Баһадирлык – адәм балаларындагы хөрмәтле бер сыйфат. Олылар мәҗлесендә утырып, алардан хикмәтле сүзләр ишетү акылны арттыра һәм гыйлемлекне күбәйтә. Шуның өчен йөрәксез балалар кебек ата-аналарыгыз белән утырудан курыкмагыз һәм белмәгән, аңламаган нәрсәләрегезне сораудан тартынмагыз.

❁ Әгәр йөргән вакытыгызда әти-әниегез очраса аларга һәм алар белән бергә булганнарга сәлам биреп, хезмәтләрен үтәргә әзер торыгыз! Әгәр утырып торган вакытыгызда килсәләр, ачык йөз белән урыныгыздан торып каршылагыз!

❁ Ата-аналарыгыз сезгә нәрсә бирсәләр дә үзләренең миһербанлыклары белән бирерләр. Шуның өчен нәрсә сорасагыз да әдәп белән сорагыз. Әгәр сораган нәрсәгезне бирмәсәләр, аларны борчымагыз. Сезгә нәрсә кирәк, нәрсә кирәк түгел икәнлеген һәм сезгә нинди эшләр туры килү-килмәвен алар сездән яхшырак беләләр.

❁ Атагызның иң якын дустыннан булса да, атагыз рөхсәтеннән башка нәрсә булса да сорау гаеп эш һәм гаилә хөрмәтен җибәрү була. Шуның өчен йомышларыгызны башкалардан түгел, ә атагыздан сорагыз.

❁ Бала чагында акча тотарга өйрәнмәгән балалар олы булгач та акча тота белмиләр һәм бөтен байлыкларын исраф итеп, дөнья рәхәтен күрмиләр. Шуның өчен сез ата-анагыз биргән акчаларны тота белергә өйрәнегез. «Бу акча аз» димәгез, чөнки әлегә сезнең кирәкләрегез дә аз.

❁ Кайбер балалар аталарының малларына ышанып, һичбер кәсеп юлына кермичә ялкаулыкка гадәтләнеп китәләр. Нәтиҗәдә беркөнне акчалары да бетә, тереклек итәр өчен кулда һөнәрләре дә булмый. Шуның өчен ата малына ышанып тормыйча, нинди зур бай баласы булсагыз да, һөнәр өйрәнегез.

❁ Дөньяда вакытта шатлыкларны һәм кайгыларны уртаклашыр өчен якын һәм ышанычлы кешеләр кирәк була. Балалар өчен әти-әниләреннән дә ышанычлырак кеше һич булмас. Алар баланың шатлыгы өчен үзеннән дә артыграк сөенәләр, ә кайгы-хәсрәтләрен җиңеләйтү өчен кулларыннан килгән чараларның бөтенесен эшләргә тырышалар. Шуның өчен серләрегезне аларга гына сөйләгез, серләрегезнең хәзинәләре һәрвакыт ата-аналарыгызның күңелләре булсын.

❁ Күзгә күренгән һәрбер нәрсәгә кызыгучы булмагыз. Аналарыгызның кунаклар өчен әзерләп куйган нәрсәләренә тимәгез. Рөхсәтсез әйбер алырга өйрәнгән балалар ахырда угры булалар.

❁ Тәнегезгә көч кергәч кулыгыздан килгән эшләрдә ата-аналарыгызга ярдәм итегез. Алар сезне яшь вакытыгызда тәрбияләп үстерделәр. Бер көнне сез дә әти, әни булырсыз, шунда сезне дә балаларыгыз хөрмәтләр. Рәсүлебез Мөхәммәд галәйһиссәләм дә: *«Ата-аналарыгызга игелек итегез, сезгә дә балаларыгыз игелек итәр»,* – дигән.

❁ Ата-аналарының тәрбияләре һәм мәшәкатьләре күләгәсендә рәхәт күреп үскән кайбер балалар соңыннан аларның фикерләренә каршы киләләр, хәтта сүзләрен ишетергә дә теләмиләр. Бернәрсә дә белмисез, дип алардан көләләр. Сез дә шулар кебек инсафсыз балалар булмагыз.

❁ Әгәр ата-аналарыгыз сезгә тиешсез бер эш кушсалар һич тартынмыйча һәм шул ук вакытта күңелләрен рәнҗетмичә генә инсаф белән ул эшнең тиешсез икәнлеген аңлатырга тырышыгыз.

* * *

Аллаһы Тәгалә әйткән:

*«Аллаһ Раббың Үзенә генә гыйбадәт кылырга һәм ата-анага игелек эшләргә боерды. Әгәр аларның берәрсе яки икесе дә синең яныңда картлыкка ирешсәләр, син аларга «уф» дип тә әйтә күрмә, аларга кычкырма, ә яхшы, мөлаем сүзләр генә сөйлә. Аларга үзеңнең рәхим-шәфкать канатларыңны җәй һәм дога кыл: «Ий, Раббым, алар мине бала чагымда ничек рәхим-шәфкатьлелек белән тәрбияләп үстергәннәре кебек, Син дә аларга рәхмәт кыл!»* Коръән аяте: (Исра-23,24)

*«Без кешегә әти-әнисе хакында васыять кылдык: әнисе аны хәлсез калып күтәреп йөрде, ә күкрәктән аны ике яшь тулгач аералар. Миңа һәм әти-әниеңә шөкерләр кыл, рәхмәтләр укы: кире кайту Миңа булачак».* Коръән аяте: (Локман – 14)

Нинди югары тәрбия, һәм акыллы өйрәтүләр бу сүзләрдә *«Миңа һәм әти-әниеңә шөкерләр кыл»*. Ислам дине ата-анага нинди бөек һәм мәртәбәле урынны биргән!

Мөхәммәд галәйһиссәләм әйткән:

*«Бер кешенең үзенең әтисе яраткан кешеләр белән элемтәдә булуы – игелекле булуның иң күркәмедер».*

Димәк хакыйкый һәм ихлас күңелле бала әтиәнисе яраткан кешеләрне дә яратыр. Ата-анасының вафатыннан соң да аларны онытмас, араны өзмәс.

## ТУГАННАР

❁ Сезгә ата-аналарыгыздан соң иң якын кешеләр – туганнарыгыз. Шуның өчен алар белән һәрвакыт әдәпле һәм мәрхәмәтле булыгыз. Олы яшьтәге туганнарыгызга карата итагатьле булыгыз, сүзләрен тыңлагыз. Кечкенәләренә карата рәхим-шәфкатьле булыгыз.

❁ Әгәр туганнарыгызда ярамаган берәр эш күрсәгез, яхшы сүз белән: «Болай эшләргә ярамый», – дип, ул эшнең ярамаганлыгын әйтегез.

❁ Туганнарыгыз өстеннән һичкемгә әләкләмәгез. Чөнки мондый балалар зур үскәннән соң сүз йөртүче булалар.

❁ Үзләре әйткәнне көтмичә, туганнарыгызның һәр изге эшләрендә ярдәмче булыгыз, кулыгыздан килгән игелекләрне кылуда үзегезне кызганмагыз.

❁ Туганнарыгызның серләрен саклагыз, аларга гел шатлыклы хәбәрләрне генә китерүче булыгыз, бик мөһим булмаса яманнарын сөйләмәгез. Сүзегез һәм эшегез белән аларга ихласлы булыгыз. Башкаларга аларны яманлап йөрмәгез. Аларга карата һәрвакыт ачык йөзле һәм киң күңелле булыгыз.

* * *

Мөхәммәд галәйһиссәләм әйткән:

*«Ризыгы киң һәм гомеренең озын булуын теләгән кеше туганнары белән элемтәне өзмәсен».*

*«Кечкенәләребезгә рәхим-шәфкатьле булмаган, олыларыбызның кадерен белмәгән кеше безнең арадан түгел».*

# КАРДӘШЛӘР

♦ Ата-ана һәм туганнарыгыздан соң сезгә иң якын кешеләр – үзегезнең кардәшләрегез. Шуның өчен алар белән дә күркәм мөгамәләдә булыгыз, барысын да бертигез якын күрегез, әгәр авырсалар барып хәлләрен белегез, шатлык һәм кайгыларын уртаклашыгыз.

♦ Ялкау һәм бозык холыклы кешеләргә игелек итү аларның ялкаулыклары артуга һәм бозыклыклары көчәюгә генә сәбәп була. Шуның өчен андый кешеләр белән башкача мөгамәлә кылыгыз. Хәләл кәсеп белән яшәүче саф күңелле кардәшләрегезгә карата исә башка төрле мөгамәләдә булыгыз. Икесенә дә бертигез итеп карамагыз. Игелекне тиешле урыннарда кылырга тырышыгыз.

* * *

Мөхәммәд галәйһиссәләм әйткән:

*«Бер-берегездән көнләшмәгез, бер-берегезгә күрә алмаучанлык хисләре сакламагыз, тарткалашучыларга колак салмагыз, үз-үзен сөюче «Карун» (байлык җыючы) булмагыз. Башка кешеләрнең гаепләрен эзләмәгез, үзегез сатып алырга теләмәгән малның хакын күтәрмәгез, бер-берегезне ташлап китмәгез, бәхәсләшмәгез һәм сезнең арадан берәүнең килешүенә ризасызлыгыгызны белдермәгез. Аллаһ коллары, туганнар булыгыз! Ул сезгә әмер иткән: мөселман – мөселманның туганы, ул аны кысрыкламый, ярдәмсез калдырмый, һәм аңа нәфрәт белән карамый».*

*«Үзенә теләгән нәрсәне кардәшенә дә теләми торып, берегез дә мөэмин булмый».*

## КҮРШЕЛӘР

❁ Кардәшләрегездән соң сезгә иң якын кешеләр – күршеләрегез. Шуңа күрә күршеләрегез белән дус һәм тату торыгыз. Шатлык һәм кайгыларын уртаклашып, авыру вакытларында хәлләрен белешеп торыгыз, хезмәтләре булса башкарыгыз. Алар өчен һәрвакыт хәер-догада булыгыз.

❁ Күршеләрнең өйләрен тикшермәгез, койма ярыкларыннан карамагыз, һичбер эштә аларның хәтерләрен калдырмагыз. Үзен хөрмәт иткән инсафлы кешеләр күршеләре белән һәрвакыт яхшы мөгамәләдә булалар.

* * *

Аллаһы Тәгалә әйткән:

*«Аллаһы Тәгаләнең Үзенә генә гыйбадәт кылыгыз, Аңа һичкемне һәм һичнәрсәне тиңдәш кылмагыз, ата-аналарыгызга игелек эшләгез һәм якын кардәшләргә, ятимнәргә, мескеннәргә, туган булган күршеләргә һәм туган булмаган күршеләргә дә игелек итегез...».* Коръән аяте: (Ниса-36).

## ӨЙ ЭЧЕНДӘ

❁ Өй эчендәгеләр белән яхшы мөгамәләдә булу шәригать каршында сөекле эш. Шуның өчен өйдәгеләр белән әдәпле вә миһербанлы булыгыз, әгәр аларга яхшы булса, сезгә дә яхшы булыр.

❁ Өй эчендәге серләрне һичкемгә сөйләмәгез.

❁ Ишек, тәрәзә кебек нәрсәләр белән уйнамагыз, югары урыннарга менмәгез, биек җирләрдән сикереп төшмәгез, тәрәзәдән тышка һәртөрле чүпләр ташламагыз.

❁ Хаҗәтханәгә кергән вакытта сул аяк белән кереп, чыкканда уң аяк белән чыгыгыз, анда һичбер сүз сөйләшмәгез, дога һәм язулы кәгазьләр яныгызда булмасын.

❁ Һәрбер эшнең үз вакыты, ә һәр вакытның үз эше булганга күрә, вакыт үткәнче иң кирәкле һөнәрләргә яшь вакытыгызда ук өйрәнегез.

❁ Өй эчендә оста пешерүче булса, аның янында йөреп, аның кебек ләззәтле ашлар пешерергә өйрәнегез.

❁ Утыннарның кайсы яхшы, кайсы начар, чи утынны ничек киптерергә, ничек хәзерләргә кирәген, сөт һәм май-каймакларның әчүен, ит, җимешләрнең бозылуын, шырпы, пычак, балта, урак, чалгы, кайнар аш, самовар кебек куркыныч нәрсәләр, спирт, йод кебек куркыныч нәрсәләрдән ничек сакланырга кирәк икәнен яхшы үзләштерегез.

❁ Башка ис тигәндә, тын беткәндә, агуланганда, кул пешкәндә, борын канаганда, һуш киткәндә, җәрәхәттән кан акканда һәм өшегәндә иң беренче ярдәм күрсәтү өчен нәрсәләр эшләргә кирәген яхшылап белеп алыгыз.

❁ Киемегездә булган ертыкларны үзегез ямагыз, керләрегезне юыгыз, керләрне ничек киптерергә һәм ничек үтүкләргә, сабынны ничек кулланырга икәнлеген яхшы белегез.

❁ Киемнәрегезне үзегез кисеп үзегез тегегез, идәннәрне себерегез, һәр ашаганнан соң савыт-сабаларны юып куегыз, тузаннарны сөртегез, өйдә гел саф һава тотарга өйрәнегез.

* * *

Мөхәммәд галәйһиссәләм әйткән:

*«Өйгә кергәндә ошбу доганы укыгыз: «Бисмилләһи вәләҗнә, вә бисмилләһи хараҗнә вә галә раббинә тәвәккәлнә»* (Аллаһ исеме белән кердек, Аллаһ исеме белән чыктык һәм Раббыбызга тәвәккәл кылдык), *аннары сәлам бирегез».*

*«Өйдән чыкканда ошбу доганы укыгыз: «Бисмилләһи тәвәккәлту галәллаһи вә лә хәүлә вә лә куввәтә иллә билләһ»* (Аллаһ исеме белән (чыгам), мин Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәлләдем, көч-куәт фәкать Аллаһы Тәгаләдә).

## МӘКТӘП ӘДӘПЛӘРЕ

❁ Иртән йокыдан торгач тәһарәт алыгыз, чәчләрегезне тарагыз, көндәлек кием киегез, чәй эчкәннән соң дәресләрегезне кабатлагыз.

❁ Мәктәпкә иртәрәк барыгыз, вакыты җиткәндә үзегез белеп әзерләнегез.

❁ Мәктәпкә баргач әдәп белән үз урыныгызга утырыгыз, дәрес вакытында сөйләшмәгез, гыйлем өйрәнү өчен ихлас белән тырышыгыз, әдәп өйрәнегез, күркәм холыклы булуны үзегезгә зур бәхет дип белегез. Яшь вакытлар бер генә килә, бу вакыт бер үтеп киткәннән соң кире кайтмавын, яшь вакытта тәрбия алмаган кешенең соңыннан үкенүендә файда юк икәнлеген онытмагыз.

❁ Китап, дәфтәр һәм башка язу әсбапларыгызны чиста тотыгыз, каләмегезне киемегезгә сөртмәгез, авызыгызга капмагыз. Бу эшләр беренчедән әдәпкә каршы булса, икенчедән һәртөрле авыруларга сәбәп була.

❁ Иртәнге чәйне эчкәннән соң сез мәктәп киемнәрегезне киеп укырга барасыз. Өйдән чыкканда әти-әниләрегез һәм туганнарыгыз белән саубуллашып: «Аллаһы Тәгалә юлына чыктым, Аллаһы Тәгалә миңа тәүфыйк бирсә иде», – дип дога кылыгыз.

❁ Мәктәп юлында уйнамагыз, туктап төрле нәрсәләргә карап тормагыз, һәрбер очраган бала белән сөйләшеп вакытыгызны бушка үткәрмәгез. Олы кешеләр шикелле вәкарь белән йөрегез. Мәктәптән кайтканда да һәм башка җирләрдә йөргәндә дә гел шулай булыгыз.

❁ Мәктәпкә кергәч аяк киемнәрегезне, бүрек, тун кебек кышкы киемнәрегезне билгеле урынга куегыз. Укытучыга һәм башка иптәшләрегезгә ачык йөз белән сәлам биргәннән соң әдәп белән үз урыныгызга утырыгыз.

❁ Дәрес вакытында башкалар белән төртешмәгез. Һичбер якка авышмыйча, укытучыга туры карап утырыгыз. Класска керсп-чыгып йөргәндә дә инсафлы булыгыз.

❁ Мәктәп эчендә кычкырышып уйнаучы тәрбиясез балалар белән иптәш булмагыз. Аларга катнашып уйнамагыз.

❁ Бер төрле дәрес биргәндә икенче дәресне карап утырмагыз. Укытучы бирә торган дәрескә күңелегезне салыгыз, һәрбер сүзен зиһенегезгә урнаштырыгыз. Дәрес вакытында сөйләшмәгез һәм башка эшләргә күңелегезне бирмәгез. Шулай булсагыз остазларыгызның ризалыгын алырсыз һәм алган гыйлемегездән файда күрерсез.

❁ Укытучы сораганда аяк үрә торып ачык тавыш белән җавап бирегез, иптәшләрегездән соралган сүзгә рөхсәтсез катышмагыз.

❁ Сүзегездә яки язуыгызда булган ялгышларны укытучы төзәтсә аның өчен күңелегезне төшермәгез. Чөнки укытучы сезне яратуы сәбәпле сезнең хаталарыгызны бетерергә тырыша.

❁ Укытучыгыз берәр нәрсәне укырга, язарга яки ятларга кушса, җиренә җиткереп үтәгез.

❁ Һәрвакыт пөхтә һәм тәртипле булу баланың акыллы булуына бер билгедер. Шуның өчен киемнәрегез һәрвакыт чиста, ә китап, дәфтәрләрегез һәрвакыт тәртиптә булсын.

❁ Язу әсбаплары белән киемнәрегезне пычратмагыз, аларны авызыгызга капмагыз.

❁ Стенага асып куйган карталарга, шулай ук урамда йөргәндә коймаларга, капкаларга төрле язулар язмагыз, чөнки бу эшләр тәрбиясезлек галәмәте.

❁ Туп белән булган уеннар буыннарны ныгыта, тәнне сәламәтләндерә, шуңа күрә андый уеннардан читтә тормагыз.

❁ Уеннарыгыз ял сәгатьләрендә, дәресләрегезгә һәм башка кирәкле эшләрегезгә кимчелек китерми торган рәвештә, саф һавада булсын.

❁ Мәктәптән кайткач әти-әниләрегезгә сәлам бирегез, китап, дәфтәрләрегезне билгеле урынга куегыз.

❁ Уйныйсыгыз килсә әдәп белән генә уйнагыз. Дәресләрегезне әзерләмичә йокларга ятмагыз.

❁ Мәктәптә булса да, башка җирдә булса да әдәпсез сүзләр сөйләмәгез. Башкаларны үзегездән нәфрәтләндермәгез.

❁ Дәресләрне күп калдыру яки дәрескә соңга калып килү иптәшләрдән артта калуга сәбәп була. Шуның өчен дәресләргә йөрүгә игътибарлы булыгыз.

❁ Мәктәпкә йөреп сабак укудан максат иманлы һәм тәрбияле кеше булу икәнлеген исегездән чыгармагыз. Әгәр синнән: «Ни өчен мәктәпкә йөрисең, ни өчен укыйсың?» – дип сораучы булса, син: «Аллаһы Тәгаләнең боерыгын җиренә җиткерү өчен, әти-әниемнең хәер-догасын алуны һәм туганнарыма, кардәшләремә, ватаныма файдалы кеше булуны өмет итеп укыйм», – дип җавап бир.

❁ Мәктәпне бетергәннән соң да «инде уку бетте, гыйлемем җитәрлек булды» дип гыйлемнән һәм китаплардан аерылмагыз, бәлки буш вакытларыгызда дөньягыз һәм ахирәтегез өчен файдалы китапларны укыгыз. Шул сәбәпле зиһенегез ачылыр, акылыгыз артыр, фикерегез дөресләнер.

## ГЫЙЛЕМ

❁ Аллаһының рәхмәтенә ирешү өчен гыйлем алуны үзенең төп бурычың итеп кабул ит.

❁ Мәрхәмәтле Аллаһы Тәгаләнең гыйлем ияләрен югары дәрәҗәләргә күтәрүе, фәкать алар гына Аллаһыдан хакыйкый курка, дип әйтеп куюы – синең өчен гыйлем өйрәнүдә дәрт биреп торучы маяк булып торсын.

❁ Гыйлем – күңел күзен ачар, наданлык караңгылыгын җибәрер, олы дәрәҗәләргә ирештерер, дошманнарга каршы корал булыр, тереклекне саклар, дөньяда тору юлларын белдерер, ил эчендә ни рәвештә булырга кирәклеген өйрәтер. Гыйлем галимнәрнең зиннәте, адәмнәрнең хөрмәте булып, һич бетми торган байлыктыр.

❁ Галимнәр – пәйгамбәрләрнең варислары, дөньяның яктыртып торучы нурларыдыр. Наданнар исә тере булсалар да үлекләр хөкемендә. Чөнки

алар Аллаһы Тәгаләнең гаҗәеп нәрсәләрен күреп торсалар да, алардан гыйбрәт ала белмиләр.

❁ Гыйлеме күп булган кешеләргә карап, аз белемле булудан оялмагыз, әмма белергә кулыгыздан килә торган нәрсәләрне белми калудан оялыгыз.

❁ Гыйлем әһелләренә нәфес артыннан йөрү һич килешми, шуның өчен шәригать үлчәвеннән тыш мал сөймәгез, нәфес теләкләренә әсир булмагыз.

❁ Гыйлемне һәрвакыт сөегез. Өйрәтелгән нәрсәләрне ихлас белән тыңлагыз, кирәкләрен өйрәнегез һәм һәрбер гыйлемнән күркәм булганын белегез, һичбер вакыт гыйлемгә тәкәбберлек күрсәтмәгез.

❁ Гыйлем өйрәнү гүзәл эш булса да, бозык ният белән укылса гүзәллеге бетәр. Шуның өчен гыйлем алудан элек: «Бездән Аллаһы Тәгалә риза булып, яхшы эшләргә сәбәп кылса иде», – дип ният кылырга кирәк. «Зур дәрәҗәле кеше булам» дип ниятләмәгез. Күңелегездә андый нәрсәләр булса чыгарып ташлагыз. Гыйлемнән максат дәрәҗә түгел, бәлки җәмгыятькә файдалы, Аллаһы Тәгаләгә яраклы адәм булудыр.

* * *

Ислам – җиңеллек дине. Чын Ислам тәрбиясе алган кеше диндә авырлыклар тудырмый, чөнки ул шуның белән эшләрне катлауландыруын, аларның гомуми зыян китерүгә алып килүен яхшы белә. Дөрестән дә, авырлыклар тудырырга омтылу һәм эшләрне катлауландыру, теге яки бу әхлакый тайпылышлары булган, һәм яхшы тәрбия алмаган кешеләргә генә хас.

❁ Кеше надан булырга тиеш түгел. Белгәннәр өйрәтергә, белмәгәннәр өйрәнергә тиеш.

❁ Гыйлемне мөмкинлек булганда өйрәнергә кирәк. Кирәк вакытта гына мөмкинлек табылмас.

❁ Гөнаһ эш кылу алган гыйлемнең бәрәкәтен бетерә, зиһенне ала.

❁ Кешеләр дөнья малы белән баеган вакытта, син Аллаһыдан рухи байлык сора; кешеләр дөнья шатлыкларына сөенгәндә, син барча уй-хисләреңне Аллаһыга юнәлт. Кешеләр олы дәрәҗәләргә һәм хөрмәткә ирешер өчен үзләренең түрәләренә барсалар, син Аллаһыга омтыл, Аны бөтен барлыгың белән сөй, һәм син иң югары дәрәҗәләргә һәм хөрмәткә ирешерсең.

❁ Әгәр эшләрең бармаса, акыл ияләреннән, галимнәрдән киңәш сора, алардан нәсыйхәт сораудан тәкәбберләнмә, тәҗрибә ияләренең сүзләренә колак сал; синең алардан киңәш сорап, уңышка ирешүең үзлегеңнән эш итеп, ахырда үкенүеңнән хәерлерәктер.

* * *

Мөхәммәд галәйһиссәләм әйткән:

*«Гыйлем алу – һәрбер мөселман өчен фарыз».*

*«Гыйлем алу юлына баскан кешенең Аллаһы Тәгалә җәннәткә керү юлын җиңеләйтер, фәрештәләр аның өстендә канатларын җәеп торырлар, җирдәге һәм күктәге нәрсәләр, хәтта судагы балыклар да аның гөнаһлары ярлыкануын теләп торырлар. Галим кешенең башкалардан артыклыгы йолдызлар янындагы тулган ай кебектер. Галимнәр пәйгамбәрләрнең варисларыдыр, пәйгамбәрләр исә дөнья малын түгел, ә гыйлемне мирас итеп калдырдылар, кем аны алса, димәк ул бик зур өлеш алды дигән сүз».*

## ✓ КИТАП УКУ

❁ Гүзәл китаплар – гаҗәеп эшләрне күрсәтүче күзге, аулакта сердәш, ялгызлыкта иптәш, гаҗизлек вакытында ярдәмче, кайгылы вакытта шатлык китерүче, фикерләрне нурландыручы, үткән заман вакыйгаларын хикәя кылучы, акыллы кешеләрнең акылларын күзгә күрсәтүче, бәһасе арзан булса да, әмма файдасы күп булган нәрсәләрдер.

❁ Китаплар арасында кирәксез нәрсәләр белән тулганнары да була. Аларны уку кыйммәтле вакытны юкка чыгару була. Шуның өчен фикерләрне нурландырырлык, холыкларны күркәмләүгә ярдәм итәрлек, акылларны арттырырлык китапларны сайлап укыгыз. Файдалы китаплар уку күңелгә шатлык китерә, фикергә азык, зиһенгә куәт була.

❁ Китап уку кешенең йөзенә нур, күңеленә шатлык китерә. Шуның өчен зиһен хезмәте белән шөгыльләнүчеләр никадәр арык булсалар да акыллары симез, ә йөзләре мәхәббәтле була.

## ✓ УКЫТУЧЫ

❁ Укытучылар һәм мәктәп хезмәткәрләре сезнең эшләрегезне юлга куючылар. Сезнең өстегездә аларның хаклары зур. Шуның өчен аларның әмерләрен җиренә җиткереп үтәгез, тыйган эшләренә якын бармагыз.

❁ Сөйләшкән вакытта алар белән әдәпле сөйләшегез, тавышыгызны күтәрмәгез, аларга нәрсәнедер алдап сөйләмәгез.

❁ Ата-аналарыгыз сезнең тәннәрегезне тәрбияләп үстерсәләр, остазларыгыз исә җаннарыгызны тәрбияләп үстерәләр. Шуның өчен аларны чын

күңел белән сөегез, сүзләрен һәм үгет-нәсыйхәтләрен тыңлагыз. Хасталарның табипларга тапшырылуы кебек, үзегезне аларга тапшырыгыз.

❁ Укытучылар янында түбәнчелекле булыгыз, әдәпле утырыгыз, нәсыйхәтләре белән гамәл кылыгыз, хезмәтләрен җиренә җиткереп үтәгез.

❁ Укытучыларга каршы килмәгез, алар белән кычкырышмагыз, гүзәл эшләрдә аларның сүзләренә җан-тән белән иярегез, ләкин аңламаган урыныгыз булса әдәп белән: «Бу җирен аңламадым», – дип кайтарып сорагыз.

❁ Мәктәпне бетергәннән соң да укытучыларыгыз һәм тәрбиячеләрегезнең хезмәтләрен исегездән чыгармагыз, очрасалар хөрмәт күрсәтегез, алар өчен һәрвакыт хәер-дога кылыгыз.

## ✓ УКУЧЫ БАЛАЛАР

❁ Һәрбер бала белән, бигрәк тә үз мәктәбегезнең укучы балалары белән, матур яшәгез, аларны туганнарыгыз кебек күрегез, алар белән йомшак сөйләшегез. Бер-берегез белән очрашкан вакытта йөзегездә куану билгеләре чагылсын. Шатлык һәм кайгыларын уртаклашыгыз.

❁ Яман холыклы балалардан ерак булыгыз, чөнки яман холык йогышлы була.

❁ Аталарыгызның байлыгы, һөнәрләре һәм киемнәрегез белән башкалар алдында мактанмагыз, үзегезне күрсәтмәгез, бәлки һәрвакыт түбәнчелекле булыгыз.

❁ Күңелне каралтучы, әдәпсез хикәяләр сөйләмәгез, кычкырышмагыз, сүз көрәштермәгез, иптәшләрегезнең хәтерләре калырлык ишарәләрдән, бигрәк тә аларга кул күтәрүдән сакланыгыз.

♦ Файдасыз эшләр белән шөгыльләнеп дәресләрегезне калдырмагыз.

♦ Иптәшләрегездә булган нәрсәләргә кызыкмагыз, алардан шул нәрсәләрне сорамагыз. Бөеклек алуда түгел, бирүдәдер, шуны онытмагыз.

♦ Мәктәпне бетергәннән соң да бергә укыган иптәшләрегезне онытмагыз, нинди зур дәрәҗәләргә ирешсәгез дә бергә укыган иптәшләрегезнең иң түбән дәрәҗәлесе алдында да үзегезне зурга куймагыз.

## ДУСЛЫК ӘДӘПЛӘРЕ

♦ Адәм баласының шатлык һәм кайгы вакытларында таяныр кешеләре – үзенең дусларыдыр. Шуның өчен дусларны үзегезгә туры килә торган кешеләр арасыннан эзләгез.

♦ Дусларның күңелләре арасында йөри торган илче, авырлык вакытларында бер-берсенә ярдәм итүгә сәбәпче нәрсә – үзара булган өлфәттер. Әгәр шул өлфәт ике тарафның да ихлас һәм үзара мәхәббәтләре аркылы хасил булган булса, дәвам итәр, ә бер файда күрү өчен генә булса, ялган өлфәт булыр. Шуның өчен мәхәббәтегез чын булсын дисәгез дусларыгызны яхшы кешеләр арасыннан сайлагыз. Дине бөтен, акылы камил һәм фикере туры булган әдәпле кешеләрне табыгыз. Мондый кешеләр авыру вакытыгызда дәва, мәшәкатьле, боек сәгатьләрегездә таяныч, күңелләрне күтәрүче, сәфәргә киткән вакытыгызда догачыгыз булырлар. Байлыкка ирешүләре белән сездән киселмәсләр, ә сез тарлыкка төшсәгез, ярдәмнәреннән ташламаслар. Дуслыклары сүзләреннән бигрәк эшләрендә күренер. Әгәр шундый дусларыгыз булса аларга

нык ябышыгыз, үзегездә кимчелекләр булдырмагыз. Дусларыгызны чын күңелдән сөегез, арагызны үлемнән башка бернәрсә дә аермасын.

❁ Дустанә мөгамәлә кылучыларның барысы белән дә дус булырга ашыкмагыз һәм үзегез яратмаган кешеләрнең барысын да дошман күрмәгез. Дуслыгы саф булмаган кешеләр белән аркадаш булмагыз, андый дуслыкка караганда һич дусларсыз тору яхшырак булыр.

❁ Телләре белән генә вәгъдәле, ихлас күңелле булып сөйләшүчеләр белән дә сынамастан элек ышанып дус булмагыз. Тел күп вакытта ялган сөйли, ихтимал бу кешеләр дә үзләренең теләкләренә ирешер өчен генә шулай матур сөйлиләрдер.

❁ Дусларыгызны шелтәләргә ашыкмагыз, алар белән бозылышуны җиңелгә санамагыз. Бәлки бераз сабыр итегез. Сабыр иткәнегез өчен соңыннан үзегез дә шатланырсыз.

❁ Мөһим сәбәпләр булмаганда дусларыгыздан бозылышып аерылмагыз, бу бик начар эш.

❁ Һәрвакыт хөрмәт күрсәтү һәм хакын җиренә китерү сәбәпле дуслык көчәя. Шуның өчен дусларыгызга һәрвакыт ярдәмче һәм таяныч булыгыз. Кеше үзе бер ялгызы булса да, дуслары белән күп булыр. Дуслар авыр көннәрдә ярдәмче булсыннар өчен кирәк.

❁ Бозык кешеләр белән аралашмагыз, алар белән дошман да булмагыз.

* * *

Мөхәммәд галәйһиссәләм әйткән:

*«Кеше уз дустының динендә булыр, шуның өчен ул узенә дус булачак кешенең холкын белсен!»*

Чыннан да, кеше үзенә туры килә торган кеше белән дус була. Шуңа күрә, акыллы кеше ахмак белән, түбәнчелекле кеше тәкәббер белән, галим кеше надан белән, ихлас күңелле мөселман монафыйк белән һичкайчан дус була алмас. Дус буласы кешене яхшы итеп сынарга кирәк. Яман кеше белән дус булганчы, бернинди дусларсыз гомер сөрү яхшырак.

Мөхәммәд галәйһиссәләм янә әйткән:

*«Мөселман кеше үзенең кардәшеннән киселеп өч көннән артык торырга тиеш түгел. Алар үпкәләшүләре сәбәпле, очрашкач та, һәрберсе үз ягына карап ике якка китеп баралар. Аларның иң яхшысы – башлап сәлам бирүче булыр».*

*«Гадел, яхшы дус – ислемай сатучыга, ә начар иптәш – тимерче күреген өрдерүчегә тиң. Ислемай сатучы янында булсаң, син аннан ислемай сатып алачаксың, яки бер дә булмаса сиңа аннан килгән хуш ис сеңәчәк. Күрек өрдерүчегә килгәндә исә, ул яки синең киемеңне яндырачак, яки син аннан үзеңә яман ис ияртеп чыгачаксың».*

## ЙӨЗ ӘДӘПЛӘРЕ

❁ Кешенең йөзе аның күңеле йомшакмы яки катымы икәнлеген күрсәтүче көзгедер. Шуның өчен йөзегез һәрвакыт ачык булсын, рәхим-шәфкатьле кеше булуыгыз йөзегездән беленеп торсын.

❁ Кеше белән сөйләшкән вакытта читкә карап сөйләшмәгез, күзегезне йоммагыз.

❁ Чытык, караңгы йөзле булмагыз. Йөзегезгә мәсхәрәләү билгеләре чыгарудан сакланыгыз. Дусларыгыз һәм иптәшләрегез сездән тартынмыйча сөйләшсеннәр өчен һәрвакыт ачык йөзле булыгыз.

* * *

Мөхәммәд галәйһиссәләм әйткән:
*«Кардәшеңә елмаю да изгелектән санала».*

## КҮЗ ӘДӘПЛӘРЕ

❁ Һәр нәрсәгә канәгатьлек күзе белән карагыз, кешеләрдәге нигъмәтләргә көнчелек белән бакмагыз. Бәлки үзегезгә дә шундый нигъмәтләр насыйп булуын Аллаһыдан дога кылып сорагыз.

❁ Фәкыйрь һәм мескеннәргә, авыру һәм бәла-казага очраган кешеләргә мәсхәрә күзе белән карамагыз, гөнаһ, оят эшләрне тамаша кылып карап тормагыз.

❁ Башкаларның язуларына яки хатларына рөхсәтсез күз салмагыз.

❁ Укыган һәм язган вакытта күзегезне бер карыштан да якын тотмагыз, ут сул яктан төшсен, яктылык сүлпән булганда язмагыз да, укымагыз да.

❁ Кояш, ай һәм көчле лампа кебек артык якты нәрсәләргә озак карап тормагыз. Ак, кызыл төстә булган нәрсәләргә дә озак карамагыз. Күз өчен яшел һәм күк төсләр файдалы.

## БОРЫН ӘДӘПЛӘРЕ

❁ Борыныгызны ялан кул белән яки киемгә сеңгермәгез, яныгызда кулъяулык булсын.

❁ Ашаган вакытта борын сеңгерергә туры килсә бер читкә борылып тавышсыз гына кулъяулыкка сеңгерегез.

❁ Төчкергән вакытта йөзегезне читкә борыгыз һәм соңыннан авызыгызны су белән юыгыз.

* * *

Мөхәммәд галәйһиссәләм әйткән:

*«Төчкергән кеше: «Әлхәмду лилләһ»* (бөтен мактау Аллаһы Тәгаләгә!), *ә иптәше аңа: «Йәрхәмукәллаһ»* (Аллаһ сиңа рәхмәт кылсын!) – *дисен. Төчкерүче иптәшенә: «Йәһдикумуллаһу вә йусълих бәләкум»* (Аллаһы Тәгалә сине туры юлга күндерсен һәм барча эшләреңне төзәтсен!), – *дип җавап бирсен».*

## КОЛАК ӘДӘПЛӘРЕ

❁ Аллаһы Тәгалә колакларны файдалы сүзләрне ишетү өчен яралткан. Шуңа күрә алар белән Коръән Кәрим, хәдис һәм гыйбрәтле сүзләрне, ата-ана һәм остазларыгызның үгет-нәсыйхәтләрен генә тыңлагыз.

❁ Бозык сүз ишетү акылга бозыклык китерә. Шуның өчен начар сүзләр тыңламагыз. Кешеләрнең яшерен сүзләрен тыңлап тормагыз, яшерен сүзләрне тыңлаучылардан һичкемнең күңеле риза булмас.

❁ Сүз йөртүчеләр һәм гайбәт сөйләүчеләрне тыңламагыз. Аларга бу эшләрнең гөнаһ икәнлеген әдәп белән сөйләп аңлатыгыз, үзегездән кече булсалар, йомшаклык белән генә тыегыз.

❁ Ишеткән сүзләрнең фетнәгә сәбәп була торганнарын һичкемгә сөйләмәгез. Әдәпсез урыннарга барып, гөнаһка төшерүче уен тавышларын тыңламагыз.

❁ Йөзегезне юганда колакларыгызны да юыгыз.

❁ Бик зур һәм авыр алкалар асып колакларыгызны бозмагыз яки бөтенләй кимәгез.

* * *

Аллаһы Тәгалә әйткән:

*«Тәхкыйкъ, колак, күз һәм йөрәк – барысы өчен дә сорау алыначак».* Коръән аяте: (Исра-36)

## КУЛ ӘДӘПЛӘРЕ

❁ Күрешкәндә уң кул белән күрешегез. Хаксыз кул озайтмагыз һәм кешеләрне рәнҗетмәгез. Яхшы белегез: хакыйкый мөселманнын теленнән дә, кулыннан да башка мөселманнар сәламәт булырлар.

❁ Тырнакларыгызны озын йөртмәгез, кимермәгез, астында булган керләрне тазартыгыз, кешеләр алдында кулларыгыз белән уйнамагыз, бармакларны шартлатмагыз, аралаштырмагыз.

❁ Берәр кешене чакырганда кул болгап түгел, бәлки мөлаем тавыш белән чакырыгыз.

❁ Пычрак нәрсәләрне тотканнан соң кулларыгызны юыгыз. Юеш кул белән киемнәрегезне чылатмагыз. Кулларыгызны юганнан соң сөртегез.

❁ Бармакларыгызны йөзек һәм балдаклар белән тутырмагыз.

## БАШ ӘДӘПЛӘРЕ

❁ Башыгызны гадәттән тыш түбән яки бер тарафка салындырмагыз, кеше янында кашымагыз.

❁ Чәчләрегезне таза йөртегез, тарагыз, көйдермәгез, бөтермәгез, табигый хәлен үзгәртмәгез, химия белән бозмагыз.

❁ Үргәндә артык тыгызламагыз, башка кеше чәчен кушып асмагыз, чәч очына авыр нәрсәләр такмагыз.

* * *

Мөхәммәд галәйһиссәләм әйткән:

*«Кемнең чәче булса, аңа тиешле хөрмәтен күрсәтсен».*

## УТЫРУ ӘДӘПЛӘРЕ

❁ Утырганда таянмыйча, төп-төз итеп утырыгыз.

❁ Сөйләшкәндә кешегә кулыгызны салмагыз, бер аягыгызны икенчесе өстенә куймагыз, аяклар белән уйнамагыз.

❁ Укыган һәм язган вакытта күз белән китап, дәфтәр арасы бер карыштан да якын булмасын, күкрәк белән өстәлгә ятмагыз, үзегезгә зарар килмәслек итеп утырырга гадәтләнегез.

## ЙОКЫ ӘДӘПЛӘРЕ

❁ Кешенең табигатенә муафикъ рәвештә кичтән ятып йоклагыз, куркыныч төшләр күреп саташмас өчен, йөзтүбән яки чалкан түгел, бәлки уң як яныгызга ятыгыз.

❁ Йокы вакытыгызны беркадәр тәртипкә салыгыз, тугыз-ун сәгатьтән калмый ятып, иртән алтыда торыгыз.

❁ Йокыгыз туйганнан соң торырга иренеп ятмагыз.

❁ Йоклаган вакытыгызда өстегезгә берәр нәрсә ябынып йоклагыз, җиләс һәм юеш урыннарда ятмагыз, усаллар куркынычы булса тәрәзәләрне ачык калдырмагыз.

❁ Йоклаган вакытыгызда тар киемнәрегезне салыгыз, бер бүлмәдә күп кеше бергә йокламагыз,

йокы бүлмәсендә гөлләр, чәчәкләр булмасын. Йокыга хәтле һәм йокыдан торгач, тәрәзәләрне ачып йокы бүлмәсен җилләтегез.

❖ Ашказаны тулы килеш йокларга ятмагыз.

* * *

Кич белән бу доганы укыгыз:

*«Әмсәйнә вә әмсә-л-мулку лилләһи рабби-л-галәмин».* Мәгънәсе: «Менә без бу кичкә дә кердек. Бу кичнең патшалыгы галәмнәрнең тәрбиячесе Аллаһы Тәгаләнекедер».

Йоклар алдыннан:

*«Әллаһуммә әсләмту нәфси иләйкә, вә вәҗҗәһту вәҗһи иләйкә, вә фәуввазъту әмри иләйкә, вә әлҗәэту заһри иләйкә рагьбәтән вә раһбәтән иләйкә, лә мәлҗә-ә вә лә мәнҗә минкә иллә иләйкә. Әәмәнту би китәбикәлләзи әнзәлтә вә би нәбиййикәлләзи әрсәлтә».* Мәгънәсе: «Ий, Аллаһы Тәгалә! Мин үземне Сиңа тапшырдым һәм йөземне Сиңа юнәлттем, һәм Сиңа омтылган һәм курыккан хәлдә аркамны ышыкладым, качу һәм котылу урыны мәгәр Синең алда гына, мин Синең иңдергән китабыңа һәм җибәргән илчеңә иман китердем».

Йокыдан торгач: *«Әлхәмду лилләһилләзи раддә галәййә рухи вә гафәни фи җәсәди вә әзинә ли би зикриһ».* Мәгънәсе: «Миңа җанымны кайтарып биргән, бәдәнемә рәхәтлек биргән һәм Үзен зикер итәргә миңа рөхсәт иткән Аллаһы Тәгаләгә барча мактаулар булсын».

Иртә белән: *«Әсъбәхнә вә әсъбәхә-л-мулку лилләһи рабби-л-галәмин».* Мәгънәсе: «Менә без иртәнгәчә исән-сау яшәдек. Бу иртәнең патшалыгы галәмнәрнең тәрбиячесе булган Аллаһы Тәгаләнекедер».

# ЙӨРҮ ӘДӘПЛӘРЕ

❁ Кирәк булмаганда артык ашыгып яки артык акрын йөрмәгез. Йөрүегез гадәттә туры һәм төз булсын.

❁ Шәһәрдә йөргәндә урам уртасыннан түгел, бәлки бер читтән йөрегез. Каршы килүчеләр булса, уң тарафыгыздан китегез, артыгызга яки як-ягыгызга каранып йөрмәгез, күзегез алдыгызда булсын.

❁ Юлда туктап тормагыз; каршы килүчеләрнең күзләренә тутырып карамагыз, аларга кагылмагыз, тыгызлык булса, уң тарафта туктап юл бушаганны көтегез. Зәгыйфьләр һәм гаҗизләр очраганда кулыгыздан килгән ярдәмне күрсәтегез. Зур, авыр нәрсәләр күтәреп килүчеләргә юл бирегез.

❁ Кычкырышучыларга, дәгъвачыларга очрасагыз, араларына кермәгез, үз юлыгызда булыгыз, турылыгына кызыгып пычрак юлларга кермәгез. Юлларның турысы туры түгел, бәлки яхшысы турыдыр.

❁ Тыгыз урыннарда кесәләрегезне, сәгатьләрегезне һәм башка нәрсәләрегезне яхшы саклагыз. Чалбарсыз яки чабуларыгыз ачык хәлдә урамда йөрмәгез.

❁ Дус-ишләр, танышлар очраганда «Әссәләмү галәйкүм» – дип сәлам бирегез, алар сездән элек сәлам бирсәләр хөрмәт белән «Вә галәйкүмүссәләм», – дип җавап кайтарыгыз.

❁ Йөргәндә аякларыгызны өстерәмәгез, кешедән көлеп калмагыз, берәр кешене мәсхәрәләп аның кебек йөреп күрсәтмәгез.

❁ Урамда йөргән вакытыгызда көнбагыш орлыгы һәм башка нәрсәләр ашамагыз, бу эшләр тәртипсезлек галәмәтедер.

❁ Олылар сезнең белән сөйләшеп йөрсәләр, аларның уң тарафларында бертигез булып йөрегез. Әмма өйгә, пароходка, вагоннарга кергәндә һәм чыкканда юл күрсәтү өчен аларның алларыннан барыгыз.

❁ Берәр кешегә зарар китерү яки шәригать һәм әдәпкә каршы булган эшләргә бер адым да ясамагыз.

* * *

Аллаһы Тәгалә әйткән:

*«Кешеләр белән сөйләшкәндә тәкәбберләнеп, яның белән сөйләшмә һәм җир өстендә масаеп йөрмә, тәхкыйкъ Аллаһы Тәгалә үзенә-үзе исе китеп, мактанып йөрүчеләрне сөйми».* Коръән аяте: (Локман-18)

## СӘФӘР ӘДӘПЛӘРЕ

❁ Самолет яки поезд белән сәфәр кылган вакытыгызда очу, кузгалу вакытларын яхшы белегез. Вакыты җитмәстән ике сәгать элек аэропортта, бер сәгать элек вокзалда булыгыз. Салон яки вагонга кергәндә-чыкканда башкаларны кысрыкламагыз, йөкләрегезне яхшы урнаштырыгыз, юлдашлар белән әдәпле булыгыз, ялан аяк яки чалбарсыз йөрмәгез. Һичкемгә илтифатсызлык күрсәтмәгез. Сезнең белән сөйләшергә теләүчеләр белән әдәпле генә сөйләшегез, низаглы мәсьәләләргә керешмәгез.

❁ Самолеттагы урыныгызның һәм тимер юлда үзегез барган поезд, вагон, купе номерларын истә тотыгыз. Бу мәгълүматлар әйберләрегез онытылып

калса яки берәр сәбәп белән үзегез калыр булсагыз, телеграмма бирергә яки югалган нәрсәләрегезне табарга ярдәм итәр.

◈ Тукталышыгызга килеп җитәрәк йөкләрегезне җыеп бәйләгез, ничә кисәк икәнен санагыз.

◈ Самолетта рөхсәтсез чыгу юлына ашыкмагыз. Ут белән яктыртылган язулы такталарга игътибарлы булыгыз.

* * *

Самолет, пароход, поезд һәм машина кебек нәрсәләргә утыргач ошбу аятьне укыгыз:

*«Субхәәнәлләзии сәххара ләнәә һәәзәә вә мәә күннәә ләһүү мукъриниин. Вә иннәә иләә раббинәә ләмуңкалибүүн».* Мәгънәсе: «Бу нәрсәләрдән безне файдаландыручы Аллаһы Тәгалә һәр кимчелектән пакьтер. Әлбәттә, бу нәрсәләрне без үзебез булдыра алмас идек. Һәм без, әлбәттә, Раббыбызга әйләнеп кайтачакбыз».

## АШАУ-ЭЧҮ ӘДӘПЛӘРЕ

◈ Ашарга утырыр алдыннан кулларыгызны юыгыз. Үзегездән олы кешеләр булганда алардан элек утырмагыз. Өстәл янында уйнамагыз, тәмам туеп җитмәстән туктагыз.

◈ Тастымалыгызны тезләрегезгә куегыз, аштан бик ерак яки бик якын утырмагыз, туры утырыгыз, ашаганда бераз бөгелегез.

◈ Башлаганда «бисмилләһ»не әйтеп уң кул белән ашагыз, ашап бетергәч, *«Әлхәмду лилләһилләзи әтъгамәнә вә сәканә вә җәгаләнә минә-л-муслимин»* догасын укып, Аллаһы Тәгаләгә мактаулар әйтегез.

❁ Зур-зур итеп капмагыз, кулларыгызны, киемнәрегезне буямагыз, башкаларның ашларына карап тормагыз, комсыз булмагыз, күп ашауга гадәтләнмәгез.

❁ Бөтен фикерегезне ашауга гына сарыф итмәгез, бәлки яшәр өчен ашагыз, ашау өчен тереклек итүче булмагыз. Сөйләшеп ашалган аш җиңел сеңә, шуңа күрә кычкырышмый, сүз көрәштерми генә сөйләшеп ашагыз.

❁ Пешеп җитмәгән җимешләрне ашамагыз. Эссе вакытларда майлы ашаудан сакланыгыз. Вакытында ашауга гадәтләнегез. Вакыты җитеп тә теләгегез булмаса, көчләп ашамагыз.

❁ Авызыгызга алган нәрсәләрне яхшылап чәйнәгез, ашыкмагыз, артык озакка да сузмагыз, бәлки ашауны егерме-утыз минут арасында тәмам итегез. Ашаганнан соң ике сәгать үтми торып йокламагыз һәм бик авыр эшләр эшләмәгез.

❁ Һәркөн иртән йокыдан торгач, тәһарәт алганда һәм ашаганнан соң авызыгызны яхшылап чайкагыз, теш араларында бернәрсә дә калмасын.

❁ Никадәр зур ялгышы булса да аш янында һичкемне шелтәләмәгез һәм һичкемнең гайбәтен сөйләмәгез.

❁ Ашаган вакытыгызда эчәргә теләсәгез, авызыгыздагы ризыкны йоткач кына эчегез, эчкәннән соң авызыгызны киемегез яки кулыгыз белән түгел, бәлки тастымал белән сөртегез.

❁ Сәламәтлек өчен иң яхшы эчемлек саф су. Исләнгән яки бозлы, карлы сулар, күл һәм саз суларын эчүдән сакланыгыз. Ашаганнан соң ике сәгать үтми торып, йокыдан тору белән һәм тирләгәннән соң салкын су эчмәгез.

❁ Ишетү һәм күрүне зәгыйфьләндергәне, сулышны тарайтканлыгы һәм авыз тәмен бетергәне өчен һичкайчан тәмәке тартмагыз.

❁ Малларны харап итүгә һәм үлем хасталыкларын алып килүгә сәбәп булган исерткечләрнең һәр төреннән бик нык сакланыгыз, боларны кулланучылар белән хәтта дус һәм белеш тә булмагыз.

* * *

Аллаһы Тәгалә әйткән:

*«Ашагыз, эчегез ләкин исраф кылмагыз».* Коръән аяте: (Әгъраф-31)

Мөхәммәд галәйһиссәләм әйткән:

*«Мөэмин кеше карыны ачмыйча ашарга утырмас, утырса, карыны тулганчы ашамас».*

*«Кешенең иң явыз гамәлләреннән берсе – карынын ризык белән бөтенләй тутыруыдыр. Карынның бер өлешендә ризык булса, икенче өлешендә су булсын, өченче өлеше исә һава суларга калсын. Карынны менә шулай өчкә бүләргә кирәк».*

*«Уң кул белән ашагыз һәм уң кул белән эчегез, чөнки сул кул белән шайтан гына ашый һәм эчә».*

*«Бер сулыштан эчмәгез, бәлки ике, өч сулыш ясап эчегез».*

## МӘҖЛЕС ӘДӘПЛӘРЕ

❁ Мәҗлескә килгәч әдәп белән үзегезгә җайлы урынга утырыгыз. Урын иркен булганда түрдән алгарак урнашыгыз, мәгәр хуҗа боерса гына түргә утырыгыз.

❁ Урындыкларга ятмагыз, аякларыгызның берсен икенчесе өстенә куймагыз. Өстәл, урындык аякларына типмәгез, уйнамагыз.

❁ Сөйләүчене әдәп белән тыңлагыз. Кирәкмәгәнгә көлмәгез, мәҗлескә лаек булмаган сүзләр сөйләмәгез, сөйләүченең сүзен бүлдермәгез, мәҗлестәгеләрнең хөрмәтләрен җибәрмәгез.

❁ Халык алдында иң сөйкемсез кеше мәҗлестә үз-үзен олыга санаучыдыр. Шуның өчен үзегезне башкалардан югары тотмагыз.

❁ Мәҗлесләрдә, бигрәк тә туй кебек шатлыклы мәҗлесләрдә булсагыз, күп көлүдән һәм артык уен-көлкедән сакланыгыз. Ачык йөз белән сабыр булып торыгыз. Кайгылы һәм ачулы кешеләр йөзеннән көлмәгез, андый кешеләргә күңелләрен табарлык сүзләрдән башка нәрсәләр сөйләмәгез.

❁ Кешеләр алдында кикермәгез, кулыгыз яки кулъяулык белән пәрдәләми торып иснәмәгез, авызыгызны ачып тешләрегезне казымагыз, йөткергән вакытта сүз сөйләмәгез, бу вакытта йөзегезне читкә борыгыз. Йөткерү күп кабатланса мәҗлестән чыгып торыгыз.

❁ Сөйләшкән вакытта төкерек чәчмәгез, кулларыгызны болгамагыз, берәүнең сүзе бетми торып сүзгә кушылмагыз. Кешеләргә таба карап төкерүдән сакланыгыз, аның өчен яныгызда кулъяулык булсын. Чи суган, сарымсак яки башка нәрсәләр белән авызыгызны сасытмагыз.

* * *

Һәрбер мәҗлестән соң ошбу доганы укыгыз:

*«Сүбхәнәкәллаһүммә вә бихәмдикә, әшһәдү әллә иләһә иллә әнтә, әстәгъфирукә вә әтүбү иләйкә»*. Мәгънәсе: «Дан һәм мактау Сиңа, ий, Аллаһ! Синнән башка Аллаһ юклыгына гуаһлык бирәм. Синнән гөнаһларымны ярлыкавыңны сорыйм һәм Сиңа тәүбә кылам».

# КУНАК ӘДӘПЛӘРЕ

◈ Кунак чакырганда алдан хәбәр итегез, кунакларны ачык йөз һәм хөрмәт белән каршы алыгыз. Һәркемне үз урынына утыртыгыз.

◈ Никадәр ләззәтле булса да ашларыгызны үзегез мактамагыз, кунакларны артык кыстамагыз, кунак итүченең вазифасы кунаклар хозурына аш китерү һәм бүлү, ашау яки ашамау кунакларның үз ихтыярларында.

◈ Кунакларның һәрберсе белән яннарына утырып бераз сөйләшегез, киткән вакытларында саубуллашып рәхмәт әйтеп калыгыз.

◈ Үзегез кунакка чакырылсагыз, билгеләнгән вакытыннан соңга калмагыз. Бара алмасагыз, алдан хәбәр бирегез.

◈ Мөмкин булганда үзегезгә тиешле кешеләр янына утырыгыз, мәҗлес һәм ашау әдәпләрен камил үтәгез. Ашлар хакында бәхәсләшмәгез, теләгәнегезне ашагыз, теләмәгәнегездән гаеп тапмагыз.

◈ Мәҗлес тәмам булгач, хуҗага рәхмәт әйтеп саубуллашып китегез.

◈ Чакырылмаган мәҗлесләргә бармагыз. Аш яки туй мәҗлесләрендә үз хәлегездән артык мал исраф итмәгез.

◈ Вакыт кадерле булганы өчен бер сәгатьтән артыкка сузылучы мәҗлесләргә бармагыз, башкаларның вакытларын исраф итә торган мәҗлесләрне үзегез дә ясамагыз.

◈ Кардәшләрегез һәм якын дусларыгыз килгәндә ачык йөз белән каршы алыгыз, үзләренә лаек булган урыннарга утыртып хәлләрен сорашыгыз, киткән вакытларында саубуллашып калыгыз. Әгәр

дә килүчеләр олы яшьтәгеләр булса рәхмәт әйтеп калыгыз.

❁ Үзегезнең хәлегезне белергә килгән кешеләргә «өйдә юк» дип хәбәр итмичә, ничек булса да үзегез каршы алырга тырышыгыз. Сезнең хәлегезне белергә килүчеләрнең үзләренә дә барып хәлләрен белегез.

❁ Язу, уку белән шөгыльләнгән вакытыгызда килүчеләр булса: «Гаепләмәсәгез, шөгылемне тәмам итәр идем», – дип рөхсәт сорап, әүвәл шөгылегезне бетерегез, соңра алар белән мәшгуль булыгыз.

❁ Йөз, кулларыгыз тузанлы, киемнәрегез керле булган хәлдә, шулай ук эш киемнәре белән һичкемнең хәлен белергә бармагыз, үзегезгә килүчеләргә дә каршы чыкмагыз.

❁ Хәлен белергә килгәч өй хуҗасына үзегезнең килгәнне белдерегез. Өч мәртәбә белдереп тә хәбәр булмаса кире кайтып китегез.

❁ Барган кешеләрегезнең өйдә юклыгы беленсә, килгәнегезне белдерү өчен язу язып калдырыгыз, барган җирегездә ишек ачык булса да рөхсәтсез өй эченә кермәгез.

❁ Кабул итсәләр хуҗага ачык йөз белән сәлам бирегез. Әгәр хуҗа башка бер кеше белән сөйләшеп торса яки башка төрле шөгыльдә булса, бер читтә көтеп торыгыз. Уку, язу белән шөгыльләнгән булса, нәрсә укыганын яки нәрсә язганын төпченмәгез.

❁ Хәл белергә барудан максат өй эчендәге нәрсәләрне тикшерү түгел, бәлки дуслык күрсәтүдер. Шуның өчен барган кешегезнең өен тикшермәгез, китапларын, язуларын актармагыз, үз исемегезгә булмаган язуларны кулыгызга да алмагыз.

❖ Берәүнең хәлен белергә бару гүзәл гадәт булса да, чиктән тыш күп бармагыз. Шәһәрләрдә иртәнге сәгать сигездән элек һәм кич сәгать тугыздан соң, шулай ук билгеле аш һәм чәй вакытларында барырга тырышмагыз.

❖ Төрле шөгыль ияләренә шөгыльләре вакытында бармагыз. Буш вакытларында барсагыз да яннарында озак утырмагыз.

❖ Вәгъдә биргән булсагыз вакытында барыгыз, көттермәгез, берәр төрле йомыш булу сәбәпле барырга туры килмәсә, бара алмавыгызны алдан хәбәр итегез.

❖ Читтәге дусларыгызга үз хәлегезне телефон яки хат аша белдерегез, үзегезгә шалтыратсалар яки язсалар җавап бирегез, җавап бирмәгән дуслар шелтәгә лаек.

## АВЫРУНЫҢ ХӘЛЕН БЕЛҮ

❖ Кардәшләрегезнең, дусларыгызның авырганлыкларын ишетсәгез, хәлләрен белергә барыгыз. Яннарына керү мөмкин булмаса, хәлен өйдә булганнардан сорагыз.

❖ Авыруга сәбәп булган нәрсәләрдән сакланмаганлыгы өчен авыруны шелтәләмәгез, бәлки мөмкин кадәр шикаятьләрен тыңлагыз, күңелен юатыгыз, сабырлыкка чакырыгыз, куркытмагыз, тиз көннәрдә тереләчәгенә өмет уятыгыз, сәламәтлеге өчен дога кылыгыз.

❖ Авыру янында озак утырмагыз, күңеленә авыр килә торган сүзләр сөйләмәгез.

## КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

❁ Кайгы килгән кешенең кайгысын җиңеләйтергә тырышыгыз, кайгыга сабыр итәргә өндәгез, сабыр итүчеләргә әҗер-саваплар вәгъдә иткән аять-хәдисләрне укыгыз.

❁ Якыннарыгыздан берәү вафат булса, гаиләсенә барып кайгы-хәсрәтләрен уртаклашыгыз.

❁ Мәетне юу, җеназасын уку, күмү кебек эшләрдә катнашыгыз.

❁ Кайгы уртаклашуны белдергәндә кайгылы булып күренегез, көлмәгез, шаяртмагыз һәм кайгыдан башка сүз сөйләмәгез. Кайгы билгесе булмаган һичбер эш эшләмәгез.

## КИЕМ ӘДӘПЛӘРЕ

❁ Кием кию турысында игътибарлы булыгыз. Кием киюдән максат салкын һәм кызулардан саклану, башкаларга күркәм күренүдер. Шуның өчен киемнәрегез шул максатларга туры килсен, артык мал исраф ителмәсен.

❁ Киемнәрегезне саклап киегез, өс-башыгызның тәрбиясез булуы ялкаулык һәм пычраклык галәмәтедер. Халыкка күркәм сыйфатта күренегез, күлмәк-ыштаннарыгызның чисталарын киегез, тир исе килмәсен. Гадәттә кырыла торган төкләрне тәндә йөртмәгез, чәч, мыекларыгызны зиннәтләп гомер уздырмагыз.

❁ Кыйммәтрәк булса да озак чыдый торган киемнәрне сайлагыз. Төсе матур булса да, ныклыгы чамалы булган киемнәрне сайлау дөнья гыйлеменнән хәбәрсезлек галәмәтедер.

❁ Модага бирелмәгез, аның хакында ишетергә дә теләмәгез, чөнки мода исерткеч яки отыш уеннары кебек бер бәладер.

❁ Кием кию турысында үзегезгә тиң булмаганнарга иярмәгез, хәлегезгә, дәрәҗәгезгә яки вакытына туры килми торган киемнәрне кимәгез.

❁ Хакыйкый камиллек киемдә түгел, шуның өчен аның белән мактанмагыз, башкаларның киеменә мәсхәрә күзе белән карамагыз. Халык алдында киемнәрегезгә карап тормагыз. Янә, күңеле кибәк булган кешенең тышы ефәк булуда бер мәгънә дә юк икәнен исегездән чыгармагыз.

❁ Бик тар яки бик киң киемне түгел, бәлки башны кызудан, аякларны салкыннан саклаучы киемнәрне сайлагыз.

* * *

Аллаһы Тәгалә әйткән:

*«Ий, адәм балалары! Без сезгә гаурәтләрегезне каплар өчен һәм зиннәт итеп киемнәр төшердек. Тәкъвалык киеме исә яхшырактыр».* Коръән аяте: (Әгьраф-26)

Мөхәммәд галәйһиссәләм әйткән:

*«Хатыннарга охшап киенүче ирләргә, һәм ирләргә охшап киенүче хатыннарга ләгънәт булсын».*

*«Ярымшәрә хатыннар җәннәткә керү түгел аның исен дә татымаячаклар».*

*«Кием кигәндә ошбу доганы укыгыз: «Әлхәмдү лилләһилләзи кәсәни һәзәс-сәүбә вә разәканиһи мин гайри хәүлин вәлә куввәтин».*Мәгънәсе: «Бу киемне миңа кидергән Аллаһы Тәгаләгә мактаулар булсын. Ул аны миңа бернинди көч-куәтсез бүләк итте».

*«Киемне салганда «Бисмилләһ», – дип әйтегез.*

## БИЗӘНҮ ӘДӘПЛӘРЕ

❁ Кызларга өйдә бизәнергә дөрес булса да, гомерегезне бизәнеп үткәрмәгез, потларга табынучылар кебек көзге тирәсендә бөтерелмәгез, хатынкызларның мәхәббәтлеләре иң тәрбияле булганнары икәнен беләсез бит.

❁ Әдәпсез хатыннар кебек йөзләрегезгә, ирennәрегезгә ак, кызыл буялар сөртмәгез, кашларыгызны йолкымагыз, каш һәм керфекләрегезне карага буямагыз.

❁ Беләкләрегезне, муеннарыгызны, күкрәкләрегезне ачык йөртмәгез, чәчләрегезне, аякларыгызны ялан хәлдә читләргә күрсәтмәгез, бу эшләргә мөбарәк динебезнең рөхсәте юк икәнен онытмагыз.

## СӨЙЛӘШҮ ӘДӘПЛӘРЕ

❁ Сөйләшкәндә артык кычкырмагыз, һәм артык акрын да сөйләшмәгез, тешләрегезне кысмагыз, бәлки гүзәл, кыска һәм ачык итеп сөйләгез. Телегез белән иреннәрегезне яламагыз, тешләрегез белән тырнакларыгызны кимермәгез.

❁ Адәм баласының күңелендә булган йомшаклык яки катылык кебек нәрсәләрне ачып бирүче, гыйлем, әдәп, мәгърифәт кебек нәрсәләрне күрсәтүче нәрсә телдер. Шуның өчен телегезнераслыктан башка нәрсә өчен кузгатмагыз, тәрбиясез сүзләр сөйләмәгез, белегез: кешенең сәламәтлеге – телен саклаудадыр.

❁ Арттырып сөйләмәгез, һичкайчан ялган һәм гайбәт сөйләмәгез, сүз йөртмәгез, белмәгән нәрсәләрне сөйләргә керешмәгез, бер кеше сүз башласа,

ахыры сезгә мәгълүм булса да, сүзе бетмәс борын ташлап китмәгез.

❁ Бер кешенең ялгыш сөйләвен белсәгез дә «ялгыш сөйлисең» яки «белмисең» димәгез, бәлки күңеленә авырлык килми торган итеп йомшаклык белән дөреслекне күрсәтегез.

❁ Үзегезнең ялгыш сөйләвегез беленсә, «ялгыштым» дип әйтүдән гарьләнмәгез. Сүзегезнең хаталыгы башкалар тарафыннан күрсәтелсә, ә сез аның хата түгеллеген белсәгез, кычкырышмыйча гына әдәп белән җавап бирегез. Сүзегезнең дөреслеген тавыш куәте яки ачу белән түгел, бәлки йомшаклык һәм дәлил куәте белән исбат итегез.

❁ Мәҗлесләрдә бер кеше хакында булган гайбәтне башкалардан күчереп булса да сөйләмәгез.

❁ Башкаларга сүз бирмичә үзегез генә сөйләп утырмагыз, күңелегезне тел артыннан түгел, бәлки телегезне күңел артыннан йөртегез, кешелеклелек сүздә түгел, бәлки эштә икәнлегеннән гафил булмагыз.

❁ Үзегездән олыларга мөрәҗәгать итәргә туры килсә «сез» кебек хөрмәт сүзләрен кулланыгыз, башкаларның сүзләрен яхшы аңламый торып «дөрес, шулай», яки «юк, алай түгел» димәгез.

❁ Үзегез, ата-баба, нәсел-ыру һәм остазларыгыз белән мактанмагыз. Кеше әгәр үзе камиллектән мәхрүм булса, башка тарафтан аңа камиллек килмәслеген яхшы белегез.

❁ Берәр нәрсә турында сорасалар, кәефегез булмаса да әдәпле итеп җавап бирегез. Сораган нәрсә кулыгызда яки күңелегездә булмаса гафу үтенеп гозер сорагыз, сүзегезне кабатлауны үтенүче булса, яңадан кайтарып сөйләгез. Шулай ук

үзегез дә аңламый калган нәрсәне йомшаклык белән генә кайтарып сорагыз.

❁ Әгәр үз фикерегезне әйтергә теләсәгез, иң элек мәсьәләне яхшы аңлагыз, шуннан соң гына керешегез, үз фикерегезгә үзегез үк хәйран калмагыз, ике сүзнең берендә ант итмәгез, чөнки үз фикереңә хәйран булу наданлык галәмәте, ант итеп «бу сүзне дөрес сөйлим» дию исә, ялганчылык галәмәтедер.

❁ Бер кешегә каршы сөйләргә мәҗбүр булсагыз «юк, алай түгел, болай» дип түгел, бәлки «сез сөйләгәнчә дә булыр, ләкин мин менә болай түгелме дип уйлыйм» кебек күңелле сүзләр кулланыгыз. Ачык белмәгән нәрсәгез хакында кеше белән тарткалашмагыз.

❁ Кирәк булмаганда кайгылы хәбәрләр сөйләмәгез, әдәпсез сүзләрне авызыгызга да алмагыз, амәнәт, сер сүзләрне фаш итмәгез, сер саклау акыллы кешеләр эшедер.

❁ Һичкемгә ләгънәт һәм бәддога кылмагыз, һичкемне сүкмәгез, һичкемгә ялган һәм гайбәт, боһтан сөйләмәгез, кешеләрне куркытмагыз. Өченче кеше алдында икегез яшерен сүз сөйләмәгез, усал эш артыннан йөрүчеләргә юл өйрәтмәгез, Аллаһы Тәгаләнең безгә бер тел ике колак бирүендә азрак сөйләп, күбрәк тыңларга кирәк икәнлегенә ишарә барлыгыннан гафил булмагыз.

* * *

Мөхәммәд галәйһиссәләм әйткән:

*«Сөйләсәң яхшы сүз сөйлә, булмаса тик тор».*

*«Эндәшмичә тик тору – галимнең зиннәте, наданның пәрдәседер».*

*«Бер-берегезгә күз кысышып сөйләшмәгез».*

*«Иманлы кеше тупас, әшәке телле, әхлаксыз һәм азгын кеше булырга тиеш түгел».*

*«Кешеләр белән бәхәсләшмә, синең белән начар мөгамәлә итүчеләргә игелекле бул, синең файдаңа булмаса да дөресен сөйлә».*

Дүрт төрле эшне эшләү яхшы булыр: аралашсаң – кешеләрнең иң яхшысы белән аралаш; сөйләсәң – иң яхшы сүз сөйлә; әгәр сиңа сүз әйтелсә – иң күркәм тыңлау рәвеше белән тыңла; әгәр вәгъдә бирсәң – аны иң күркәм рәвештә үтә; акылсыз кеше белән сөйләшкәндә мәзәк сөйләүдән тыел; шулай ук, хаклыкка аркасы белән борылган кеше белән сөйләшүеңне, әдәп-тәрбиясе булмаган кеше белән аралашуыңны, һәм соңыннан үкенерлек булган сүз һәм эшләреңне калдыр.

## ХӘРӘКӘТЛӘНҮ ӘДӘПЛӘРЕ

❁ Кагыйдәсен белеп хәрәкәтләнү, күнегүләр ясау фикерне уята, кан йөрешенә ярдәм бирә, буыннарны ныгыта, теләкне ача, зиһенне арттыра, уй-фикергә куәт бирә. Шуның өчен авылда булган вакытыгызда йорт һәм кыр эшләрен эшләгез, атларга менеп йөрегез, суда йөзегез, кул, аяк һәм башка әгъзаларыгызны хәрәкәтсез тотмагыз. Шәһәрдә булганда сирәк кенә булса да бакчаларга барыгыз, тау өсләренә чыгыгыз, су буйларында, яшел үлән өсләрендә, урман буйларында йөрегез, саф һава иснәгез.

❁ Физик күнегүләр ясаганнан соң су эчмәгез, бер-ике сәгать вакыт үтми торып ашамагыз, ашаган ашыгыз сеңми торып күнегүләргә керешмәгез. Физик күнегүләр өчен саф һавалы җирләрне сайлагыз.

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

***Бисмилләәһи-р-рахмәәни-р-рахиим***

# ДИН ӘДӘПЛӘРЕ

Галәмнәрне тәрбия кылучы Аллаһы Тәгаләгә барча мактау, дан һәм хөрмәт булсын!

Барлык галәмгә рәхмәт итеп җибәрелгән, үзенең тормышы белән безгә күркәм үрнәк булган, сабырлык белән саф, гадел гомер кичергән, башкаларның күңелләрендә изгелек, мәрхәмәтлелек уята белгән Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләмгә Аллаһының рәхмәте һәм сәламе булсын!

Дин – ул бу дөньядагы иң изге сыйфатларны сугаручы илаһи бер чишмә. Аллаһы Тәгалә Үзенең динен аерым бер кешенең яки аерым бер гаиләнең, яисә аерым бер җәмгыятьнең генә тормышын төзәтер өчен түгел, бәлки, барлык халыкларның юлын яктыртучы нур итеп, аларны караңгылыктан яктылыкка чыгару өчен җибәргән.

Мондый җитәкчелек астында кешенең тормышы, әлбәттә, искиткеч матур булачак. Ләкин, моңа ирешер өчен, Исламның якты сурәте тасвирланган хакыйкый мөселманны тәрбияләргә кирәк. Нәтиҗәдә андый тәрбия алган мөселман Аллаһы Тәгалә һәм Аның Илчесе Мөхәммәд галәйһиссәләмгә буйсынып яши, тәрбияле, ихлас күңелле һәм үзенең ата-анасына итагатьле була;

- ул үзенең көнен Аллаһыга мактаулар әйтеп башлый һәм тәмам кыла;
- кылган гөнаһлары өчен тәүбә кылып, Аллаһыдан үзен гафу итүен сорый;

❁ аның йөрәгендә беркемгә карата ачу да, көнчелек һәм үч алу хисләре дә булмый;

❁ ятим-мескеннәргә һәм зәгыйфьләргә карата рәхим-шәфкатьле, мәрхәмәтле була. Олыларны хөрмәт итә, кечкенәләргә карата миһербанлы була;

❁ үзен җәберләгән кешеләрне, кыерсытучыларны гафу итә, үзе белән араны өзүчеләр белән дә элемтәне югалтмаска тырыша;

❁ мохтаҗлыкта калса – кайгырмый, бәлки, Аллаһыга шөкер итә. Баеп китсә – тәкәбберләнми, мохтаҗларны кызгана белә;

❁ ул үзе яшәгән җәмгыятьнең ихлас, тугры һәм файдалы бер әгъзасы булып тора;

❁ анда игелек һәм ышаныч билгеләре нык булганга күрә, башкалар аңа тулысынча ышаналар;

❁ һәрбер гамәле белән ул җәмгыятькә файда гына китерергә тырыша, шуның белән ул кешеләрнең күңелләрендә өмет уята һәм тынычлык тудыра.

Ислам дине Аллаһы Тәгаләгә ихлас күңелдән ышануны, һәрдаим Аны зикер итеп, Аның белән нык элемтәдә торуны, тулаем Аңа тапшырылуны һәм фәкать Үзеннән генә ярдәм сорауны таләп итә. Бу нәрсә мөселман кешегә һәрвакыт Аллаһының көч-кодрәте, ярдәме һәм терәген тоеп яшәргә тиешлеген белдерә.

Хакыйкый мөселман, күңеленең халәте нинди булуга карамастан, Аллаһы Тәгалә һәм Рәсүлебез Мөхәммәд галәйһиссәләмнең кушкан барлык әмерләренә тулаем буйсынып яши. Димәк, хакыйкый мөселманның тормышын Аллаһының җитәкчелегеннән һәм Рәсүле Мөхәммәд галәйһиссәләмнең юлыннан башка күз алдына да китерү мөмкин түгел.

❁ Һәр нәрсәне бар иткән һәм безне гүзәл сурәттә яралтып акыл нигъмәтен биргән мәрхәмәтле Аллаһы Тәгаләгә чын күңелдән иман китерегез, Аның боерыкларын җиренә җиткереп башкарырга тырышыгыз. Аңа гыйбадәт кылыгыз.

❁ Гыйбәдат кылу көне буе намаз уку, ураза тоту яки бөтен эшләрне бер якка куеп мәчетләрдә яту түгел, бәлки Аллаһы Тәгалә боерган бурычларны өстән төшерү, кешеләр белән күркәм мөгамәләдә булу, рәхим-шәфкатьле булу һәм гөнаһ эшләрдән сакланудыр.

❁ Рәсүлебез Мөхәммәд галәйһиссәләм китергән ислам шәригатенә үз белдегегез белән бер хәреф тә арттырмагыз һәм бер хәрефен дә киметмәгез, бәхет-сәгадәт шәригатьтәдер, моны һәрвакыт хәтерегездә тотыгыз.

❁ Киемнәрегезне, тәннәрегезне кер һәм пычрактан тазартканыгыз кебек, күңелләрегезне дә, алдау, көнчелек, ачу, золым кебек начар нәрсәләрдән пакьләгез.

❁ Аллаһы Тәгаләгә шөкер итү һәм Аллаһы Тәгаләнең ихлас бәндәләре белән бергә җыелып дуслык булдыру нияте белән намазларны мөмкин кадәр җәмәгать белән укыгыз. Ураза тотудан булган максатыгыз нәфесне тәрбия итү, сабырга гадәтләндерү, фәкыйрь һәм мескеннәрнең хәленә керә белү булсын. Малыгыздан зәкят биргәндә юмартлыкка гадәтләнү, саранлык кебек бозык холыклардан нәфесне пакьләү, фәкыйрьләрне шатландыру булсын. Хаҗ кылган вакытта максатыгыз мөселманнар белән танышу, мәшәкатьләргә сабыр итү, сәяхәт итеп гыйбрәт алу булсын.

❁ Пәйгамбәрләр халыкларны хак юлга чакыру өчен Аллаһы Тәгалә тарафыннан җибәрелгәннәр.

Шуның өчен аларның барысын да чын күңелдән сөегез.

❁ Әҗер-савап һәм газаплар, файда һәм зарарларны, кылган гамәлләрегезгә булачак бүләк, җәзаларны безгә һәрвакыт хәбәр биреп торучы юл күрсәтүчебез Коръән Кәримнең хак һәм мөбарәк китап икәнлегенә нык ышаныгыз.

❁ Дөньяның иң авыр сәгате булган үлем исереклеге вакытындагы кыенлыкларны җиңеләйтүче Ислам динебезгә азау тешләрегез белән ябышып һәрбер сүзегез һәм эшегез белән Аллаһы Тәгаләгә тәкъвалык үзәрендә булыгыз.

❁ Ахирәт өлешләреннән мәхрүм калуны теләмәсәгез изге бәндәләр йөргән юлларда йөрегез, бозык кешеләргә дус булмагыз, Аллаһы Тәгалә риза булмаган эшләрне эшләмәгез.

❁ Мәчеткә кергәндә әдәп белән керегез, мәчетнең хөрмәтен җибәрә торган нәрсәләрдән сакланыгыз.

❁ Эшләрегезнең хәерле булуын, дин һәм дөнья кирәкләрен, бигрәк тә дөньядан иман белән китүне Аллаһы Тәгаләдән ялварып сорагыз.

❁ Бөтен хаҗәтләрегезне Аллаһының туры үзеннән сорагыз. Аллаһы Тәгалә белән ике арага үлек һәм терекләрдән һичкемне куймагыз, нәзер әйтмәгез. Фәлән шәех хөрмәтенә дип сораудан бик нык сакланыгыз, һичкемнең бәхетле яки бәхетсез булуы белән гуаһлык бирмәгез.

❁ Үз иманнарыгызны һәм гамәлләрегезне Мөхәммәд галәйһиссәләм юлына муафикъ итәргә тырышыгыз, һичкемне «кяфер» дип сөйләмәгез, телегезне мондый сүзләргә гадәтләндермәгез.

❁ Аллаһының боерганнарын үтәгез, тыйган эшләреннән ерак йөрегез, галимнәрне тыңлагыз һәм

күңелегезне һәрвакыт төзек тотыгыз. Күңел төзек булса бөтен тән төзек булыр.

❁ Коръән укылганда мәгънәсен белмәсәгез дә Аллаһының сүзләре дип олылап тыңлагыз, үзегез дә укырга өйрәнегез. Картлыгыгыздан элек яшьлекнең, авырудан элек сәламәтлекнең, фәкыйрьлектән элек байлыкның, шөгыльдән элек иркенлекнең, вафат булудан элек яшәүнең кадерен белегез.

## ИМАН НИГЕЗЛӘРЕ

Иманның алты нигезе бар:

❁ Синең Аллаһыга, Аның барлыгына һәм берлегенә, бердәнбер гыйбадәт кылырга лаеклылыгына һәм бөтен галәмнәрнең тәрбиячесе булуына ихтыяри рәвештә иман китерүең.

❁ Аның фәрештәләренә ышану. Алар нурдан яралтылган, Аллаһының кушканнарын һич карышмастан үтәүче һәм гөнаһ кылудан пакь затлар.

❁ Аның Тәүрат, Зәбур, Инҗил һәм Коръән кебек изге китапларына ышану.

❁ Аның илчеләренә ышану. Алар Аллаһы Тәгаләнең динен халыкларга ирештерүче изге кешеләр.

❁ Ахирәт көненә ышану. Бу көнне бәндәләр дөньялыкта кылган яхшы яки яман гамәлләре өчен Аллаһ алдында хисап тоталар һәм тиешле бүләк яки җәза алалар.

❁ Тәкъдирнең изгесе дә яманы да Аллаһы Тәгаләдән икәнлеккә иман китерү. Тәкъдирнең изгесен дә яманын да берсүзсез кабул итәргә кирәк, чөнки алар барысы да Аллаһ тарафыннан алдан билгеләнә.

## ИМАН КӘЛИМӘЛӘРЕ

Мөхәммәд галәйһиссәләм: «Иманнарыгызны һәрвакыт яңартып торыгыз», – дип әйтә торган булган. Иманнарны яңартып тору исә түбәндәге иман кәлимәләрен һәркөнне бер мәртәбә булса да уку белән була.

♦ Кәлимәтүн таййибәһ: *Ләә иләәһә илләллааһү, Мухәммәдүр-расүүлүллааһ.*

♦ Кәлимәтү-ш-шәһәәдәһ: *Әшһәдү әлләә иләәһә илләллааһү вә әшһәдү әннә Мухәммәдән габдүһүү вә расүүлүһ.*

♦ Кәлимәтү-т-тәүхид: *Әшһәдү әлләә иләәһә илләллааһү вәхдәһүү ләә шәриикә ләһ. Ләһү-л-мүлкү вә ләһү-л-хәмду йүхьии вә йүмиит. Вә һүә хәййүлләә йәмүүт. Бийәдиһи-л-хайру вә һүә галәә күлли шәй-иң кадиир.*

♦ Кәлимәтү радди-л-күфр: *Әллааһүммә инниии әгуузү бикә мин ән үшрикә бикә шәй-ән вә әнә әгъләм. Вә әстәгъфирукә лимәә ләә әгъләм. Иннәкә әнтә галләәму-л-гуйүүб.*

♦ Кәлимәтү-л-истигъфәр: *Әстәгъфируллааһ, әстәгъфируллааһ, әстәгъфируллааһә тәгааләә мин күлли зәнбин әзнәбтүһүү гамдән әү хата-ән, сирран әү галәәнийәһ. Вә әтүүбү иләйһи минә-з-зәнбилләзии әгъләму вә минә-з-зәнбилләзии ләә әгъләм. Иннәкә әнтә галләәму-л-гуйүүб.*

♦ Кәлимәтү-т-тәмҗид: *Субхәәнәллааһи вә-л-хәмдү лилләәһи вә ләә иләәһә илләллааһү вәллааһү әкбәр. Ләә хәүлә вә ләә куввәтә илләә билләәһи-л-галиййи-л-газыйиим. Мәә шәә-әллааһү кәәнә вә мәә ләм йәшәә ләм йәкүн.*

❁ Әл-иимәну: *икъраарун би-л-лисәәни вә тәсъдиикун би-л-кальби бимәә җәә-ә биһии мин гыйндилләәһи Мухәммәдур-расуулуллааһ. Салләллааһу галәйһи вә сәлләм.*

❁ Имәәнүн мүҗмәл: *Әәмәнту билләәһи кәмәә һүә би әсмәә-иһи вә сыйфәәтиһии вә кабилту җәмига әхкәәмиһ.*

❁ Имәәнүн мүфәссаль: *Әәмәнту билләәһи вә мәләә-икәтиһии вә кутубиһии вә русулиһии вә-л-йәуми-л-әәхыйри вә-л-кадәри хайриһии вә шәрриһии минәллааһи тәгааләә вә-л-бәгъси бәгъдә-л-мәүүт.*

## ИСЛАМ НИГЕЗЛӘРЕ

Ислам биш нигезгә корылган:

❁ Аллаһы Тәгаләдән башка һичбер илаһ юк, һәм Мөхәммәд галәйһиссәләм – Аллаһының илчесе дип шәһадәт (гуаһлык) биру.

❁ Намаз уку: намаз вакытында аның барлык шартларын һәм тиешле гамәлләрен тирән ихтирам һәм басынкылык белән башкару.

❁ Зәкят түләү: зәкят мөселман кешенең 85 грамм алтын бәрабәрендә акчасы булганда түләнә. Зәкят агымдагы бер ел үткәч шул бәянең 2,5%ы күләмендә түләнә. Шулай ук башка төрле мал-мөлкәтнең дә зәкят күләмнәре билгеләнгән.

❁ Рамазан аенда ураза тоту: таң атканнан алып кояш баеганга кадәр азык-төлек, эчемлектән һәм башка тыелган чаралардан тыелып тору.

❁ Юлга көче җиткән һәр кешенең Мәккәгә хаж кылуы.

Ислам нигезләре кешенең хис-тойгыларына охшаган. Әгәр бер кеше үзенең хис-тойгыларын югалтса, ул үлгән кешегә охшап кала. Кеше әлеге хис-тойгылардан башка яши алмаган кебек, Ислам да үзенең нигезен тәшкил итүче терәкләреннән башка яшәми. Шуңа күрә үзен мөселман санаган һәр кеше бу терәкләрне күтәрергә һәм шуның белән Исламның тулылыгын, бөтенлеген сакларга бурычлы. Сәламәт йөрәкле чын мөселман булу өчен Ислам терәкләре нигезендә яшәргә кирәк.

## ШӘҺАДӘТ КӘЛИМӘЛӘРЕ

Исламны биек диварлары белән югарыга, күккә омтылган мәһабәт бина белән чагыштырырга мөмкин. Әлеге бинага ныклык биреп, аны тотып торучы терәк-баганалары булган кебек, Исламның да нигезен тәшкил итүче баганалары бар. Шуларның иң беренчесе һәм иң әһәмиятлесе: *«Ләә иләәһә илләллааһ,Мөхәммәдур-расүлуллааһ»* кәлимәсе.

Мәгънәсе: «Аллаһы Тәгаләдән башка һичбер илаһ юк һәм Мөхәммәд галәйһиссәләм – Аллаһ тарафыннан динне кешеләргә җиткерүче илчедер».

Бу нигез башкалары арасында иң мөһиме. Әгәр бер кеше ярдәм сорап Аллаһыга түгел, ә һәртөрле изгеләргә мөрәҗәгать итә икән, ул вакытта аның кылган изге гамәлләре аңа һич файда китермәс, чөнки кемне дә булса Аллаһы Тәгаләгә тиңләштерү теләсә нинди тырышлыкның нәтиҗәсен юкка чыгара. Аллаһы Тәгалә әйткән:

*«Әгәр син Аллаһы Тәгаләгә кемне дә булса тиң күрсәң, хак, синең тырышлыгың юкка чыгар, һәм әлбәттә, син зарар күрерсең».* Коръән аяте.(Зүмәр - 65)

Менә шуның өчен барлык пәйгамбәрләр дә

беренче нәүбәттә шул *«Ләә иләәһә илләллааһ»* кәлимәсен халыкларга җиткерергә тырышканнар, чөнки ул Аллаһыга гына баш иярргә, Аңа гына гыйбадәт кылырга чакыра, Аллаһ бөтен кешелекне шуның өчен яралткан да.

Мөхәммәд галәйһиссәләмнең Аллаһ тарафыннан җибәрелүенә һәм аның безгә җиткергән барлык сүзләренә ышанырга кирәк. Аның кушканнарына буйсынырга һәм ул тыйган нәрсәләрдән тыелырга кирәк. Пәйгамбәр галәйһиссәләмгә иман китерү Аллаһы Тәгаләнең чакыруына җавап бирүдә күренә.

## НАМАЗ

Чын мөселман биш вакыт намазны билгеләнгән вакытларында үти. Чөнки намаз – диннең терәге. Шул терәкне ныгытучы кеше диннең үзен дә ныгыта, ә киресенчә булса, динне җимерә. Намаз – бик мөһим һәм мәртәбәле эш. Намаз – ул Аллаһ һәм Аның колы арасын бәйләүче бер җеп булып тора. Намазга керешкән кеше барлык дөнья эшләрен ташлап, бөтен барлыгы белән үзенең Раббысына омтыла. Шул вакытта ул Аллаһыдан үзен туры юлга күндерүне, үзенә ярдәм итүне, һәрбер эштә Аның җитәкчелек итүен сорый. Чишмә суында юынып пакьләнгән кебек, намаз укучы да намаз укуы белән үзенең гөнаһларын юа, иманын ныгыта.

Мөхәммәд галәйһиссәләм намазларны даими рәвештә җәмәгать белән укучыларны җәннәт белән сөендереп болай дигән: *«Мәчеткә баручыга һәм аннан кайтучыга Аллаһы Тәгалә җәннәттә ризык әзерләп куяр»*.

Хак мөселман намазларын җиренә җиткереп укырга тырыша. Намазда төрле хәрәкәтләр ясау, намаздан тыш башка нәрсәләр турында уйлап намаз уку чын мөселманга хас нәрсәләр түгел.

Намазын тәмамлаганнан соң да ул тиз генә сикереп тормый, бәлки, зикер-тәсбихләр, салаватлар әйтеп, Аллаһы Тәгаләгә догалар кыла. Ихлас күңеленнән Хак Тәгаләдән дөньяда да, ахирәттә дә нигъмәтләрен бирүен, адаштырмыйча, дөрес, туры юлдан алып баруын сорый.

Менә шундый намаз – кешенең күңелен тулысынча пакьләндерүче гамәл булып тора, калебен йомшарта. Әгәр кешеләр үзләренең намазларын ихласлык һәм сабырлык белән укысалар, алар турыдан-туры Аллаһының ярдәмен һәм яклавын табарлар, бәла-каза килсә – кайгырмаслар, ризык-нигъмәтләр ирешсә – тәкәбберләнмәсләр.

## ЗӘКЯТ

Аллаһыдан куркып, намазларын ихластан үтәүче кеше, булган малы хисабыннан чыгып, зәкятен дә түли. Шул вакытта аның башында зәкятнең бер өлешен генә булса да бирмәскә дигән фикер тумый. Чөнки зәкят түләү – мөселман кеше өчен Аллаһы Тәгалә тарафыннан билгеләнеп куелган олы фарызларның берседер. Шуны белгән кеше һичкайчан шәригать хөкемен бозу, Хак Тәгаләнең сүзенә карышу юлына баса алмый. Фәкать дини хисләре саеккан, калебе пычранган, әдәп-әхлак төшенчәләреннән ерак торучы мөселманның гына зәкят түләү мәсьәләсендә карышып, тарткалашып торуы мөмкин.

Намаз һәм зәкятнең бер-берсенә бәйләнеп, Ислам диненең терәкләре булып торуын һәм Коръәндә килгән аятьләр аша аларның бербөтен булуын күрергә мөмкин.

## УРАЗА

Чын мөселман ихласлык белән һәм Аллаһыдан әҗерен өмет итеп, Рамазан аенда фарыз уразасын тота, һәм ул үзенең йөрәгендә гөнаһларының гафу ителүенә һәрвакыт ышаныч саклый.

Мөхәммәд галәйһиссәләм әйткән:

*«Аллаһының әҗер-савапларын өмет итеп, Рамазан аенда ураза тотучының үткәндәге барлык гөнаһлары гафу ителәчәк».*

Һәрбер мөселман ураза тотканда үзенең телен, күзләрен һәм башка әгъзаларын Аллаһы Тәгалә тыйган нәрсәләрдән сакламаса, аның барлык әҗер-саваплары җилгә очачагын һәм тоткан уразасы бушка булачагын белеп тора.

Мөхәммәд галәйһиссәләм әйткән:

*«Ураза тотучы кеше начар сүзләр әйтмәсен һәм кычкырышмасын. Әгәр аны берәү сүксә, яки әйткәләшергә сәбәп эзләсә: "Мин ураза!"– дип әйтсен».*

*«Әгәр бер кеше ялган сөйләүдән һәм ялган белән гамәл кылудан туктамаса, Аллаһы Тәгалә каршында аның ашамый, эчми торуында файда юк».*

Димәк, акыллы, игътибарлы мөселман бу мөбарәк Рамазан аеның һәрбер мизгелен игелек белән үткәрергә тырыша: ул көндезләрен уразада булып, Коръән укып, сәдакалар өләшеп һәм башка төрле шундый изге гамәлләр белән үткәрсә, кичләрен өстәмә намазлар укып, Аллаһыга догалар кыла.

# ХАҖ

Динендә ихлас булган мөселман кеше, мөмкинлеге булу белән, Кәгъбәтуллага барып, хаҗ кыла. Хаҗы дөрес һәм тулы булсын өчен, ул, хаҗга барыр алдыннан, аның барлык тәртипләрен дә җентекләп өйрәнә. Хаҗ кылып өенә, гаиләсе янына әйләнеп кайтканда, гөнаһларыннан чистарынып, үзен яңа туган бала кебек хис итә.

# НИЯТ

Һәрбер гамәлнең нәтиҗәсе – кирәк тән гамәле, кирәк тел гамәле булсын, кирәк аз, кирәк күп булсын – нияткә карап була. Шуңа күрә, әгәр ният төзек булса, гамәл дә төзек була, бозык булса, гамәл дә бозык була.

Нияткә карап, бер гамәл өчен бик күп савап яки бик күп гөнаһ язылырга мөмкин. Яхшы ният белән хәрам эшне эшләргә ярамаган кебек, ният бозык булуны сылтау итеп, фарыз гамәлләрне дә калдырырга ярамый.

Мөхәммәд галәйһиссәләм әйткән:

*«Гамәлләр нияткә карап була һәм һәр кешенең гамәле бәрабәренә булган өлеше ниятенә карата була».*

Хакыйкый мөселман, нәрсә генә эшләсә дә, фәкать Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы өчен дип эшли, хәтта аның Аллаһ ризалыгы өчен дип эшләгән эшләре кайбер кешеләрнең ачуларын чыгарса да.

Мөхәммәд галәйһиссәләм әйткән:

*«Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы өчен дип йөрүе белән кешеләрнең ачуын чыгаручы бәндәне Аллаһы Тәгалә Үзе яклый һәм саклый. Кешеләргә ярарга*

*тырышып, Аллаһының ачуын чыгаручыны исә, Хак Тәгалә шул кешеләрнең хөкеменә тапшыра».*

Шуның өчен мөселман кеше барлык гамәлләрен дә Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы өчен генә үти. Әгәр берәр төрле эш Аллаһының ачуын чыгара торган булса, ул аны һичкайчан эшләми. Ул бервакытта да үзенә каршы эш кылмый. Син аны бер гамәлендә Аллаһыга буйсынган хәлдә, ә икенчесендә тәкәбберләнеп баш тартучы итеп һичкайчан күрмәячәксең.

Әгәр син бер кешене мәчеттә намаз укыганын күреп тә, урамда, өендә, мәктәптә яки башка урыннарда шәригать кануннарыннан тайпылып яшәвен, шулай ук үзенең балалары, туганнары белән тиешле рәвештә мөгамәлә кылмавын күрсәң, белеп тор: бу кеше Аллаһының хак юлын тулысынча аңлап бетермәгән, яки аны аңларга теләмәгән.

Дини өйрәтмәләрне яхшы үзләштергән һәм аның күрсәтмәләрен кабул иткән чын мөселман Аллаһының изгелеге, рәхимлелеге хакына эчкерсез булырга тырыша, һәм үзенең гамәлләрен күрсәтер өчен генә эшләүдән ерак тора.

## ДӘГЪВАТ

Гыйбадәтнең асылын дөрес аңлаучы кеше аны башкаларга да җиткермичә булдыра алмый. Аллаһының нурын бөтен җиргә җиткерер өчен ул үзенең бөтен көче белән тырыша. Ул үзенә Ислам чакыруларын тормышка ашыруны максаты итеп куя.

Юлдан язган кешегә чын күңелдән әйтелгән һәр яхшы сүз өчен бирелгән әҗер-савапка, өндәүченең чакыруы белән туры юлга керүчеләргә бирелгән әҗер-саваплар да өстәләчәк.

Аллаһ юлына өндәүчеләрнең хәлләренә чыннан да көнләшерлек. Алар бит үзләренең күпме вакытларын, байлыкларын хак юлдан тайпылучыларны туры юлга өндәүгә багышлыйлар.

Кешеләрне Аллаһ юлына чакыручы кеше үзенең гыйлемен азга санамасын. Чөнки аннан бары тик үзенә билгеле булган хакыйкатьне генә башкаларга җиткерү таләп ителә.

Кешеләрдә шәригать кушканнарны үтәүгә теләк уяту һәм ярамаган эшләр өчен аларга җитди кисәтүләр ясау – Аллаһ юлына өндәүне тормышка ашырудагы иң кирәкле шартларның берсе булып тора. Мөхәммәд галәйһиссәләм әйткән:

*«Әгәр сез нинди дә булса ярамаган эшне күрсәгез, аны кулларыгыз белән төзәтегез; әгәр кулларыгыз белән булдыра алмасагыз – телегез белән; әгәр инде моны да эшли алмасагыз йөрәгегез белән аның яхшы якка үзгәрүен теләгез. Ләкин инде монысы иманның көчсезлеген белдерә».*

*«Урамнарда утырып торудан сакланыгыз. Әгәр утырырсагыз, юлларда утыру әдәпләрен үтәгез: тиешсез нәрсәләргә карамагыз, йөрүчеләргә комачауламагыз, сәлам кайтарыгыз, яхшы эшләргә боерыгыз һәм яман эшләрдән тыегыз».*

Ислам динен тотучы мөселман билгесезлектән, сүлпәнлектән һәм салкын караштан ерак тора. Ул бервакытта да дини эшләрне әһәмиятсез нәрсәләр дип санамый, кешеләрдә хак эшләргә теләк уятудан баш тартмый, тыелган эшләрне яратмый, һәм аларның эшләнүенә дә юл куймый, чөнки дингә кагылышлы һәрбер мәсьәлә җитди санала, һәм монда шаярулар урынлы түгел. Дини кануннар тәвәккәллекне таләп итә, ташламалар ясауны кабул итми.

Исламга өндәүче мөселман башкаларга хикмәт белән үгет-нәсыйхәтләр бирә.

Аллаһы Тәгалә әйткән:

*«Раббың Аллаһ юлына хикмәт һәм яхшы үгет-нәсыйхәтләр белән чакыр».* Коръән аяте: (Нәмел – 125).

Димәк, Аллаһ юлына чакыручы кеше, иң беренче чиратта кешеләрдә дингә мәхәббәт тәрбияләп, аларны читкә этәрүче, үпкәләтүче һәм ачу кузгатучы нәрсәләрдән сакланып, йөрәкләргә дөрес юл таба. Ул барлык белгәннәрен берьюлы сөйләми, бәлки аларның йөрәкләрендә нәрсә барлыгын ачыклагач, бөтен нәрсәне тәртибе белән өйрәтә. Ул үзе өндәгән кешеләргә карата сабырлыгын югалтмый. Сорауларга мөмкин кадәр тулы һәм йомшак итеп җавап бирә, аларга остаз, дус кебек мөгамәләдә була һәм алар үзләрен кызыксындырган нәрсәләрнең асылына төшенгәнче аларга аңлатуын дәвам итә.

## КОРЪӘН

Югарыда әйтелгән бөек сыйфатларга ирешү өчен мөселман кеше бертуктаусыз Коръән Кәрим чишмәсеннән сугарылып тора. Коръән аятьләре аның йөрәгенә үтеп кереп, күңеленә иман һәм тынычлык иңдерә.

Мөхәммәд галәйһиссәләм әйткән:

*«Сезнең яхшыларыгыз – үзе Коръәнне өйрәнеп, аны башкаларга да өйрәтүчегездер».*

Коръәнне укучы кеше үзен Коръән уку әдәпләре белән зиннәтләргә тиеш, чөнки ул Аллаһы Тәгаләнең сүзләре. Кулына Коръән Кәримне алып укучы кеше камил тәһарәтле, пакь киемдә, хуш исләнгән һәм игътибарлы булырга тиеш. Мәгънәләрен

фикерләп, эчендәге һәртөрле хөкемнәр, вакыйгалар һәм вәгазьләр белән тәэсирләнүе, шатлык аятьләре килгәндә йөзе ялтырып, үзе дә югары дәрәҗәләргә омтылуы, куркыту аятьләре килгәндә йөзенә Аллаһы Тәгаләдән курку әсәрләре чыгып, түбән дәрәҗәләрдән саклануы кирәк.

Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтен өмет итеп, газабыннан курыккан хәлдә укылган Коръән Кәрим генә үзен укучыга файда бирә. Шул вакытта аның иманы арта һәм барча эшләре төзек була.

Аллаһы Тәгалә әйткән:

*«Хак мөэминнәр шулар: кайчан Аллаһы Тәгалә искә алынса, аларның йөрәкләре калтырар, кайчан аларга Аллаһы Тәгаләнең аятьләре укылса, ул аларга иманнарын арттырыр һәм алар үзләренең Раббыларына тәвәккәл кылалар».* Коръән аяте:(Әнфәл-2)

* * *

Коръәнне күтәреп йөрүчеләр өчкә бүленәләр: беренчесе – аны мал кебек күтәреп йөрүче кеше; ул аны шәһәрдән шәһәргә кешеләрдән акча алыр өчен йөртә. Икенчесе – аның һәр хәрефен ятлаган, әмма хаклык чикләрен оныткан кеше; ул аның белән идарәче хакимнең күңелен яулап алу һәм кешеләр алдында үзен өстен тоту өчен өйрәнгән. Өченчесе – Коръәндә ни барын өйрәнеп, ятлап, шуның белән гамәл кылып, Аллаһыга гыйбадәт кылган кеше. Менә шуларның өченчесе – Коръәнне күтәреп йөрүчеләрнең иң хәерлеседер.

بِسْمِ اللّٰهِ الرَّحْمَٰنِ الرَّحِيمِ

*Бисмилләhи-р-рахмәни-р-рахим*

# ГЫЙБАДӘТ КИТАБЫ

## ТӘҺАРӘТ АЛУ ТӘРТИБЕ

Күңелеңнән тәһарәт алуны ниятлә: *«Бисмилләhи-р-рахмәни-р-рахим. Иләhи ният кылдым тәhарәт алмакка халисан лилләhи Тәгалә»*.

Өчәр мәртәбә кулларыңны ю.

Өчәр мәртәбә авыз-борыныңны чайка.

Өчәр мәртәбә битеңне ю.

Кулларыңны терсәккә кадәр өчәр мәртәбә ю.

Кулларыңны юешләп, башыңа һәм колакларыңа бер мәртәбә мәсих кыл.

Уңнан башлап, өчәр мәртәбә аякларыңны ашык сөягенә кадәр ю.

## ТӘҺАРӘТНЕ БОЗА ТОРГАН НӘРСӘЛӘР

Тәһарәтне сигез төрле эш боза:

1. гаурәттән нәҗес, яки мәзи белән вәди бүленеп чыгу;
2. җәрәхәттән кан, эрен яки сары су агу;
3. борын канау;
4. күздән лайлалы яшь агу;
5. авыз тутырып косу;
6. ятып яки сөялеп йоклау;
7. акылын югалткан, тилергән, аңын югалткан, яки көчле дару тәэсире астында булган очракта;
8. намаз эчендә тавыш белән көлү.

# ГОСЕЛ

Госел билгеле бер тәртиптә бөтен тәнне су белән юуны аңлата. Госелсезләргә намаз уку, Коръәнгә кагылу һәм мәчеттә булу тыела.

Госел фарыз була торган сәбәпләр өч:

1. Җөнеб булу: а) алгы як юлыннан юеш килү; б) җенси якынлык кылу; в) төшләнү.
2. Хәез каны тәмам булу.
3. Нифас каны тәмам булу.

# ГОСЕЛ АЛУ ТӘРТИБЕ

Госелләнергә ниятләгән кеше түбәндәге тәртип буенча эш йөртер:

1. Гаурәтләрен пакьләр.
2. Беләзекләренә кадәр ике кулын юар.
3. Тәһарәт алыр, ләкин аякларын юмас.
4. Госелгә ният кылыр.
5. Авызын өч мәртәбә чайкар.
6. Борынына өч мәртәбә су алып чайкар.
7. Әүвәл башына, аннан соң уңнан башлап ике як иң өстенә, алгы якка, аркага, уң яктан башлап ике як ботка су йөгертер. Бер кат су йөгерткәч, тәненең һәрбер җирен мөмкин кадәр куллары белән ышкып чыгар.
8. Шул тәртиптә икенче мәртәбә бөтен тәненә су кояр. Тәненең һәрбер җирен янә куллары белән ышкып чыгар.
9. Билгеле тәртип белән өченче мәртәбә бөтен тәненә су кояр. Су йөгерткән урыннарны куллары белән янә мөмкин кадәр ышкып чыгар.
10. Иң ахырда уңнан башлап ике аягын юар.

# НАМАЗ УКУ

## АЗАН

Азан – түбәндәге сүзләр ярдәмендә биш вакыт намазга чакырудыр. Азан кычкырып һәм сузып әйтелә:

*«Әллааһү әкбәр. Әллааһү әкбәр.*
*Әллааһү әкбәр. Әллааһү әкбәр.*
*Әшһәдү әлләәә иләәһә илләллааһ.*
*Әшһәдү әлләәә иләәһә илләллааһ.*
*Әшһәдү әннә Мүхәммәдә-р-расүүлүллааһ.*
*Әшһәдү әннә Мүхәммәдә-р-расүүлүллааһ.*
*Хәййә галә-с-саләәәһ.*
*Хәййә галә-с-саләәәһ.*
*Хәййә галә-л-фәләәәх.*
*Хәййә галә-л-фәләәәх.*
(Шушы сүзләрдән соң иртәнге намазга азан әйткәндә
*Әс-саләәту хайрум-минә-н-нәүүүм,*
*Әс-саләәту хайрум-минә-н-нәүүүм,*
дигән ике җөмлә өстәлә).
*Әллааһү әкбәр. Әллааһү әкбәр.*
*Ләә иләәһә иллә-ллааһ».*

Азаннан соң бу дога укыла:

*«Әллааһүммә раббә һәәзиһиддәгвәти-т-тәәммәти вә-с-саләәти-л-каа-а-имәһ. Әәти Мүхәммәдә-ни-л-вәсииләтә вә-л-фәдыйиләтә вә-д-дәраҗәтә-л-гаалийәтә-р-раафигаһ.Вәбгасьһү мәкаамәм-мәхмүүдәниллләзии вәгаттәһ».*

## КАМӘТ

Камәт фарыз намазы алдыннан кычкырып, әмма сузмыйча әйтелә:

*Әллааһү әкбәр. Әллааһү әкбәр.*
*Әллааһү әкбәр. Әллааһү әкбәр.*
*Әшһәдү әлләә иләәһә илләллааһ.*
*Әшһәдү әлләә иләәһә илләллааһ.*
*Әшһәдү әннә Мүхәммәдә-р-расүүлүллааһ.*
*Әшһәдү әннә Мүхәммәдә-р-расүүлүллааһ.*
*Хәййә галә-с-саләәти,*
*хәййә галә-с-саләәһ.*
*Хәййә галә-л-фәләәхи,*
*хәййә галә-л-фәләәх.*
*Каде каамәти-с-саләәтү,*
*каде каамәти-с-саләәһ.*
*Әллааһү әкбәр. Әллааһү әкбәр.*
*Ләә иләәһә илләллааһ».*

## НАМАЗ УКУ ШАРТЛАРЫ

Намаз түбәндәге шартларны үтәгәндә генә укыла: намаз вакыты керү, госел, тәһарәтле булу, тәннең, киемнең һәм гыйбадәт урынының пакьлеге һәм теләсә нинди нәҗестән мөмкин булган дәрәҗәдә котылу һәм ябу кабул ителгән әгъзаларны каплау.

Ирләрнең кендектән алып тезләренә кадәр каплаулы булырга тиеш. Хатын-кызның йөзе һәм кул чукларыннан тыш бөтен гәүдәсе тулысынча каплаулы булырга тиеш. Хатын-кызның киеме тыгыз тукымадан булырга тиеш. Әгәр тукыма аша тәннең төсе күренә икән, намазы дөрес булмый.

# НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

Иртәнге намазның вакыты – таң яктылыгы җәелгәннән башлап, кояш чыга башлаганчы.

Өйлә намазының вакыты – кояш төш вакыты турысыннан авышканнан алып, икенде вакытына кадәр.

Икенде вакыты – һәр нәрсәнең күләгәсе төш вакытындагы күләгәсеннән башка үзе озынлыгы кадәр ике өлеш озайганнан башлап, кояш батканга кадәр.

Ахшам вакыты – кояш батып тәмам күмелгән вакыттан башлап, шәфәкъ кызыллыгы беткәнче.

Ястү вакыты – шәфәкъ кызыллыгы беткән вакыттан башлап, таң яктылыгы җәелгәнчегә кадәр.

Витр һәм тәравих намазларының вакыты – ястү намазы укып бетерелгән вакыттан алып таң атканчыга кадәр.

Җомга намазының вакыты – өйлә вакыты.

Гает намазларының вакыты – кояш чыгып, бераз күтәрелгән мизгелдән башлап, өйлә вакыты кергәнчегә кадәр.

## НАМАЗЛАРДАГЫ РӘКӘГАТЬ САННАРЫ

| намазлар | рәкәгать саннары | | |
|---|---|---|---|
| | фарыз намазга кадәрге сөннәт | фарыз | фарыз намаздан соңгы сөннәт |
| иртәнге | 2 | 2 | - |
| өйлә | 4 | 4 | 2 |
| җомга | 4 | 2 | 4 |
| икенде | - | 4 | - |
| ахшам | - | 3 | 2 |
| ястү, витр | - | 4 | 2-3 |

## КАЙБЕР КАГЫЙДӘЛӘР

Намазда игътибарыңны тупларга, алдыңа гына карарга һәм беркая да борылмаска кирәк.

Намаз укыганда ашыгудан саклан, чөнки ашыгу намазның дөреслеген югалта.

Әгәр намаз җәмәгать белән укылса, бөтен хәрәкәтне имам артыннан кабатла. Әгәр имам күтәрелгәнгә кадәр рөкүгъгә өлгерсәң, шул рәкәгатькә җитешкәнгә хисап кылыныр. Әгәр өлгермәсәң, рәкәгатькә хисап кылынмас. Бер рәкәгатькә яки күбрәккә имамнан соңга калсаң да, намаз беткәнче имам артыннан ияр, ләкин имам белән бергә сәлам бирмәстән, калган рәкәгатьләреңне үзең ялгыз укып тәмамла.

Сәҗдә кылганда җиргә тияргә тиеш булган әгъзалар: йөз, куллар, тезләр һәм аяк бармаклары.

Әттәхиййәттә утырганда уң аякның бармак башларын кыйблага таба каратып бөгеп куела да сул аяк өстенә утырыла, хатын-кызлар исә сул як очалары белән җиргә утыралар һәм ике аякның да башларын кыйблага таба каратып куялар.

Хатын-кызлар азан да, камәт тә әйтмиләр.

Фарыз намазын ике кеше укыса, берсе имам була, икенчесе исә аның уң ягына басып аңа оеп укый. Имамга оеп укучылар бер кешедән күбрәк булсалар, алар имамның артына басып оеп укыйлар. Җәмәгать намазында хатын-кызлар һәм балалар да булса, ирләрдән артта балалар, балалардан соң хатын-кызлар була. Ир белән хатын бергә укысалар, хатын ирнең артында була.

Намазны имамга оеп укыган кеше Сәнә догасын, рөкүгъ, сәҗдәләрдәге зикерләрне, шулай ук

Әттәхиййәт белән Салават һәм Сәлам догаларын эченнән үзе укый.

Ирләр иртәнге һәм җомга намазларының ике рәкәгать фарызында, шулай ук, ахшам һәм ястүдәге фарыз намазларының әүвәлге ике рәкәгатендә Фатиха сүрәсен, аннан соң укыла торган сүрәне һәм тәкбир, сәламнәрне кычкырып укыйлар.

Имамга оеп укыганда да, үзең генә укыганда да Фатиха сүрәсеннән соң әйтелә торган «*Әмин*» сүзе кычкырмыйча, эчтән генә әйтелә.

## СӘҺҮ СӘҖДӘСЕ

Сәһү сәҗдәсе намаз укучы тарафыннан, намаздагы игътибарсызлыгы өчен, сәламләү тәгъбиреннән соң ике мәртәбә сәҗдә кылуны үз эченә ала.

Игътибарсызлык өчен сәҗдә кылучы түбәндәгеләрне белергә тиеш:

Әгәр сәламләү намаз беткәнче ашыгып әйтелгән икән, кеше намазны укып бетерә һәм азагында ике мәртәбә сәҗдә кыла. Намазны сузган очракта да ахырда ике сәҗдә кыла.

Дүрт рәкәгатьле намазда беренче Әттәхиййәтне укырга онытса да ахырда ике сәҗдә кыла

Әгәр ул беренче Әттәхиййәтне укырга онытып, бөтен буена торып басканчы хәтеренә төшерсә, ул төшереп калдырганны тутыра ала. Әгәр тулысынча тураеп басса, инде кире әйләнеп кайтырга ярамый һәм намаз ахырында ике сәҗдә кылырга кирәк.

Әгәр намаз укучы рәкәгатьләр санына шикләнә икән, аларның иң аз күләменнән чыгып эш итсен. Шуннан соң намазны тәмамларга һәм сәламләү сүзләреннән соң утырган хәлдә ике мәртәбә сәҗдә кылырга кирәк.

# ИРТӘНГЕ НАМАЗ

## Ике рәкәгать сөннәт

Кыйбла тарафына юнәлеп намазлык өстенә баскач, күңелеңнән түбәндәгечә иртәнге намазның ике рәкәгать сөннәтен укыйм дип ниятлә:

*«Әгуузү билләәһи минә-ш-шәйтаанир-раҗиим Бисмилләәһи-р-рахмәәни-р-рахиим. Илаһи, ният кылдым, иртә намазының ике рәкәгать сөннәтен укымакка, йөземне юнәлдердем кыйбла тарафына, хаалисан лилләәһи тәгаалә»*, – дигәннән соң, кулларыңны колакка (хатын-кызлар күкрәк өстенә) кадәр күтәреп: *«Әллааһү әкбәр»*, – дип әйт. Кендек астына (хатын-кызлар күкрәк өстенә) уң кулыңны сулы өстенә куй да Сәнә догасын укы:

*«Субхәәнәкә-ллааһүммә вә бихәмдикә вә тәбәәракәсмүкә вә тәгаалә җәддукә вә ләә иләәһә гайрук».*

Әгузү-бисмилләһне әйткәч, Фатиха сүрәсен һәм Коръәннән берничә аять яки бер кыска сүрә укы: *«Әл-хәмдү лилләәһи рабби-л-гааләмииин. Әр-рахмәәни-р-рахииим. Мәәлики йәүми-д-диин. Ииййәәкә нәгъбүдү вә ииййәкә нәстәгыйииин. Иһдинә-с-сыйраата-ль-мусьтәкыйиим. Сыйраата-лләзиинә әнгамтә галәйһим, гайри-л-мәгъдууби галәйһим вә-лә-д-дааааллииин. Әәмиин!»*

*«Вә-л-гаср. Иннә-л-инсәәнә ләфии хусръ. Илләлләзиинә әәмәнүү вә гамилу-с-саалихәәти вә тәвәәсау би-л-хәккый вә тәвәәсау би-с-сабер»*

*«Әллааһү әкбәр»*,–дип, тезләреңә кулларыңны куеп бөгел дә иң азы өч мәртәбә: *«Субхәәнә раббийә-л-газыйиим»*, – дип әйт. Турайганда:

*«Сәмигаллааһү лимән хәмидәһ»*, – дип әйт. Турайгач: *«Раббәнәә ләкә-л-хәмде»*, – диелә.

*«Әллааһү әкбәр»*, – дигән сүз белән сәҗдәгә кит: ике учың белән тезләрдән алдарак җиргә таян, шулай ук маңгай, борын һәм аяк бармакларын да җиргә тидер. Терсәкләреңне намазлыктан һәм гәүдәңнән аерып, иң азы 3 мәртәбә: *«Субхәәнә раббийә-л-әгъләә»*, – дип әйт.

Сәҗдәдән күтәрелеп утырганда: *«Әллааһү әкбәр»*, – дип әйт. Кулларыңны тезләреңә куй. *«Әллааһү әкбәр»*, дигән сүз белән икенче сәҗдәгә кит. Сәҗдәдә иң азы 3 мәртәбә: *«Субхәәнә раббийә-л-әгъләә»*, – дип әйт.

Шуның белән беренче рәкәгать тәмам булды.

Икенче рәкәгатькә баскач Бисмилләһне әйтеп, Фатиха сүрәсен һәм шулай ук башка берәр кыска сүрә яки берничә аять укы да алда әйтеп үтелгән юл белән рөкүгъ һәм ике сәҗдә кыл. Шуннан соң утыр һәм Әттәхиййәт белән Салаватны укы:

*«Әт-тәхиййәәтү лилләәһи вә-с-саләвәәтү вә-т-таййибәәт. Әс-сәләәму галәйкә әййүһә-н-нәбиййү вә рахмәтүллааһи вә бәракәәтүһ. Әссәләәму галәйнәә вә галәә гыйбәәдилләәһи-с-саалихииин. Әшһәдү әлләә иләәһә илләллааһү вә әшһәдү әннә Мүхәммәдән габдүһүү вә расүүлүһ»*

*«Әллааһуммә салли галәә Мүхәммәдин вә галәә әәли Мүхәммәд, кәмәә салләйтә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибрааһиим. Иннәкә Хәмиидум Мәҗиид. Әллааһуммә бәәрик галәә Мүхәммәдин вә галәә әәли Мүхәммәд, кәмәә бәәрактә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибрааһиим. Иннәкә Хәмиидум Мәҗиид»*.

Салаваттан соң Раббәнә догасы укыла:

*«Раббәнәә әәтинә фи-д-дуньйәә хәсәнәтәүв-вә фи-л-әәхыйрати хәсәнәтәүв-вә кыйнәә газәәбә-н-нәәр»*, башыңны уңга һәм сулга борып: *«Әссәләәму галәйкум вә рахмәтуллааһ!»* – дип ике якка сәлам биргәннән соң Сәлам догасын укы:

*«Әстәгъфируллааһ! Әстәгъфируллааһ! Әстәгъфируллааһ! Әллааһуммә әнтә-с-сәләәму вә минкә-с-сәләәм! Тәбәәрактә йәә зә-л-җәләәли вә-л-икраам!»*

## Ике рәкәгать фарыз

1-нче рәкәгать:

Күңелеңнән, иртәнге намазның ике рәкәгать фарызын укыйм дип ниятлә:

*«Әгуузу билләәһи минә-ш-шәйтаани-р-раҗиим Бисмилләәһи-р-рахмәәни-р-рахиим. Илаһи ният кылдым, иртә намазының ике рәкәгать фарызын (имам булып) укымакка, йөземне юнәлдердем кыйбла тарафына, (оедым ошбу хәзер имамга) хаалисан лилләәһи тәгааләә»*, – дигәннән соң кулларыңны күтәреп: *«Әллааһу әкбәр»*, – дип әйт.

Кулларыңны баглап, Сәнә догасын, Әгузубисмилләһне әйтеп, Фатиха сүрәсен һәм бер кыска сүрәне укы, бер рөкүгъ, ике сәҗдә кыл.

2-нче рәкәгать:

Торып баскач, Бисмилләһне әйтеп, Фатиха сүрәсен һәм бер кыска сүрәне укы, бер рөкүгъ, ике сәҗдә кыл да утыр һәм Әттәхийййәт белән Салаватны, Раббәнә догасын укы да ике якка сәлам бир һәм Сәлам догасын укы.

# ЗИКЕР-ТӘСБИХЛӘР

Биш вакыт намазлардан соң түбәндәге зикер-тәсбихләр укыла:

*«Сүбхәнәллааһи вә-л-хәмдү лилләәһи вә ләә иләәһә илләллааһү вәллааһү әкбәр, ләә хәүлә вә ләә куввәтә илләә билләәһи-л-галиййи-л-газыйиим. Мәә шәәәә-әллааһү кәәнә вә мәә ләм йәшәэ ләм йәкүн»*

*Әгуузү билләәһи минә-ш-шәйтаани-р-раҗиим.*

*Бисмилләәһи-р-рахмәәни-р-рахииим.*

*Әллааһү ләә иләәһә илләә һүәл-хәййү-л-каййүүмү ләә тәәхузүһүү синәтүввә ләә нәүүм. Ләһүү мәә фи-с-сәмәәвәәти вә мәә фи-л-әрдъ. Мәң зәлләзии йәшфәгуу гыйңдәһүү илләә би изниһ. Йәгъләмү мәә бәйнә әйдииһим вә мәә халфәһүм вә ләә йүхыйиитуунә би шәй-им мин гыйльмиһии илләә бимәә шәәә-ә вәсига курсиййүһү-с-сәмәәвәәти вә-л-әрда вәләә йә-үүдүһүү хыйфзуһүмәә вә һүә-л-галиййү-л-газыйиим».*

33 мәртәбә *«Сүбхәәнәллааһ».*

33 мәртәбә *«Әл-хәмдү лилләәһ».*

33 мәртәбә *«Әллааһү әкбәр».*

*«Ләә иләәһә илләллааһү вәхдәһүү ләә шәриикә ләһ. Ләһү-л-мүлкү вә ләһү-л-хәмдү вә һүә галәә күлли шәй-иң кадиир».*

Бу зикерләрдән соң кул күтәреп дога кылына:

*«Әллааһүммә тәкаббәл миннәә саләәтәнәә вә сыйәәмәнәә вә кыйра-әәтәнәә вә рукүүганәә вә сүҗүүдәнәә вә кугуудәнәә вә тәсбиихәнәә вә тәһлииләнәә вә тәхашшүганәә вә тәдарруганәә.*

*Әллааһүммә тәммим тәкъсыйиранәә вә тәкаббәл тәмәәмәнәә вәстәҗиб дүгаа-әнәә вәгъфирь әхьйә-әнәә вәрхәм мәүтәәнәә йәә мәүләәнәә.*

*Әллааһүммә-хфәзнәә йәә хәәфизъ мин җәмиигый-ль-бәләәйәә вә-л-әмрадзъ.*

*Әллааһүммә тәкаббәл миннәә һәәзиһи-с-саләәтә-л-фәрда мәга-с-сүннәти мәга җәмиигый нүкъсаанәәтиһәә би фәдъликә вә кәраамикә, вә ләә тәдъриб биһәә вүҗүүһәнәә йәә иләәһә-л-гааләмиин, вә йәә хайра-н-нәәсыйриин. Тәвәффәнәә мүслимиинә вә әлхыйкънәә би-с-саалихиин. Вә салләллааһү тәгааләә галәә хайри халькыйһии мүхәммәдин вә галәә әәлиһии вә әсъхәәбиһии әҗмәгыйиин. Вә-л-хәмдү лилләәһи рабби-л-гааләмиин. Бирахмәтикә йәә әрхәмә-р-раахимиин. Әмин».*

## ӨЙЛӘ НАМАЗЫ

### Дүрт рәкәгать сөннәт

1-нче рәкәгать:

*«Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаани-р-раҗиим. Бисмилләәһи-р-рахмәәни-р-рахииим. Илаһи, ният кылдым, өйлә намазының дүрт рәкәгать сөннәтен укымакка, йөземне юнәлдердем кыйбла тарафына, хаалисан лилләәһи тәгааләә»*, – дигәч, кулларыңны күтәреп: *«Әллааһү әкбәр»*, – дип әйт. Кулларыңны билгеле тәртиптә багла да Сәнә догасын укы һәм Әгузү-бисмилләһ әйткәч, Фатиха сүрәсен һәм Коръәннән берничә аять яки сүрә укы да бер рөкүгъ, ике сәҗдә кыл.

2-нче рәкәгать:

Торып баскач, Бисмилләһне әйтеп, Фатиха сүрәсен һәм бер кыска сүрәне укы, бер рөкүгъ, ике сәҗдә кыл да утыр һәм Әттәхиййәтне укыгач, өченче рәкәгатькә тор.

3-нче рәкәгать:

Бисмилләһне әйтеп, Фатиха сүрәсен һәм бер кыска сүрәне укы, бер рөкүгъ, ике сәҗдә кыл да дүртенче рәкәгатькә тор.

4-нче рәкәгать:

Бисмилләһне әйтеп, Фатиха сүрәсен һәм бер кыска сүрәне укы, бер рөкүгъ, ике сәҗдә кыл да утыр һәм Әттәхиййәт белән Салаватны, Раббәнә догасын укы да ике якка сәлам бир һәм Сәлам догасын укы.

## Дүрт рәкәгать фарыз

1-нче рәкәгать:

*«Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаани-р-раҗиим. Бисмилләәһи-р-рахмәәни-р-рахиим. Илаһи, ният кылдым, өйлә намазының дүрт рәкәгать фарызын укымакка, йөземне юнәлдердем кыйбла тарафына, хаалисан лилләәһи тәгааләә»,* – дигәч, кулларыңны күтәреп: *«Әллааһу әкбәр»*, – дип әйт. Кулларыңны билгеле тәртиптә багла да Сәнә догасын укы һәм Әгузү-бисмилләһ әйткәч, Фатиха сүрәсен һәм Коръәннән берничә аять яки сүрә укы да бер рөкүгъ, ике сәҗдә кыл.

2-нче рәкәгать:

Торып баскач, Бисмилләһне әйтеп, Фатиха сүрәсен һәм бер кыска сүрәне укы, бер рөкүгъ, ике сәҗдә кыл да утыр һәм Әттәхиййәтне укыгач, өченче рәкәгатькә тор.

3-нче рәкәгать:

Бисмилләһне әйтеп, Фатиха сүрәсен генә укы, бер рөкүгъ, ике сәҗдә кыл да дүртенче рәкәгатькә тор.

4-нче рәкәгать:

Бисмилләһне әйтеп, Фатиха сүрәсен генә укы, бер рөкүгъ, ике сәҗдә кыл да утыр һәм Әттәхиййәт белән Салаватны, Раббәнә догасын укы да ике якка сәлам бир һәм Сәлам догасын укы.

## Ике рәкәгать сөннәт

1-нче рәкәгать:

*«Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаани-р-раҗиим. Бисмилләәһи-р-рахмәәни-р-рахииим. Илаһи, ният кылдым, өйлә намазының ике рәкәгать сөннәтен укымакка, йөземне юнәлдердем кыйбла тарафына, хаалисан лилләәһи тәгааләә»*, – дигәч, кулларыңны күтәреп: *«Әллааһү әкбәр»*, – дип әйт. Кулларыңны билгеле тәртиптә багла да Сәнә догасын укы һәм Әгузү-бисмилләһне әйткәч, Фатиха сүрәсен һәм Коръәннән берничә аять яки сүрә укы да бер рөкүгъ, ике сәҗдә кыл.

2-нче рәкәгать:

Торып баскач, Бисмилләһне әйтеп, Фатиха сүрәсен һәм бер кыска сүрәне укы, бер рөкүгъ, ике сәҗдә кыл да утыр һәм Әттәхиййәт белән Салаватны, Раббәнә догасын укы да ике якка сәлам бир һәм Сәлам догасын укы.

# ИКЕНДЕ НАМАЗЫ

## Дүрт рәкәгать фарыз

1-нче рәкәгать:

*«Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаани-р-раҗиим. Бисмилләәһи-р-рахмәәни-р-рахиим. Илаһи, ният кылдым, икенде намазының дүрт рәкәгать фарызын укымакка, йөземне юнәлдердем кыйбла тарафына, хаалисан лилләәһи тәгааләә»*, – дигәч, кулларыңны күтәреп: *«Әллааһү әкбәр»*, – дип әйт.

Кулларыңны билгеле тәртиптә багла да Сәнә догасын укы һәм Әгузү-бисмилләһне әйткәч, Фатиха сүрәсен һәм Коръәннән берничә аять яки сүрә укы да бер рөкүгъ, ике сәждә кыл.

2-нче рәкәгать:

Торып баскач, Бисмилләһне әйтеп, Фатиха сүрәсен һәм бер кыска сүрәне укы, бер рөкүгъ, ике сәждә кыл да утыр һәм Әттәхиййәтне укыгач, өченче рәкәгатькә тор.

3-нче рәкәгать:

Бисмилләһне әйтеп, Фатиха сүрәсен генә укы, бер рөкүгъ, ике сәждә кыл да дүртенче рәкәгатькә тор.

4-нче рәкәгать:

Бисмилләһне әйтеп, Фатиха сүрәсен генә укы, бер рөкүгъ, ике сәждә кыл да утыр һәм Әттәхиййәт белән Салаватны, Раббәнә догасын укы да ике якка сәлам бир һәм Сәлам догасын укы.

# АХШАМ НАМАЗЫ

## Өч рәкәгать фарыз

1-нче рәкәгать:

*«Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаани-р-раҗиим. Бисмилләәһи-р-рахмәәни-р-рахиим. Илаһи, ният кылдым, ахшам намазының өч рәкәгать фарызын укымакка, йөземне юнәлдердем кыйбла тарафына, хаалисан лилләәһи тәгааләә»*, – дигәч, кулларыңны күтәреп: *«Әллааһү әкбәр»*, – дип әйт. Кулларыңны билгеле тәртиптә багла да Сәнә догасын укы һәм Әгузү-бисмилләһне әйткәч, Фатиха сүрәсен һәм Коръәннән берничә аять яки сүрә укы да бер рөкүгъ, ике сәждә кыл.

2-нче рәкәгать:

Торып баскач, Бисмилләһне әйтеп, Фатиха сүрәсен һәм бер кыска сүрәне укы, бер рөкүгъ, ике сәждә кыл да утыр һәм Әттәхиййәтне укыгач, өченче рәкәгатькә тор.

3-нче рәкәгать:

Бисмилләһне әйтеп, Фатиха сүрәсен генә укы, бер рөкүгъ, ике сәждә кыл да утыр һәм Әттәхиййәт белән Салаватны, Раббәнә догасын укы да ике якка сәлам бир һәм Сәлам догасын укы.

## Ике рәкәгать сөннәт

1-нче рәкәгать:

*«Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаани-р-раҗиим. Бисмилләәһи-р-рахмәәни-р-рахиим. Илаһи, ният кылдым, ахшам намазының ике рәкәгать сөннәтен укымакка, йөземне юнәлдердем кыйбла*

*тарафына, хаалисан лилләәhи тәгааләә»,* – дигәч, кулларыңны күтәреп: *«Әллааhу әкбәр»*, – дип әйт.

Кулларыңны билгеле тәртиптә багла да Сәнә догасын укы һәм Әгузү-бисмилләhне әйткәч, Фатиха сүрәсен һәм Коръәннән берничә аять яки сүрә укы да бер рөкүгъ, ике сәждә кыл.

2-нче рәкәгать:

Торып баскач, Бисмилләhне әйтеп, Фатиха сүрәсен һәм бер кыска сүрәне укы, бер рөкүгъ, ике сәждә кыл да утыр һәм Әттәхиййәт белән Салаватны, Раббәнә догасын укы да ике якка сәлам бир һәм Сәлам догасын укы.

## ЯСТҮ НАМАЗЫ

### Дүрт рәкәгать фарыз

1-нче рәкәгать:

*«Әгуузү билләәhи минәш-шәйтаани-р-раҗиим. Бисмилләәhи-р-рахмәәни-р-рахиим. Илаhи, ният кылдым, ястү намазының дүрт рәкәгать фарызын укымакка, йөземне юнәлдердем кыйбла тарафына, хаалисан лилләәhи тәгааләә»*, – дигәч, кулларыңны күтәреп: *«Әллааhү әкбәр»*, – дип әйт.

Кулларыңны билгеле тәртиптә багла да Сәнә догасын укы һәм Әгузү-бисмилләhне әйткәч, Фатиха сүрәсен һәм Коръәннән берничә аять яки сүрә укы да бер рөкүгъ, ике сәждә кыл.

2-нче рәкәгать:

Торып баскач, Бисмилләhне әйтеп, Фатиха сүрәсен һәм бер кыска сүрәне укы, бер рөкүгъ, ике сәждә кыл да утыр һәм Әттәхиййәтне укыгач, өченче рәкәгатькә тор.

3-нче рәкәгать:

Бисмилләһне әйтеп, Фатиха сүрәсен генә укы, бер рөкүгъ, ике сәҗдә кыл да дүртенче рәкәгатькә тор.

4-нче рәкәгать:

Бисмилләһне әйтеп, Фатиха сүрәсен генә укы, бер рөкүгъ, ике сәҗдә кыл да утыр һәм Әттәхиййәт белән Салаватны, Раббәнә догасын укы да ике якка сәлам бир һәм Сәлам догасын укы.

## Ике рәкәгать сөннәт

1-нче рәкәгать:

*«Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаани-р-раҗиим. Бисмилләәһи-р-рахмәәни-р-рахиим. Илаһи, ният кылдым, ясту намазының ике рәкәгать сөннәтен укымакка, йөземне юнәлдердем кыйбла тарафына, хаалисан лилләәһи тәгааләә»*, – дигәч, кулларыңны күтәреп: *«Әллааһү әкбәр»*, – дип әйт.

Кулларыңны билгеле тәртиптә багла да Сәнә догасын укы һәм Әгузү-бисмилләһне әйткәч, Фатиха сүрәсен һәм Коръәннән берничә аять яки сүрә укы да бер рөкүгъ, ике сәҗдә кыл.

2-нче рәкәгать:

Торып баскач, Бисмилләһне әйтеп, Фатиха сүрәсен һәм бер кыска сүрәне укы, бер рөкүгъ, ике сәҗдә кыл да утыр һәм Әттәхиййәт белән Салаватны, Раббәнә догасын укы да ике якка сәлам бир һәм Сәлам догасын укы.

## ВИТР-ВӘҖЕП НАМАЗЫ

1-нче рәкәгать:

*«Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаани-р-раҗиим. Бисмилләәһи-р-рахмәәни-р-рахиим. Илаһи, ният кылдым, өч рәкәгать витр-вәҗеп намазын укымакка, йөземне юнәлдердем кыйбла тарафына, хаалисан лилләәһи тәгаалә»,* – дигәч, кулларыңны күтәреп: *«Әллааһү әкбәр»*, – дип әйт. Кулларыңны билгеле тәртиптә багла да Сәнә догасын укы һәм Әгузү-бисмилләһне әйткәч, Фатиха сүрәсен һәм Коръәннән берничә аять яки сүрә укы да бер рөкүгъ, ике сәҗдә кыл.

2-нче рәкәгать:

Торып баскач, Бисмилләһне әйтеп, Фатиха сүрәсен һәм бер кыска сүрәне укы, бер рөкүгъ, ике сәҗдә кыл да утыр һәм Әттәхиййәтне укыгач, өченче рәкәгатькә тор.

3-нче рәкәгать:

Бисмилләһне әйтеп, Фатиха сүрәсен һәм бер кыска сүрәне укы да кулларыңны күтәреп тәкбир әйт һәм Кунут догасын укы: *«Әллааһүммә иннәә нәстәгыйиинукә, вә нәстәгъфирукә, вә нәстәһдиикә, вә нүэминү бикә, вә нәтүүбү иләйкә, вә нәтәвәккәлү галәйкә вә нүснии галәйкә-л-хайра күлләһү нәшкүрукә, вә ләә нәкфүрукә, вә нәхъләгу, вә нәтрукү мәййәфҗүрук. Әллааһүммә иййәәкә нәгъбүдү, вә ләкә нүсаллии, вә нәсҗүдү, вә иләйкә нәсгаа, вә нәхъфидү; нәрҗү рахмәтәкә вә нәхъшәә газәәбәк.Иннә газәәбәкә бил-күффәәри мүлхыйкъ»,* һәм бер рөкүгъ, ике сәҗдә кыл да утыр һәм Әттәхиййәт белән Салаватны, Раббәнә догасын укы да ике якка сәлам бир һәм Сәлам догасын укы.

# ҖОМГА НАМАЗЫ

## Дүрт рәкәгать сөннәт

1-нче рәкәгать:

*«Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаани-р-раҗиим. Бисмилләәһи-р-рахмәәни-р-рахиим. Илаһи, ният кылдым, җомга намазының дүрт рәкәгать сөннәтен укымакка, йөземне юнәлдердем кыйбла тарафына, хаалисан лилләәһи тәгаалəә»*, – дигәч, кулларыңны күтәреп: *«Әллааһү әкбәр»*, – дип әйт.

Кулларыңны билгеле тәртиптә багла да Сәнә догасын укы һәм Әгузү-бисмилләһне әйткәч, Фатиха сүрәсен һәм Коръәннән берничә аять яки сүрә укы да бер рөкүгъ, ике сәҗдә кыл.

2-нче рәкәгать:

Торып баскач, Бисмилләһне әйтеп, Фатиха сүрәсен һәм бер кыска сүрәне укы, бер рөкүгъ, ике сәҗдә кыл да утыр һәм Әттәхиййәтне укыгач, өченче рәкәгатькә тор.

3-нче рәкәгать:

Бисмилләһне әйтеп, Фатиха сүрәсен һәм бер кыска сүрәне укы, бер рөкүгъ, ике сәҗдә кыл да дүртенче рәкәгатькә тор.

4-нче рәкәгать:

Бисмилләһне әйтеп, Фатиха сүрәсен һәм бер кыска сүрәне укы, бер рөкүгъ, ике сәҗдә кыл да утыр һәм Әттәхиййәт белән Салаватны, Раббәнә догасын укы да ике якка сәлам бир һәм Сәлам догасын укы.

Ошбу дүрт рәкәгать сөннәттән соң, имам мөнбәргә менгәч, мөәзин икенче азанны әйтә. Икенче азаннан соң Азан догасы укылмый. Имам мөнбәрдә ике хөтбә укый. Башкалар тын гына

имамны тыңлап торалар. Ике хөтбә арасында имам дога кыла. Имам икенче хөтбәне укып бетергәннән соң мөнбәрдән төшкәч, мөәзин фарыз намазына камәт әйтә.

## Ике рәкәгать фарыз

*«Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаани-р-раҗиим. Бисмилләәһи-р-рахмәәни-р-рахиим. Илаһи, ният кылдым җомга намазының ике рәкәгать фарызын укымакка, йөземне юнәлдердем кыйбла тарафына, оедым ошбу хәзер имамга хаалисан лилләәһи тәгаалә»*, – дисең һәм имам кулларын күтәреп: *«Әллааһү әкбәр»*, – дип тәкбир әйткәч, син дә имам артыннан кабатлап шул ук тәкбирне әйтәсең һәм башка фарыз намазларындагы кебек үк ошбу ике рәкәгатьне имамга оеп укыйсың.

## Дүрт рәкәгать сөннәт

1-нче рәкәгать:

*«Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаани-р-раҗиим. Бисмилләәһи-р-рахмәәни-р-рахиим. Илаһи, ният кылдым җомга намазының дүрт рәкәгать сөннәтен укымакка, йөземне юнәлдердем кыйбла тарафына, хаалисан лилләәһи тәгаалә»*, – дигәч, кулларыңны күтәреп: *«Әллааһү әкбәр»*, – дип әйт.

Кулларыңны билгеле тәртиптә багла да Сәнә догасын укы һәм Әгузү-бисмилләһне әйткәч, Фатиха сүрәсен һәм Коръәннән берничә аять яки сүрә укы да бер рөкүгъ, ике сәҗдә кыл.

2-нче рәкәгать:

Торып баскач, Бисмилләһне әйтеп, Фатиха сүрәсен һәм бер кыска сүрәне укы, бер рөкүгъ, ике сәждә кыл да утыр һәм Әттәхиййәтне укыгач, өченче рәкәгатькә тор.

3-нче рәкәгать:

Бисмилләһне әйтеп, Фатиха сүрәсен һәм бер кыска сүрәне укы, бер рөкүгъ, ике сәждә кыл да дүртенче рәкәгатькә тор.

4-нче рәкәгать:

Бисмилләһне әйтеп, Фатиха сүрәсен һәм бер кыска сүрәне укы, бер рөкүгъ, ике сәждә кыл да утыр һәм Әттәхиййәт белән Салаватны, Раббәнә догасын укы да ике якка сәлам бир һәм Сәлам догасын укы.

## ГАЕТ НАМАЗЛАРЫ

Гает намазы ике рәкәгатьтән тора. Беренче рәкәгать башында намазга керешү тәкбиреннән соң Сәнә укыгач, һәм икенче рәкәгатьтә рөкүгъгә китәр алдыннан кулларын күтәреп янә өчәр мәртәбә *«Әллаһү әкбәр»,* дип тәкбир әйтелә. Дүртенче тәкбир белән рөкүгъгә кителә. Рәкәгатьләрдә «Фатиха» сүрәсен һәм башка аятьләр укыла.

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

***Бисмилләһи-р-рахмәни-р-рахим***

# РАМАЗАН ҺӘМ КОРБАН БӘЙРӘМНӘРЕ

Бәйрәмнәр кешеләрнең тормышында мөһим бер вакыйга булып торалар. Бәйрәмнәр кешеләр арасындагы бергәлекне арттыра, кардәшлекне ныгыта, гает көннәрендә кешеләр, мәчетләрдә күрешеп, бер-берләре белән йөрешеп, араларындагы дуслыкны сафландыралар.

Пәйгамбәребез гает көннәрендә иртәрәк уянуны, ару итеп юынуны, хушбуйлар сөртүне, иң яраткан һәм иң яхшы киемнәрне киюне, урамда яисә мәчеттә очрашкан кешеләргә шат һәм көләч йөзле булуны саваплы эшләр дип аңлаткан.

Рамазан гаетендә намаздан элек нәрсә булса да ашап, мәчеткә бару, Корбан гаетендә исә гает намазын укып бетермичә, берни дә ашамау мөстәхәб санала.

Гает шатлык булганга күрә, гает көнендә кешеләр өчен күңелле вә кызык булган, дин ягыннан тыелмаган эшләрне дә эшләргә рөхсәт ителгән. Бу көнне һәртөрле спорт ярышлары, балаларны шатландыра торган көлкеле, кызыклы уеннар уйнарга, милли, тарихи җырларны җырлап күңел ачарга һәм боларга охшаган күңел ачулар оештырырга мөмкин.

Рамазан гаете өч көн, Корбан гаете дүрт көн дәвам итә. Гает көннәрендә мөселманнар берберләрен гает бәйрәме белән котлап, бер-берләре өчен дога кылырлар.

Кайбер хәдис вә фикыһ китапларында мөселманнар бер-берләренә шулай дога кылсыннар диелгән: *«Гафәраллаһү ләнә вә ләкүм»,* ягъни, Аллаһ безне дә, сезне дә гафу әйләсен. Яисә «Тәкаббәләллаһу Тәгалә миннә вә минкүм», ягъни, Аллаһы Тәгалә бездән вә сездән кабул итсен.

## КОРБАН ЧАЛУЛАР

Корбан – Аллаһыга якынлык өчен Корбан бәйрәме көннәрендә чалынган хайвандыр.

Корбан чалу гадәте Ибраһим пәйгамбәр вакытыннан бирле дәвам итеп килә.

Аллаһы Тәгалә әйткән: *«Раббың өчен намаз укы һәм корбан чал.»* Коръән аяте: (Кәүсәр - 2)

Бай мөселманнарга һәр елны Корбан бәйрәме көннәрендә корбан чалу вәҗептер. Корбанны бәйрәмнең беренче көнендә чалу яхшырак. Беренче көнне чалу мөмкин булмаса, икенче көнне, икенче көнне мөмкин булмаса, өченче көнне кояш баеганга кадәр чалырга мөмкин.

Корбан итеп дөя, сыер, сарык һәм кәҗә кебек хайваннар чалына. Болардан дөя белән сыерны, теләсәләр, җиде кеше уртак итеп чала алалар. Кешеләрнең саны җидедән дә азрак булырга мөмкин. Ләкин сарык белән кәҗә бер кеше өчен генә ярый. Бу хайваннарның яшьләре дә динебездә түбәндәгечә билгеләнгән: дөя иң аз дигәндә биш яшендә, сарык белән кәҗә бер яшьтә булулары шарт. Бу яшьләрдән ким булган хайваннарны корбан чалу дөрес түгел. Алты айлык сарык яки кәҗә бәтие, бер яшен тутырган сарык яисә кәҗә кадәр зур һәм симез булса, аларны да корбан итеп чалу дөрес.

Бу әйтелгән хайваннардан башка каз, үрдәк, тавык кебекләр корбан итеп чалынмас. Корбан буларак чалынган хайванның әгъзалары бөтен һәм сәламәт булырга тиеш. Мәсәлән, күзләренең берсе яисә икесе дә сукыр, тешләренең күбесе төшкән, колаклары, мөгезе яисә койрыгы төптән өзелгән хайваннарны корбан итеп чалырга ярамый. Бик ябык, йөри алмаган, аксак вә авыру хайваннарны да корбан итеп чалынмас.

## ҖОМГА КӨН

Динебездәге иң изге көннәрдән берсе – җомга көнедер. Пәйгамбәребезнең хәдисе буенча, җомга көне гает көннәреннән дә изгерәктер.

Җомга көн – мөселманнарның бәйрәме. Бу көнне өйлә вакытында җәмәгать белән укыла торган җомга намазы бар. Иң аз дигәндә атнага бер мәртәбә, мәчеткә барып, бу намазны уку, вәгазь тыңлау мөселманнарга фарыздыр. Сәбәпсез җомга намазын калдыру зур гөнаһтыр.

Җомга көнне, балаларга бүләкләр алып, аларны шатландыру, ярлыларга ярдәм бирү, каберләрне зиярәт итү, госел алып, яңа, ару киемнәр киеп, мәчеткә бару, кардәшләр белән күрешү дини гадәтләребездәндер.

Пәйгамбәребезнең хәдисе буенча, җомга көнендә кылынган догаларны Аллаһы Тәгалә кабул итә торган бер сәгать бар. Ләкин бу сәгатьнең кайсы вакытка туры килүен беркем дә белми. Моның максаты – мөселманнарны мөмкин кадәр көне буе гыйбадәт хәлендә тоту, яхшы вә саваплы эшләргә өндәүдер.

Адәм галәйһиссәләм җомга көнне яралтылган. Шуның өчен адәм баласы бар ителгән бу көн изге көн дип кабул ителгән. Бу көнне бер-беребезне хөрмәтләү, гыйбадәт вә догалар кылып, Аллаһыга рәхмәтебезне белдерү һәр мөселманның вазифаларыннандыр.

## ИЗГЕ АЙЛАР

Аллаһы Тәгалә колларының гөнаһларын гафу итәр өчен төрле айлар, көннәр вә кичәләр яраткан. Бу вакытларның, кыйммәтен белеп, миннән гафу сорагыз, гафу итәрмен дигән. Аеруча бу вакытларда гыйбадәтләрне күбрәк кылырга, начар гадәтләрне ташлап, яхшы кеше булырга омтылырга кушкан.

Ислам динендә изге айлар дип кабул ителгән өч ай бар. Болар: Рәҗәп, Шәгъбан һәм Рамазан айлары. Пәйгамбәребез бу айлар турында түбәндәгеләрне әйткән: *«Рәҗәп ае Аллаһының ае, Шәгъбан ае минем ай, Рамазан ае өммәтемнең аедыр»*. Кайбер мөселманнар бу изге айларны ураза тотып уздыралар.

## КАДЕР КИЧЕ

Ислам галәмендә айлар арасында Рамазан ае, көннәр арасында җомга көн, кичәләр арасында Кадер киче иң мөбарәк, иң мөкатдәс вакытлар дип кабул ителгән. Бигрәк тә Кадер кичәсе мең айдан да хәерлерәк булганы өчен барча көннәрдән вә кичләрдән кыйммәтле һәм әһәмиятледер.

Мең айның мәгънәсе мөселманнарның бу кичне мең айлык гыйбадәт савабын казаначакларын

аңлата. Бу кичтә фәрештәләр һәм Җәбраил галәйһиссәләм җир йөзенә төшәрләр.

Кадер кичәнең кайсы кич булганы төгәл итеп билгеләнмәгән. Кадер киче турында Пәйгамбәребезнең төрле хәдисләре бар. Бу хәдисләрдә Пәйгамбәребез шулай дигән: *«Кадер кичен Рамазанның ахыргы ун көне арасыннан, бигрәк тә парсыз кичләрдән эзләгез».*

Пәйгамбәребез Рамазан аенда гыйбадәт вә догаларын тагын да арттыра, бигрәк тә Рамазанның соңгы ун көнендә, бик аз йоклый, көне-төне гыйбадәт кыла торган булган.

Гайшә анабыз Пәйгамбәребездән сораган: «Әй, Аллаһының илчесе. Кадер кичәсенә ирешсәм, ничек дога кылыйм?» Пәйгамбәребез түбәндәгечә дога кыл дигән: *«Әллаһуммә иннәкә гафуввун, тухиббул гафвә, фәгъфу ганни»,* ягъни «Аллаһым Син бик гафу итүчесең. Гафу итүне дә яратасың. Мине дә гафу әйлә».

Кадер кичендә ике мөһим вакыйга булган:

Бу кичне Мөхәммәд галәйһиссәләмнең пәйгамбәрлек вазифасы башланган.

Коръән беренче тапкыр бу кичне төшерелә башлаган.

Мең айдан да хәерлерәк булган бу кичне гафләт белән уздыру зур хата булыр. Шуның өчен елга бер мәртәбә килә торган бу кичне гыйбадәтләр, догалар, тәүбәләр белән уздырырга кирәк. Пәйгамбәребез бер хәдисендә болай дигән: *«Кем, Аллаһыга ышанып, һәм савабын Аллаһыдан өмет итеп, Кадер кичәсен гыйбадәт белән уздырса, ул кешенең эшләгән гөнаһлары гафу ителер».*

## БАЛАЛАРГА ИСЕМ КУШУ

Балаларга исем кушу Пәйгамбәребезнең сөннәтләреннәндер. Бала тугач, бер атнадан балага исем кушарга кирәк. Ул берничә көн элек, яки соң булса да ярый. Пәйгамбәребез улы Ибраһим туып, бер атнадан соң мал суеп, халыкны мәҗлескә җыйган. Кунаклар ашап-эчкәннән соң, барлык чакырылган кеше алдында балага исем кушылган. Шул ук көнне баланың чәчләре кыркылган һәм чәчләренең авырлыгы кадәр көмеш акча ярлыларга сәдака итеп өләшенгән.

Балага исем кушканда баланың бер колагына азан, икенче колагына камәт әйтелә. Азан вә камәттән соң бала өчен дога кылына. Догадан соң да бер яки өч мәртәбә баланың колагына исеме кычкырып әйтелә. Шуның белән исем кушу йоласы тәмам була.

Ата-ананың баласына карата булган беренче вазифасы шушы дини тантана белән башлана. Исем кушу вазифасын үтәгәндә балага матур һәм мәгънәле исем кушарга кирәк. Пәйгамбәребез әйткән: *«Кыямәт көнендә сез үз исемнәрегез һәм аталарыгызның исемнәре белән чакырылачаксыз, шуның өчен балаларга гүзәл исемнәр кушыгыз».*

Пәйгамбәребез мәгънәсез, ямьсез исемнәрне алыштыра торган булган.

Балага исем кушканда игътибарлы булырга кирәк. Аллаһы Тәгаләнең «Аллаһ» дигән исеменнән башка тагы 99 исеме бар. Аларга Аллаһының исем-сыйфатлары диләр. Күп кешеләр бу сыйфатларны да балаларына исем итеп кушалар. Ләкин бу сыйфатларның кайберләрен балага исем итеп кушарга ярамый. Мәсәлән: Халикъ (бар итүче), Рахман

(колларына бик мәрхәмәтле), Коддүс (кимчелексез), Мүһәймин (бөтен барлыкны саклаучы), Мутәкәббир (бик олы, бик бөек). Аллаһыга гына мөнәсәбәте булган бу исемнәрне кешеләргә кушу хәрам санала. Әгәр бу исемнәрне балаларга исем буларак кушкан очракта бу исемнәрнең алдына «габде» (кол) сүзен куярга кирәк, ягъни: Габделхаликъ, Габдеррахман һ.б. Аллаһының сыйфатларын аңлата торган кайбер сүзләрне кешеләргә исем буларак кушарга ярый. Ләкин кешеләр бу сыйфатларга лаек булырга тиешләр. Мәсәлән: Галим (белүче), Сәмигъ (ишетүче), Басир (күрүче), Кадир (көче җитүче). Шулай булса да, бу исемнәрнең алдына «габде» сүзен кую хәерлерәк.

Ата-ананың вазифасы бала тудыру белән генә чикләнми. Туган баланы сәламәт итеп үстерү, яхшы тәрбияләү, дине вә милләте өчен файдалы итү – ата-ананың иң зур вазифаларыннан исәпләнә.

Ата-ананың баласына карата булган вазифалары нигездә түбәндәгеләр:

– балаларына хәләл ризыклар гына ашату;

– бала тугач матур һәм мәгънәле исем кушу;

– ир баланы сөннәтләү;

– мәктәп яшенә җиткәч, аны мәктәпкә җибәрү;

– җиде яшеннән башлап дини белемнәрне өйрәтү;

– ун яшенә җиткәч, намаз укырга өндәү.

Ун яшьтән соң балага Коръән укырга һәм динебезнең нигезләрен өйрәтү – ата-ананың иң мөһим вазифаларыннан санала.

Өйләнү яшенә җиткәч, баласын эчемлек мәҗлесләре ясамыйча дөрес итеп өйләндерер.

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

***Бисмилләһи-р-рахмәни-р-рахим***

## ЯХШЫ ХӘЛЛӘР – КҮРКӘМ ХОЛЫКЛАР

Холык – тумыштан яки уку-өйрәнү һәм гаилә тәрбиясе белән ирешелгән рухи халәттер.

Сүзләрендә, эшләрендә һәм һәртөрле хәлләрдә дөрес эш иткән кешегә әхлаклы кеше диләр. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм үзенең бер хәдисендә әйткән: *«Холкы яхшы булган мөселман – иман ягыннан да иң мөкәммәл мөселмандыр».*

Мөхәммәд галәйһиссәләм янә әйткән: *«Аллаһ сезнең тышкы сурәтләрегезгә карамас. Ләкин Ул сезнең эчегезгә, калебләрегезгә карар».* Димәк, эчке арулык, рух чисталыгы Ислам динендә зур әһәмияткә ия икән. Шуның өчен дә кешенең үзенә карата булган иң мөһим вазифаларыннан берсе булып үзен рухи яктан үстерү санала. Начар һәм пычрак уйлардан үзен саклау, башкалар турында ямьсез фикер йөртүдән үзен тыю кешенең үзенә карата булган иң төп вазифаларынан санала.

Кешедә ике төрле хасталык бар: берсе матди, икенчесе мәгънәви хасталык. Тәнебездәге матди хасталыклар күзгә күренеп беленә. Гәүдәбезне һәртөрле матди хасталыклардан саклау – үзебезгә карата булган вазифаларыбызның берсе. Мәгънәви хасталыклар күзгә күренмәсләр. Гайбәт, ялганчылык, яла ягу, хәйләкәрлек, алдау, башкаларны мыскыл итү, көнләшү, тәкәбберлек, саранлык һәм ялкаулык кебек чирләр рухи хасталыклардан санала.

Мөхәммәд галәйһиссәләм әйткән: *«Ике көнен бертигез үткәргән кеше зарардадыр».*

Чыннан да, әгәр кеше һәркөнне алга таба бару һәм өзлексез үзен камилләштерү өстендә тырышмаса, ул иртәгә зыянда калачак.

Тормышын тырышлык белән алып барган һәм башкаларның тәҗрибәсен өйрәнгән кеше генә үзенә, милләтенә һәм диненә файда китерә ала.

Күңеле Ислам нуры белән яктырган мөселман, җәмгыять әгъзасы буларак, башкаларның ышанычын яулау өчен бөтен көчен куя. Чөнки кешеләр үзләре яраткан һәм хөрмәт иткән кешегә генә ышаналар, аның сүзләренә колак салалар.

Мөхәммәд галәйһиссәләм әйткән:

*«Кыямәт көнендә миңа иң якын кешеләр – сезнең иң күркәм холыклыларыгыздыр».*

Күркәм холыкның төрләре бик күп:

- Тугрылык. Тугрылыклы булу фазыйләткә ирештерә.
- Хатаны тану. Үз хаталарыңны танымыйча, карышып тору – мәгънәсезлектер.
- Сүзне батыр итеп сөйләү. «Кешеләр ратмас», «теге кешенең күңеленә хуш килмәс», «дөресен әйтсәм, күңеленә авыр килер» кебек сәбәпләр белән күпләр дөрес сөйләүдән тартыналар. Бу эш шәригать каршында ап-ачык хыянәттер.
- Вазифаны белү. Кирәк дини, кирәк дөньяви булсын, һәрбер кеше үз вазифасын үзе яхшы белергә тиеш.
- Хакыйкатьне күрү. Эшләрнең тышкы тарафларына карап түгел, бәлки, хакыйкатенә карап бәя бирелергә тиеш.
- Эшне вакытында башкару. Бүгенге эшне иртәгә калдырмау дөнья көтүнең мөһим бер шарты.

Бер эшнең үз вакытында башкарылмавы аның бөтенләй эшләнми калуына сәбәп булырга мөмкин.

❖ Үз сүзеңдә нык тору. Һәртөрле киртәләр булуга карамастан, үзеңнең дөрес дип белгән фикереңдә нык тору.

❖ Үзеңә ышану. Һәрнәрсәне, башкалардан көтмичә, үзең булдыру.

❖ Гыйффәтле булу. Кешеләрне фәрештәләр дәрәҗәсенә күтәрә торган нәрсә – гыйффәтле булудыр. Хайваннардан да түбәнрәк дәрәҗәгә төшерә торган нәрсә – гыйффәтсезлекдер.

❖ Салкын кан белән фикер йөртү. Бу сыйфат кешеләрнең акыллары камил булуга бер дәлилдер.

## ДӨРЕСЛЕК

Хак мөэмин-мөселман барлык кешеләр белән дә гадел була. Ул яхшылыкның һәм бөек әхлакый сыйфатларның нигезендә дөреслек ятканын белә. Шул дөреслек аңа юл күрсәтә, аны җәннәткә илтә. Ялган исә кешене бозыклыкка юнәлтә.

Бер кеше, никадәр ялган сөйләмәскә тырышса да, әгәр ишеткән һәрбер сүзен кешеләргә сөйләп йөрсә, бервакыт ялган сөйләми калмас.

Башкаларны алдау ярамаган кебек, үзең дә башкалар тарафыннан алданудан сакланырга кирәк.

Гадел, тугры мөселман хәрәмләшми, алдашмый һәм хыянәт тә итми, чөнки дөреслекнең иң кирәкле шарты булып эчкерсезлек, гаделлек, күңел сафлыгы һәм тугрылык тора. Ә инде ялганга, гаделсезлеккә, хыянәткә һәм хәйләкәрлеккә анда урын юк.

# ТУГРЫЛЫК

Тугрылык – сүзләребездә, эшләребездә һәм хәрәкәтләребездә дөрес булу димәктер.

Тугры кеше ялган сөйләмәс, беркемне дә алдамас, башкаларга карата хәйлә кормас. Тугрылыкны Аллаһ мөселманнарга фарыз кылган. Бик күп аять һәм хәдисләрдә тугрылыкның әһәмияте аңлатылган. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дигән: *«Әй, мөэминнәр, Аллаһыдан куркыгыз һәм тугрылар белән бергә булыгыз».* (Тәүбә - 119)

Мөселман – сүзе үзенә, үзе сүзенә килешкән кешедер. Мөселман күренгәне кебек булыр, булганы кебек күренер.

Мөселман кулы һәм теле белән башкаларга зарар итмәс. Үзе өчен теләгән нәрсәне мөселман кардәше өчен дә теләр. Мөселман хәләл малына һәм акчасына хәрәм катыштырмас. Гаиләсенә һәм балаларына хәрам ризык ашатмас. Пәйгамбәребез бер хәдисендә болай дигән: *«Мөселманга зарар иткән һәм аны алдаган кеше бездән түгел».*

Коръәндә Аллаһы Тәгалә болай дигән:

*«Киметеп үлчи торган үлчәү кулланганнарга каты газап бардыр. Алар кешеләрдән сатып алганда төгәл иттереп үлчәтеп алырлар, ләкин сатканда ким үлчәп сатарлар».* (Мутаффифин – 1-3)

Кеше белмәс, сизмәс дип мондый эшләрне эшләргә һич ярамый. Чөнки эшләгән эшләребезне Аллаһ һәрвакыт күреп тора. Кирамән Кәтибин фәрештәләре гөнаһ һәм савапларыбызны язып баралар. Кешеләрне алдасак та, Аллаһыны алдау мөмкин түгеллекне истән чыгарырга ярамый.

Чын һәм эчкерсез мөселман үзенең тугрылыгы һәм эчкерсезлеге белән аерылып тора. Ул, кешеләр

белән аралашканда, төрле авырлыклар һәм уңайсызлыклар белән очрашуга карамастан, хәйләләми, аңлашылмаган һәм ялган сүзләр сөйләми.

Аллаһы Тәгалә әйткән:

*«Дөреслектә, иман китергән кешеләр: "Безнең тәрбиячебез – Аллаһ!"– диярләр дә, иманда, диндә һәм тормышта тугры, гадел һәм нык булырлар. Үлгән вакытларында аларга рәхмәт фәрештәләре иңәр һәм: "Сез – хак мөэминнәрсез. Үлемнән һәм Ахирәт газапларыннан курыкмагыз! Бәлки, үзегезгә вәгъдә ителгән җәннәтнең сезгә бирелүенә шатланыгыз!"– диярләр. Без сезнең белән дөньяда һәм Ахирәттә дусларбыз. Үзегезгә әзерләнгән җәннәттә күңелләрегез ни теләсә – шул булыр, анда сезгә ни сорасагыз – шул бирелер. Ярлыкаучы һәм рәхмәт Кылучы Аллаһ тарафыннан әзерләнгән төрле яхшы ризыклар булганы хәлдә».* Фүссыйләт-30,32.

Тугрылыктан тайпылмаучы мөэминнәрне менә нинди зур бүләкләр көтә! Рәхмәт фәрештәләре аларга менә нинди куанычлы хәбәрләр китерәләр! Боларның барысы да тугрылыкның никадәр югары һәм бөек дәрәҗәдә булуын күрсәтә. Бу нәрсәгә бары тик Аллаһыдан хакыйкый куркучы, Аллаһыга чын күңелдән гыйбадәт кылучы һәм бу дөньяда байлык, югары дәрәҗә һәм башкаларга баш ию богауларыннан азат булганнар гына ирешә.

Йөрәгенә Ислам тәрбиясе сеңгән чын мөселман үз вазифасына тугрылыклы һәм биргән вәгъдәләрен үтәүче була. Бу сыйфатлар аның җәмгыятьтәге урынын билгеләүче иң мөһим үзенчәлек булып тора. Бу үзенчәлек аны тагын да дәрәҗәлерәк итә. Мондый сыйфатка ия булу мөселманның хак динле булуын күрсәтә.

## ТЫРЫШЛЫК

Ислам – тырышлык дине. Аллаһы Тәгалә тырышуны да гыйбадәтләрнең берсе итеп санаган һәм Коръәндә шулай боерган: *«Аллаһының сиңа биргәне белән ахирәт бәхетен эзлә. Дөньядан да өлешеңне онытма ...»* (Касас - 77)

Дөнья тормышы өчен тырышмаган милләтләр ярлы булып калып, башка милләтләргә мохтаҗ булалар, көч-куәтләрен югалтып, башка милләтләрнең кул астына төшәләр. Мондый милләтләр ул вакытта үзләренең гыйбадәтләрен төгәл итеп үти алмыйлар, мәдәният һәм мәгърифәттән аерылып балалары надан булып калалар. Бу милләтләрнең диннәре, иманнары зәгыйфьләнеп, дөнья кайгысыннан диннәрен кайгыртырлык хәлләре калмас, алар тормышта авыр хәлләргә төшәрләр.

Дөньяга артык бирелеп ахирәтен оныткан кешеләрнең хәлләре дә моңа охшый. Дин, иман зәгыйфьләнеп, мәчетләрдә намаз укучылар азая, кешеләр арасында өлфәт һәм мәхәббәт бетә, кешеләрнең дәрәҗәсе акча белән генә үлчәнә башлый. Тәкәбберлек арта, дуслык һәм кардәшлек кими. Бу хәлләрнең икесе дә аяныч. Шуның өчен мөселман дөнья тормышын да дөрес итеп алып барырга, ахирәтне дә онытмаска тиеш.

Пәйгамбәребез бер хәдисендә болай дигән: *«Чын мөселман ахирәттән дә, дөньядан да ваз кичмәс. Дөньясын калдырып, бары тик ахирәте өчен генә тырышучыгыз хәерле, яхшы мөселман түгел. Ахирәтен калдырып бары тик дөньясы өчен генә тырышучыгыз да хәерле мөселман түгел. Кешенең хәерлесе, яхшысы дөньясы өчен ахирәтен калдырмас, ахирәте өчен дөньясын калдырмас,*

*икесен дә бергә алып барыр һәм башкаларга йөк булмас».*

Дөньяда да, ахирәттә дә бәхетле яшәү – мөселманның хакыдыр. Кайбер мөселманнар дөнья – кяфернеке, ахирәт мөселманныкы дип ышандырырга тырышалар. Ягъни мөселманнарга дөньяда, ахирәттә кяферләргә рәхәт юк димәкче булалар. Яисә дөньяда кяфер, ахирәттә мөселман бәхетле, дип сөйлиләр. Юк, Аллаһы Тәгалә бу дөньяны үзенә ышанган коллары өчен бар иткән. Мөселман кеше бу ике җиһанда да бәхетле булырга тиеш.

Пәйгамбәребезнең иң күп кылган догаларыннан берсе: *«Әй, Раббыбыз, безгә дөньяда да, ахирәттә дә яхшылык бир. Безне җәһәннәм утыннан сакла»,* дигән догадыр.

Дөньяда бәхетле булыр өчен, ахирәтне онытмыйча, тырышлык белән яшәргә кирәк. Чөнки дөнья тормышы фанидыр, ул бик тиз үтеп китәчәк, мәгәр ахирәт тормышы гына мәңгелек.

Пәйгамбәребез бер хәдисендә болай дигән: *«Дөнья ахирәтнең кырыдыр. Ул кырга нәрсә чәчсәң, ахирәттә шуны урырсың».*

Бер галимнең әйтүенчә, дөньяда ике төрле кеше бар: берсен дөнья алдый, чөнки ул Аллаһыны да, ахирәтне дә оныткан, дөнья тормышы өчен генә тырыша, икенчесе дөньяны алдый, чөнки ул дөнья өчен дә, ахирәт өчен дә тырыша, икесен дә бергә алып бара. Сез дә икенчесе кебек булыгыз, дөнья сезне алдамасын, сез дөньяны алдагыз.

## МӘРХӘМӘТЛЕЛЕК

Аллаһы Тәгалә Рахман һәм Рахим, ягъни колларына дөньяда да, ахирәттә дә бик шәфкатьле вә миһербанлыдыр. Шуның өчен мәрхәмәт илаһи бер тойгыдыр. Мөселман каты йөрәкле, каты күңелле түгел, киресенчә, мәрхәмәтле һәм йомшак күңелле булырга тиеш. Аллаһының рәхмәте һәм мәрхәмәте чиксез. Аларның бик кечкенә өлеше генә кешеләргә бирелгән. Пәйгамбәребез бер хәдисендә: *«Аллаһы Тәгалә Үзенең рәхмәтен йөз өлешкә аерды. Туксан тугыз өлешен үзе янында калдырып, бер өлешен генә җир йөзенә төшерде. Менә бу бер өлеш рәхмәт аркылы кешеләр бер-берләренә мәрхәмәт күрсәтәләр...».*

Каты күңелләр, башкаларга золым һәм газап кылучылар дөньяда да, ахирәттә дә бәхетле була алмыйлар. Ислам дине каты күңелле булуны хәрам кылган. Беркөнне Пәйгамбәребез оныгын, хәзрәти Хәсәнне кочаклап үпкән вакытта бер сәхабә аны күреп: «Димәк, сез балаларны үбәсез икән. Минем ун балам бар, мин аларны беркайчан да үпкәнем юк», – дигән. Пәйгамбәребез бу кешегә исе китеп караган да, әйткән: *«Мәрхәмәт итмәгән кешегә мәрхәмәт кылынмас».* Башка бер хәдисендә Пәйгамбәребез болай дигән: *«Кешеләргә мәрхәмәт кылмаган кешегә Аллаһ та мәрхәмәт кылмас».*

Бу хәдисләрдән күренгәнчә, мәрхәмәтсез һәм каты күңелле кешеләргә Аллаһының да мәрхәмәте булмас.

Ислам дине мөселманнарны бер гәүдә әгъзалары кебек күрә. Гәүдәнең әгъзалары, бер-берләренә булышып, ярдәмләшеп, гәүдәнең сәламәтлеген саклаган кебек, мөселманнар да, бер-берләренә

таянып, бер-берләренең кайгыларын уртаклашып, мәрхәмәт һәм шәфкать күрсәтеп, араларындагы сөю вә хөрмәтне арттырып, барлыкны дәвам иттерергә тиешләр. Коръәндә Аллаһы Тәгалә әйткән: *«Минем рәхмәтем вә мәрхәмәтем һәрнәрсәне урап алган».* (Әгъраф - 156)

Ислам дине тарафыннан безгә васыять ителгән мәрхәмәт бөтен кешелекне, хәтта бөтен барлыкны урап алган. Мөселман кеше кешелеккә карата гына түгел, хайваннарга да мәрхәмәтле булырга тиеш. Зарарсыз хайваннар үтерелмәс. Ач һәм сусыз калдырып, яисә кыйнап газап кылынмас. Ислам динендә кешеләрнең генә түгел, хайваннарның да хак һәм хокуклары бар.

Бервакыт Пәйгамбәребез үзенең сәхабәләренә җәһәннәмлек бер хатын турында сөйләгән. Бу хатын, мәчесенә ачуланып, аны бер бүлмәгә ябып куйган. Мәчесенә аш та, су да бирмәгән, һәм шулай итеп, мәченең ачка үлүенә гаепле булган.

Ислам дине безне кешеләргә генә түгел, бәлки бөтен җан ияләренә дә шәфкатьле вә мәрхәмәтле булырга өнди.

## ОЯТ-ХӘЯ

Хәя – оялу, Аллаһыдан куркып, начар эшләрдән саклану, тартыну димәктер.

Мөселман кеше өчен иң мөһим нәрсәләрдән берсе – хәядер. Әгәр кешеләрдә әдәп, хәя, Аллаһы Тәгаләдән курку һәм үзен тота белү булмаса, дөнья тормышының тәртибе бозылачак. Әгәр кеше эшләгән хата, кимчелекләреннән оялмаса, Аллаһыдан курыкмаса, аны начар һәм ямьсез эшләрдән туктатып булмаячак. Бу вакытта мәмләкәтләр явыз

кешеләр кулында калып, тормышның рәхәтлеге һәм тынычлыгы бетәчәк.

Оят-хәя барлык кешеләрдә дә бертөрле булмый. Кайбер кешеләр ялгышлык белән генә берәр хата эшләсәләр дә, көннәр буе оялып йөриләр. Кайберләре исә зур гөнаһлар, гафу ителмәслек хаталар эшләсәләр дә, бер дә исләре китми. Чөнки алар, кызганычка каршы, оят-хәяләрен, вөждан тойгыларын югалтканнар. Шуның өчен, Ислам дине оят-хәяне кешеләрне ямьсез эшләрдән туктатучы калкан, зур гөнаһлардан саклаучы чара дип кабул иткән.

Пәйгамбәребез бер хәдисендә болай дигән: *«Оялмаган кеше теләгәнен эшләсен».*

Димәк башкалардан оялмаган кеше һәртөрле начар эшләргә дә сәләтле. Чөнки Пәйгамбәребез әйткән: *«Кешеләрдән оялмаган, Аллаһыдан да оялмас».*

Кешеләрнең оялуы ике төрле була: Аллаһыдан оялу, кешеләрдән оялу.

Әлбәттә Аллаһыдан оялу кешеләрдән оялудан өстен, чөнки Аллаһыдан оялу кешеләрне һәртөрле явызлыклардан һәм усаллыклардан туктата.

## САБЫРЛЫК

Сабырлык - түземле булу, авыр хәлләр килгәндә чыдам булып, үзеңә хуҗа булу, ямьсез сүзләр һәм начар хәрәкәтләрдән үзеңне тыя белүдер.

Бу дөнья – бер имтихан дөньясыдыр. Кеше дөньяда төрле хәлләр белән очраша. Кайбер хәлләр кешене шатландырса, кайберләре исә кайгыга сала. Шатлык вакытында шөкерле, кайгы вакытында сабырлы булу иманның ныклыгына бер ишарә.

Пәйгамбәребез бер хәдисендә бодай дигән: *«Мөселман шатлыклы хәлендә шөкер кылыр. Бу аның өчен бер хәердер. Кайгылы вакытында сабыр итәр. Бу да үзе өчен бер хәердер. Мөселманның хәле гаҗәптер, һәр эшендә аңа саваn бар».*

Сабырлык – мөселманның коралыдыр, ләкин шулай да сабырлыкны дөнья тормышыбызда белеп кулланырга кирәк. Хәлебездән килеп тә берәр эш белән мәшгуль булмасак, ярлылыкка риза булсак – ялкаулык басар. Аллаһ шулай язган дип, ярлылыкка баш июнең, әлбәттә, сабырлык белән һич кенә дә уртаклыгы юк. Хак һәм хакыйкать каршысында, авызыңны ябып, берни әйтми тору да сабырлык түгел, чөнки Пәйгамбәребез әйткәнчә: *«Хакыйкать каршысында авызын япкан кеше – телсез шайтандыр».*

Сабырлык өч төрле була.

1. Бәла, казаларга карата булган сабырлык.

Әгәр каза Аллаһ колының малына, җанына һәм баласына төшсә, кешенең бу бәхетсезлекне туктатырга көче дә, белеме дә җитмәсә, ул вакытта риза булып сабыр итәр. Зилзилә, су басулар, сугышлар кебек хәлләрдә авырлыкларга чыдап, сабыр итәргә кирәк. Сабырлыкның савабына ышанмаганнар, бәхетсезлекләр каршысында өметсезлеккә төшеп, дөньядан бизәрләр, алар өчен тормышның тәме калмас. Коръәндә Аллаһы Тәгалә әйткән: *«Сезне бераз курку һәм ачлык белән, малларыгызны, җаннарыгызны вә җимешләрегезне бераз киметеп имтихан кылырбыз. Син сабыр итүчеләргә сөенеч бир».* Коръән аяте. (Бәкара - 155)

Димәк, кеше дөньяда дәвамлы имтихан тота. Аллаһы Тәгалә хәятне һәм үлемне кешеләрне сынар өчен биргән. Ул, кешене төрле хәлләргә куеп,

сынап карый. Бу имтиханның шарты – сабырлыктыр. Бер куддүси хәдисендә Аллаһы Тәгалә: *«Мин колларымнан берсенең җанына, малына яисә баласына зарар иткәндә, әгәр колым ул бәлане сабырлык белән кабул итсә, мин ул колым өчен мизан корып, гамәл дәфтәрен ачудан, ягъни Кыямәт көнендә җавап алудан азат итәрмен»,* – дигән.

2. Гыйбадәтләрне сабырлык белән кылу.

Сабырлыкның икенче бер мөһим өлеше – гыйбадәтләрне сабырлык белән кылуга карый. Гыйбадәтләрдәге кыенлыкларны сабырлык белән кылган кешене Аллаһы Тәгалә зур дәрәҗәләргә ирештерер. Озын кызу җәй көннәрендә ач һәм сусыз калып, ураза тоту, кыска төннәрдә, кояш чыкмастан әүвәл торып, иртәнге намазны уку, биш вакыт намазны вакытында һәм калдырмыйча үтәп бару, Мәккә, Мәдинәгә барып, хаҗ кылу, бай кешеләргә һәр ел малының һәм акчасының кырыктан бер өлешен зәкят нияте белән ярлыларга бирү кебек гыйбадәтләрне җиренә җиткереп үтәүнең, әлбәттә, үзенә күрә авырлыклары да бар. Бу авырлыкларга сабырлык белән түзеп кенә Аллаһының ризалыгын казанырга мөмкин.

Ислам динендәге гыйбадәтләр һәрвакыт сабырлык белән генә кылына. Динебезнең максаты кешене чыдамлы итеп тәрбияләү, шуның нәтиҗәсендә аны дөньяда һәм ахирәттә бәхетле итү. Мәсәлән, хаҗ гыйбадәте дә – бер сабырлык гыйбадәтедер. Сабыр итми авырлыкларга чыдый алмаган кеше, бу гыйбадәтнең савабыннан мәхрүм калыр. Шулай ук ураза гыйбадәте дә шундый гыйбадәтләрдән санала.

Пәйгамбәребез Рамазан аена кадәр унбиш көн элек сөйләгән бер вәгазендә болай дигән: *«Бу ай*

*сабырлык аедыр. Сабыр итүчеләрнең барачак урыны җәннәттер».*

Димәк, гыйбадәтләрдән булган максатларның берсе – кешеләрне сабырлыкка күндерүдер.

3.Гөнаһ эшләрне кылмауда сабыр итү.

Кеше үзенең тормышында изге эшләр эшләгән кебек хата һәм гөнаһлы эшләр дә эшләргә сәләтле. Аллаһының хәрам кылган эшләреннән үзен читкә тартып сабырлык күрсәтүчегә зур саваблар бар. Кеше бер яктан Аллаһының әмерләре, икенче яктан нәфесе, ягъни начар теләкләре, уйлары һәм шайтанның хәйләсе белән каршылыклы хәлдә яши. Мондый чакларда кеше, шайтанга ияреп, Аллаһ юлыннан тайпылса, зур гөнаһларга дучар булыр. Кешенең эчендә начар эшләргә өндәгән бер көч, бер куәт яши. Бу куәткә «нәфсе әммәра» диләр. Бу көч белән көрәшү, шушы көч өндәгән начар ниятләргә каршы тору динебезнең әмерләреннән санала. Бу уңайдан Пәйгамбәребез болай дигән:

*«Көрәштә иптәшләрен җиңгән кеше түгел, ә нык ачуланган хәлдә, сабыр итеп, үз ачуын җиңгән кеше көчле кеше була».*

## ШӨКЕР ИТҮ

Шөкер итү – кешенең үз хәленнән канәгать булып, Аллаһыга рәхмәтләрен белгертүе димәктер. Шөкер итү – Аллаһыны олылау, Аллаһыны зурлаудыр. Шөкер итү – Аллаһы Тәгалә биргән санаусыз нигъмәтләрнең кыйммәтен аңлап, аларны Аллаһ юлында куллануудыр.

Аллаһы Тәгалә кешеләргә санаусыз нигъмәтләр биргән. Ашау-эчүләребезне бар иткән, саулыкта яшәткән бөек Зат – Аллаһы Тәгаләдер. Акыл,

рух гәүдәбезгә, көч-куәт биреп, төрле эшләрне тормышка ашырырга мөмкинлек бирүче – Аллаһтыр. Безнең өчен табигатьтәге һәрнәрсәне; һаваны, суны, җимешләрне, шулай ук барча хайваннарны бар итүче – Аллаһтыр. Кеше барлыкларның иң хөрмәтлесеедер. Шулай булгач, ул Аллаһы Тәгаләгә шөкер кылырга һәм бу нигъмәтләрнең чын Хуҗасын һәрвакыт олылап искә алырга тиеш.

Коръәндә Аллаһы Тәгалә болай дигән: *«Әгәр Аллаһының нигъмәтләрен санарга тотынсагыз, санап бетерә алмассыз».* (Ибраһим - 34)

Дөнья тормышыбызда кемнән булса да ярдәм күрсәк, аның нинди дә булса нигъмәтенә ирешсәк, аңа рәхмәтләр укыйбыз, ул кешегә хөрмәтебезне белдерергә тырышабыз. Шуның кебек санаусыз ярдәмнәре һәм нигъмәтләре өчен без Аллаһы Тәгаләгә һәрдаим шөкер кылырга тиешбез.

Шөкер өч төрле була.

1. Калеб, йөрәк белән шөкер итү. Һәрбер нигъмәтнең Аллаһ тарафыннан бирелгәнлегенә чын йөрәктән ышану.

Безгә ирешкән нигъмәтләрнең барысы да Аллаһыдандыр. Моңа инанган мөэмин-мөселман байлыкка һәм нигъмәткә ирешсә, Аллаһ юлыннан бервакытта да тайпылмас, бу нигъмәтләрнең Аллаһыдан килгәнен онытмас. Нигъмәте арткан саен шөкере дә арта барыр. Нигъмәткә шөкер итү нигъмәтне арттырыр. Нигъмәтнең кыйммәтен белмәү нигъмәтнең бетүенә сәбәп булыр.

Аллаһы Тәгалә әйткән:

*«Әгәр сез, биргән нигъмәтләремә шөкер итсәгез, мин ул нигъмәтне арттырырмын. Әгәр куфран кылсагыз, нигъмәтнең кадерен белмәсәгез минем газабым бик катыдыр».* Коръән аяте. (Ибраһим - 7)

2.Тел белән шөкер итү. Һәрбер нигъмәтнең Аллаһыдан килгәнлеген танып, тел белән шөкер әйтү.

Пәйгамбәребез бер хәдисендә әйткән:

*«Әгәр Аллаһ үзенең колына бер нигъмәт бирсә һәм кол «Әлһәмду лилләһ», дисә, ул бу нигъмәтнең шөкерен үтәгән булыр. Кол икенче мәртәбә, «Әлһәмду лилләһ», дисә, Аллаһы Тәгалә ул кешенең савабын арттырыр, өченче мәртәбә, «Әлһәмду лилләһ», дисә, Аллаһ ул кешенең гөнаһларын гафу итәр».*

Әгәр кеше шөкер кылса, Аллаһ аның күңеленә канәгатьлек, тормышына рәхәтлек вә тынычлык бирер. Ә шөкер кылмаучылар күпме баесалар да, күңелләре кайгыдан котылмас. Чөнки шөкерсез малның һәм шөкерсез гомернең бәрәкәте булмас.

3. Әгъзалар белән булган шөкер. Әгъзалар белән шөкер кылу – Аллаһыга гыйбадәт кылу, Аллаһының диненә хезмәт итүдер.

Намаз уку, ураза тоту, хаҗ кылу кебек гыйбадәтләр белән бергә Аллаһының динен аңлату, тарату һәм бу юлда хезмәт итү дә әгъзалар белән булган шөкердер.

Шөкер пәйгамбәрләрнең, фәрештәләрнең һәм Аллаһының сөекле колларының гадәтләреннәндер. Шөкерне торган саен арттыра барырга кирәк. Чөнки нигъмәтнең дәвамлы булуына сәбәп булган иң мөһим нәрсә – шөкердер. Шөкер кылучы һичбер вакыт Аллаһыны онытмас. Андый кеше дөньядагы нигъмәтләре белән тәкәбберләнеп, кешеләргә өстән карамас, беркемне дә түбән күрмәс. Нигъмәт ягыннан үзеннән түбәнрәк булган кешеләрнең хәленә карап, алардан дөрес гыйбрәт алыр, үзенең хәленә шөкер итәр.

# ОЛЫЛАРНЫ ХӨРМӘТ ИТҮ, САБЫЙЛАРНЫ СӨЮ

Барлыклар арасындагы иң өстене, иң хөрмәтлесе – кешедер. Аллаһы Тәгалә бу хакта Коръәндә болай дигән: *«Без кешене иң мөкәммәл рәвештә бар иттек, яралттык».* (Тин - 4)

«Кешегә карасаң, әлбәттә Аллаһының бөек көч-кодрәтен күрерсең, чөнки кеше кадәр мөкәммәл затны бары тик Аллаһы Тәгалә генә яралта ала», – дигәннәр Ислам галимнәре.

Аллаһ кешене хөрмәт белән бар иткән. Пәйгамбәребез дә һәрвакыт кешеләрне хөрмәт кылу белән боера торган булган. Бер хәдисендә ул болай дигән: *«Олыларга хөрмәт, кечкенәләргә шәфкать күрсәтмәгән кеше бездән түгел».*

Пәйгамбәребез башкаларга һәрвакыт шәфкать һәм мәрхәмәт күрсәткән. Аның якын көрәштәшләреннән булган Әнәс р.г. болай дигән: *«Мин Пәйгамбәребезгә ун ел хезмәт кылдым. Шул вакыт эчендә мин аның бер мәртәбә дә ямьсез сүз сөйләгәнен ишетмәдем, бер тапкыр да, бу эшне ник болай эшләдең, дип ачуланганын күрмәдем».*

Бервакыт Пәйгамбәребезгә: *«Әй, Аллаһының илчесе, дошманнарыңа ләгънәт укы. Аллаһ аларга бәла-каза китерсен. Аллаһ аларга җәзасын бирсен»,* – дигәннәр Пәйгамбәребез аларга: *«Мин кешеләргә ләгънәт укучы түгел, ә рәхмәт кылучы буларак җибәрелдем»,* – дип җавап биргән.

Пәйгамбәребез дус-ишләрен вә танышларын ярата, картларны хөрмәт итә торган булган. Кайбер вакытларны уен-көлке сөйләргә дә яраткан. Беркөнне Пәйгамбәребезнең өенә бер карчык кергән. Пәйгамбәребез аны зур хөрмәт белән каршы

алган. Кара-каршы бик күңелле сөйләшеп торганда ул хатын Пәйгамбәребезгә болай дигән: «Әй, Аллаһның илчесе, безгә дога кылсаң иде, синең доганң белән җәннәткә керсәк иде». Пәйгамбәребез аңа: *«Синең кебек карчыкларны Аллаһ җәннәткә кертми»,* – дигән. Ул карчыкның кайгырганын күргәч, Пәйгамбәребез: *«Юк, кайгырма, мәзәк итеп кенә әйттем. Син иншаллаһ җәннәткә кергәндә яшь кыз хәлендә булачаксың, Аллаһ кешеләрне яшәртеп җәннәткә кертәчәк»,* – дигән.

Олыларны хөрмәт итү дөнья тормышыбызның бәрәкәтен арттырыр. Аллаһы Тәгалә аларның догаларын кабул итеп, кечкенәләргә мәрхәмәт кылыр, ризыкларына бәрәкәт иңдерер.

Бер мәҗлестә Пәйгамбәребезгә бер чынаяк ширбәт тәкъдим иткәннәр. Пәйгамбәребез үз чиратында ширбәтне үзеннән өлкәнрәк булган Әбү Гобәйдә исемле сәхабәгә тәкъдим иткән. Әбү Гобәйдә: «Әй, Аллаһының илчесе, беренче булып син эч. Син миннән лаеклысың, син пәйгамбәрсең», – дигәч, Пәйгамбәребез: *«Син эч. Бәрәкәт картларыбыздадыр»,* – дигән, һәм беренче итеп ширбәтне аңа эчерткән.

Пәйгамбәребез балаларны бик яраткан һәм башкаларга да яратырга кушкан. Балаларны күрсә, мөбарәк йөзе нурланып, аларны кочаклый торган булган. Урамда очраган балалар белән сәламләшә, алар белән әңгәмә корып, вакыт-вакыт аларга кызыклы хәлләр дә сөйли торган булган. Дөягә атланып барган чагы булса, аларны дөясенә атландырган. Хәтта бервакыт балалар белән ярышта катнашып аларны шатландырган. Усәмә бине Зәед тарафыннан китерелгән бер хәдистә: *«Пәйгамбәребез мине бер тезенә, оныгы Хәсәнне икенче тезенә*

*утырта иде, безне кочаклап: «Аллаһым, боларга мәрхәмәт әйлә, тәүфыйклы, бәхетле кыл. Мин боларның хәерле һәм бәхетле булуларын телимен», – дип дога кыла иде»,* – дигән.

Сабый балалар дөнья тормышының бизәге, олылар дөнья тормышының бәрәкәте. Шуның өчен сабый балаларны сөю, олыларга хөрмәт күрсәтү динебезнең нигез ташларыннан санала.

## ХАКЛАР

Хак – тугрылык, дөреслек, гадәләт, башкаларга карата булган нәрсә, бер эш һәм хезмәт өчен алыначак түләүдер. Ислам динендә ике төрле хак бар:

1. Аллаһ хакы.
2. Кеше хакы.

Аллаһ Үзе белән кеше арасындагы хакларны теләсә гафу итәр, чөнки ул хаклар Аның үзенә караган, Аңа бәйләнешле булган хаклардыр. Ләкин кеше хакын бары тик кеше гафу итәр, Аллаһ гафу итмәс. Шуңа күрә мөселманнар сәфәргә чыкканда, хаҗга киткәндә, кемнең дә булса хәтерен калдырганда яисә кемнең дә булса малына яки җанына зарар китергәндә үзара бәхилләшәләр, бер-берләреннән гафу үтенешәләр. Моның максаты – кеше хакыннан котылудыр. Чөнки Аллаһ гафу итми торган гөнаһларның берсе – кеше хакыдыр.

Вафатыннан берничә көн элек Пәйгамбәребез, мәчеткә барып, намаз укыткан һәм шунда әйләнә-тирәдәге кешеләргә: *«Әй, кешеләр! Арагызда кемгә зарар иткән булсам, әйтсен, бәхилләтермен, кемгә суккан булсам, килеп миңа суксын. Кемнәргә бурычым булса, әйтсен, түлим»,* – дигән. Шунда берәү басып: *«Беркөнне, янызда акчагыз булмагач,*

*бер ярлыга сәдака бирергә дип, миннән өч дирхәм акча алган идегез»,* – дигән. Пәйгамбәребез, хәтеренә төшереп, ул кешегә бурычын түләп, рәхмәтләрен әйткәннән соң: *«Ахирәттә Аллаһының алдында оялудан күрә, дөньяда кешеләр алдында оялу яхшырактыр»,* – дигән.

Мөселман көндәлек тормышында башка мөселман кардәшенең малына һәм җанына зарар итмәс, аларны теле яки кулы белән рәнҗетмәс. Әгәр боларны эшләсә, мөселман кардәшеннән гафу сорар һәм аның белән бәхилләшер.

Пәйгамбәребез янә әйткән: *«Кемдә кеше хакы булса, вафат булмастан әүвәл алар белән бәхилләшсен. Чөнки кыямәт көнендә кешенең малы аңа ярдәм бирмәс».*

Пәйгамбәребезнең хәдисләреннән аңлашылганча, башкаларның малына яки җанына зарар иткән, сүз белән рәнҗеткән, мөселман кардәшләре турында яман ният белән фикерләр йөртүче аларның хакларына зарар китергән булып санала.

Кыямәт көнендә Аллаһ гаделлек белән хөкем кылачак, хак ияләренә хакларын тапшырачак. Дөньяда эшләгән усаллыклар беркемгә дә табыш булып бармаячак.

## ГАДЕЛЛЕК

Гаделлек – хакка һәм дөреслек ягына авышу, золымны ташлап, хакны хак иясенә тапшыру, эшләребездә, гамәлләребездә һәм сүзләребездә дөрес юлны тоту димәктер.

Кешеләрнең бәхете үзара гаделлек белән генә була. Гаделсез халыклар һәм мәмләкәтләр озын гомерле булмыйлар.

Ислам әхлагында гаделлек мәсьәләләренә зур әһәмият бирелә. Аллаһы Тәгалә әйткән:

*«Аллаһы Тәгалә гадел булырга, изге эшләрне эшләргә, ярлы кардәшләребезгә ярдәм итәргә куша. Һәм сезләрне начар ямьсез эшләрдән, кешеләргә золым кылудан тыя...»* Коръән аяте: (Нәхел - 90)

Каинәтнең һәм дөньяның тәртибе гаделлеккә бәйле. Гаделлек булмаган җирдә золым хөкем сөрә. Золым исә, Ислам динендә иң зур гөнаһлардан санала. Пәйгамбәребез бер хәдисендә болай дигән: *«Көферлек, динсезлек дәвам итсә дә, ләкин золым дәвам итмәс»*.

Тарих атаклы залимнарны хәтерли, ләкин аларның золымнары мәңге дәвам итә алмаган һәм киләчәктә дә дәвам итә алмаячак.

Аллаһы Тәгалә әйткән:

*«Әгәр кешеләр арасында хөкем кылсагыз, гаделлек белән хөкем кылыгыз»* Коръән аяте: (Ниса - 58)

630 елда, Мәккә шәһәре мөселманнар тарафыннан алынган вакытта, кабиләнең алда килгән кешеләреннән берсенең хатыны, ганимәт малларыннан кайбер кыйммәтле әйберләрне урлаган. Пәйгамбәребез, бу хәлне ишеткәч, ул хатынга җәза бирергә булган. Ләкин кайбер кешеләр, уртага чыгып, болай дигәннәр: «Әй, Аллаһының илчесе! Бу хатын мәшһүр бер кабиләдән, шөһрәтле бер хатындыр. Бу хатынга җәза бирмәсәгез һәм аны гафу итсәгез иде». Пәйгамбәребез аларга болай дип җавап биргән: *«Сездән элек яшәгән милләтләр, бер мәшһүр һәм бай кеше урласа, бер җәза да бирмичә, аны гафу итәләр иде. Бер ярлы яки зәгыйфь кеше урласа, аңа җәза бирәләр иде. Аларның бу гаделәтсезлекләре ул милләтләрнең юкка чыгуына*

*сәбәп булды. Аллаһ белән ант итеп әйтәм, әгәр кызым Фатыйма урласа, аңа да җәза бирер идем».*

Кеше кайда гына яшәмәсен, нинди генә вазифада булмасын, бай-ярлыга, дус-дошманга, яхшы-яманга, олы-кечегә аермыйча гаделлек белән хөкем ителергә тиеш.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә, Ниса сүрәсенең 135-нче аятендә, үзебезнең ата-аналарыбыз һәм якын туганнарыбызның зарарына булса да гадәләт белән таныклык кылырга куша. Гадәләт бары тик мәхкәмәдә генә булмыйча, мәмләкәтнең һәр җирендә булырга тиеш. Өйдә ата-ана балаларына, мәктәптә укытучы шәкертләренә, бай кешеләр кул астындагы эшче һәм хезмәтчеләренә гадәләтле булырга тиешләр. Мөселман, һәрвакыт Аллаһыны уйлап, Аллаһыдан куркып, сүзләрендә, гамәлләрендә тугры булырга тырышыр һәм һичбер вакыт гаделлектән аерылмас.

## ӘМАНӘТ

Әманәт – саклану өчен кемгә булса да тапшырылган нәрсә димәк.

Әмин – ышанычлы, беркемгә дә зарары тими торган, тыныч табигатьле, куркусыз кеше димәк.

Пәйгамбәребезгә пәйгамбәр булганчы ук «Мөхәммәт әл-Әмин», ягъни ышанычлы, имин кеше, дип әйтә торган булганнар.

Әманәт сүзенең төрле мәгънәләре бар. Пәйгамбәребез вафат булыр алдыннан өч ай әүвәл, хаҗ вакытында, йөз меңнән артык мөселманнарга Гарәфәт тавында сөйләгән саубуллашу вәгазендә түбәндәге сүзләр белән мөрәҗәгать иткән. *«Сезгә бер әманәтне калдырам. Ул әманәтне сакласагыз,*

*туры юлдан адашмассыз. Бу әманәт – Аллаһының китабы Коръән Кәримдер».*

Димәк, Коръән мөселманнарга бер әманәттер. Бу әманәтне ике күзебез кебек саклап, бездән соң киләчәк буыннарга да тапшыру безнең бурычыбыздыр. Әгәр динебезне сакламасак, изге китабыбызны өйрәнмәсәк, тора-бара динебез дә онытылыр. Үзебезгә тапшырылган әманәтне саклamаган өчен гөнаһлы булырбыз.

Дин һәм Коръән кебек үк җан да кешегә бер әманәттер. Җанны бирүче Аллаһтыр, вакыты җиткәч, бу әманәт тә кире алыныр. Үз-үзен үтергән кешеләр, Аллаһының бу әманәтенә хыянәт иткән өчен зур гөнаһлы булалар.

Безгә тапшырылган вазифалар да әманәт булып санала. Бу вазифаларны хәлебездән килгән кадәр җиренә җиткереп башкарырга тиешбез. Әгәр вазифаларыбызны, эшләребезне тиешенчә башкара алмасак, әманәткә хыянәт кылган булырбыз.

Кешелек өчен дәүләт һәм милләт тә бер әманәттер. Милләт эшләрен алып барачак кешеләрне сайлаган вакытта, яхшы кешеләрне сайлап, әманәтне лаеклы кешеләргә тапшыру да безнең әманәт бурычларыбыздандыр. Аллаһы Тәгалә әйткән:

*«Шик тә юк, Аллаһ сезгә әманәтләрне әһелләренә тапшырырга әмер кыла»* Коръән аяте. (Ниса - 58)

Дәүләт һәм милләт малы да бер әманәттер. Аларга зарар итү һәм үз файдабызга куллану шулай ук әманәткә хыянәт булып исәпләнә.

Хәзрәти Гомәр бер төнне хөкүмәт йортында милләт эшләрен башкарганда Габдрахман бине Гауф исемле бер сәхабә килгән. Сәламләшеп исәнләшкәннән соң хәзрәти Гомәр өстәленең тартмасыннан бер шәм чыгарып кабызган. Моңа кадәр

өстәл өстендә янып торган шәмне сүндереп, тартмага куйган. Иптәше хәзрәти Гомәрнең бу хәрәкәтенә карап торган да сораган: «Йә, Гомәр! Шәмнең берсен кабыздың, берсен сүндердең. Боларның икесе дә шундый ук шәм. Ник болай эшләдең?» Хәзрәти Гомәр болай дип җавап биргән: «Син килгән вакытта милләт эшен эшли идем. Ләкин син килгәч, эшемне калдырып, синең белән сөйләшә башладым. Синең белән сөйләшкәндә милләтнең шәмен яндырырга хакым юк. Шуның өчен, тартмадан алып, үз акчама алынган шәмне кабыздым».

Балалар да кеше өчен бер әманәттер. Аларны динле һәм әхлаклы итеп тәрбияләү, дини гореф-гадәтләребезне өйрәтеп, милли һәм дини тойгылар белән үстерү безнең әманәт бурычыбыздыр.

Безгә сер итеп кенә сөйләгән сүзләр дә үзенә күрә әманәттер. Пәйгамбәребез бер хәдисендә болай дигән: *«Берәр кеше сиңа нинди дә булса бер сүз сөйләгәндә тирә-ягына карап сөйләсә, ул сүз – бер әманәттер. Ул сүзне башкаларга сөйләмә»*.

Әманәтне сакламаган һәм әманәткә хыянәт кылган кешегә «хаин» диләр. Димәк, әманәтнең киресе хыянәттер. Безгә тапшырылган әманәткә зарар итү, эшләребезне, вазифаларыбызны җиренә җиткереп үтәмәү әманәткә хыянәт итү булып, мондый эшләр динебездә хәрам санала.

## ВӘГЪДӘДӘ ТОРУ

Кемгә булса да берәр вәгъдә бирсәк, аны җиренә җиткереп үтәү безнең дини вазифалардан санала. Ислам динендә, кайбер гыйбадәтләр фарыз кылынганы кебек, кайбер эшләр вә гамәлләр дә фарыз кылына. Боларның берсе – вәгъдәдә тору.

Вәгъдәдә тормау беркемгә дә зарардан башка файда китермәс. Вәгъдәдә тормаучылар үзләренә генә түгел, башкаларның да хак, хокукларына игътибар итмәсләр. Гадәттә мондый кешеләргә беркем дә ышанмый. Үз ихтирамнарын үзләре югалткан бу кешеләрне беркем дә хөрмәт итми. Вәгъдәдә тормаучылардан Кыямәт көнендә каты сорау алыначак. Аллаһы Тәгалә болай дигән:

*«Вәгъдә биргән вакытта вәгъдәгездә торыгыз. Әлбәттә, кеше Кыямәт көнендә вәгъдәсеннән сораlачактыр».* Коръән аяте. (Исра - 34.)

Шул ук сүрәдә Аллаһы Тәгалә кеше үтерү, зина кылу, киметеп үлчәү, ятим малын ашау, тәкәбберләнү кебек зур гөнаһлар белән бер рәттән вәгъдә бозуны да санаган. Пәйгамбәребез дә бер хәдисендә болай дигән: *«Монафыйкның өч галәмәте бар. Сүз сөйләсә, ялган сөйләр, вәгъдә бирсә, вәгъдәсендә тормас һәм әманәткә хыянәт итәр».*

Мөселман – дөреслек белән яшәүче кешедер. Ул алдау һәм ялган кебек начар холыклардан ерак тора. Пәйгамбәребез болай дигән: *«Вәгъдәдә тору иманнандыр».* Ягъни иманы булган һәр мөселман вәгъдәсендә торырга, вәгъдәсен җиренә җиткереп үтәргә тиеш.

## ЮМАРТЛЫК

Үз диненең үгет-нәсыйхәтләрен тотучы мөселман киң күңелле һәм юмарт була. Ул һәрвакыт юмартлык белән эш итә. Чөнки ул үз малыннан Аллаһ юлына өлеш чыгарганда, аның ике дөньяда да зур файда китерәчәген белә. Аллаһы Тәгалә әйткән: *«Байлыкларын Аллаһ юлында сарыф итүчеләр – һәрберсе йөзәр бөртекле җиде башак бирә*

*торган бөртек утыртучыга тиң. Ә Аллаһы Тәгалә теләгән кешесенә аннан да арттырып бирә. Аллаһы Тәгалә – һәрнәрсәне Колачлаучы, Белүчедер!»*

Аллаһ ризалыгы өчен тотылган чыгымнар мөселманнарның иҗтимагый тормышына зур файда китерә, чөнки дөнья тормышында матди як та зур әһәмияткә ия.

Юмартлык мөселманның иң яхшы сыйфатларыннан берсе булып санала. Нәкъ менә шуңа күрә бер сәхабәнең: «Исламда иң яхшы сыйфат кайсы?» – дигән соравына Пәйгамбәребез: *«Кешеләрне сыйла һәм танышларыңа да, таныш түгелләргә дә сәлам бир»,*– дип җавап биргән.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм үзенең сәхабәләрен гел юмартлыкка өйрәткән; һәм, алар муллыкта яшәп, Аллаһы Тәгаләне истән чыгармасыннар өчен, күңелләрендәге байлык җыю хисен бетерергә тырышкан.

## ҺӘР ИГЕЛЕК СӘДАКА

Ислам күрсәтмәләре нигезендә тәрбияләнгән кеше башкаларга файда гына китерергә, ә зыян китерергә мөмкин булган һәрнәрсәдән үзен сакларга тырыша. Чөнки ул яхшылыкның фәкать уңышка гына китерәчәген, һәм ул башкаларга яхшылык эшләү юлында ясаган һәр адымында Аллаһының рәхмәтенә юлыгачагын яхшы белә.

Мөхәммәд галәйһиссәләм әйткән:

*«Әгәр ачуланышкан ике кешене дуслаштырсаң, бу эшең сиңа сәдака булыр, әгәр кешегә атланып утырырга яки йөген куярга ярдәм итсәң, бу эшең дә сәдака булыр. Һәр яхшы сүз – сәдака; гыйбадәт кылу юлында ясалган һәр адымың – сәдака; юлдан*

*башкаларга зыян китерерлек нәрсәләрне алып ташлавың да – синең өчен сәдака булачак».*

Аллаһының рәхмәте бервакытта да Аңа баш иючене һәм Аның алдында үзенең теләкләрен ихлас күңелдән белдерүчене урап узмый. Шуның өчен ул яхшылыкка омтылып, эшләгән эшләре өчен генә түгел, ә, начарлыктан тыелып, хәтта эшләмәгән эшләре өчен дә әҗер-савап ала.

Мөхәммәд галәйһиссәләм әйткән:

*«Аллаһы Тәгаләдән курык! Иң кечкенә бер игелекне дә кадерсез санама һәм игътибарсыз калдырма. Хәтта су алырга килүченең чиләгенә су алып салуың да үзенә күрә бер игелектер. Тәкәббер һәм һавалы булудан бик саклан! Аллаһы Тәгалә тәкәбберлекне сөйми. Әгәр бер кеше синдә булган бер гаеп белән сине сүксә яки мәсхәрә итсә, син аның үзен анда булган гаепләр белән сүкмә, мәсхәрә кылма. Шулай итсәң – сиңа савап булыр, ә аңа гөнаһ язылыр. Һичкемне сүгүче булма».*

Мөселманнарга файда китерү һәм аларны зыян килүдән саклап калуның төп билгеләреннән берсе булып аларны бер-берсе белән дошманлашкан вакытта татулаштырырга омтылу тора.

Аллаһы Тәгалә әйткән:

*«Чынлыкта, мөэминнәр – туганнардыр; шуңа күрә, үзара дошманлашкан ике туганыгызның арасын төзәтегез, дуслаштырыгыз һәм Аллаһыдан куркыгыз!..»* Коръән аяте: (Хүҗүрат – 10)

Белегез: игелек – мактау һәм әҗернең хасил булуына сәбәп булыр. Әгәр игелекне кеше сурәтендә күрсәгез, сез аны матур, күз явын алырлык матур сурәттә күрер идегез, ә начарлыкны яман кыяфәтле, күңелне кайтаручы, карашны үзеннән бордыручы кеше сурәтендә күрер идегез.

## ИГЕЛЕККӘ КАРШЫ ҖАВАП БИРҮ

Мөселманның янә бер яхшы сыйфаты шул, ул үзенә кылынган яхшылыкка каршы үзенең рәхмәтен белдерергә онытмый.

Мөхәммәд галәйһиссәләм әйткән:

*«Әгәр берәү үзенә яхшылык кылган кешегә: «Аллаһ сиңа игелек белән түләсен!» – дисә, бу иң яхшы рәхмәт әйтүдер».*

Яхшылык эшләүчегә рәхмәт белдерү – кешенең теге яки бу файда алу мөмкинлегенә бәйле булган ихтирамлылык яки әдәплелек түгел, бәлки, дини таләпләргә туры килүче гадәттер. Исламның мөселманнар эчендәге бу гадәтне тәрбияләү омтылышы шул кадәр көчле ки, хәтта, игелек эшләүчегә рәхмәт кебек аның күңелен күтәрүче сүзләр әйтмәүче кеше яхшылыкның кадерен белмәүче һәм барлык изгелекләрне бирүче Аллаһыга шөкер кылмаучы булып санала. Бу хакта Аллаһ Илчесе болай дигән: *«Кешеләргә рәхмәт белдермәүче кеше Аллаһыга да шөкер кылмас».*

Игелек эшләүче кешегә рәхмәт белдерү яхшылыкларның артуына китерә һәм изге эшләргә мәхәббәт тәрбияли. Бу исә, җәмгыять әгъзалары арасында үзара ярату җепләрен ныгыта, йөрәкләрне мәхәббәт хисләрен белдерүгә сәләтле итә һәм күңелләрдә яхшылык эшләүгә теләк уята.

## БУРЫЧ ХӘЛЕ

Чын мөселман авыр хәлдә калучы кардәшенә бурычка дип бирәр нәрсә бирсә, аны түләтүне ашыктырмый, бәлки, хәле яхшырганчы вакыт бирә, яки бөтенләй гафу итә.

Аллаһы Тәгалә әйткән: *«Әгәр авыр хәлдә булса, хаәте яхшырганчы вакыт бирегез».* (Бәкара-280)

Димәк, әгәр берәү үзенә бурычлы кардәшенең авыр хәлдә икәнен күрсә, ул аның хәленә кереп, аңа вакыт бирергә, яки хажәтенең бер өлешен гафу итәргә тиеш. Моңа бүләк йөзеннән ул үзе дә Кыямәт көнендәге ачы хәсрәттән котылачак.

Аллаһ Илчесе әйткән:

*«Авыр хәлдә калучыга вакыт бирүчене яки бурычының бер өлешен гафу итүчене, Аллаһ Кыямәт көнендә – башка күләгәләр булмаган көндә – Үзенең Тәхете күләгәсенә кертәчәк».*

## КЕШЕ КАЙГЫСЫНА СӨЕНМӘҮ

Чын мөселман башкаларның кайгысына сөенү кебек түбән сыйфатлардан ерак тора.

Мөхәммәд галәйһиссәләм әйткән:

*«Кардәшеңнең кайгысына сөенмә, чөнки Аллаһы Тәгалә аңа рәхим-шәфкать кылырга, ә сиңа бәлә-каза җибәрергә мөмкин».*

Ислам рухын сеңдергән чын мөселман кеше кайгысына сөенми, киресенчә, аның хәлен җиңеләйтергә тырыша. Ислам рухыннан ерак торган, үч алырга яратучы, усал ниятле, явыз фикерле һәм гайбәт сөйләүче авыру рухлы кеше генә башкаларның кайгысына сөенә. Мөхәммәд г.с. әйткән:

*«Башына берәр кайгы төшкән кеше: "Без үзебез дә, әһлебез дә, һәм барча малыбыз да – Аллаһы Тәгаләнекедер, һәм Аның хозурына кайтачакбыз. Ий, Аллаһ! Мин бу кайгым бәрабәренә булачак савапка өметләнәм, сабыр итүем бәрабәренә миңа савап бир, шушы кайгымны яхшылыкка әйләндер!"– дип әйтсен».*

## КАНӘГАТЬЛЕЛЕК

Чын мөселман тыйнак була. Ул булганы белән канәгать булырга, башкаларга үтенеч белән мөрәҗәгать итмәскә, авырлыклар белән очрашса, сабыр итәргә, бөтен барлыгы белән хәер сораучылар хәленә төшмәскә тырыша.

Мөхәммәд галәйһиссәләм әйткән:

*«Үз-үзен тыярга омтылучыны Аллаһ тотнаклы итәчәк; булганына риза булучыны башка кешеләргә үтенеч белән мөрәҗәгать итүдән коткарачак; сабыр итүчегә Аллаһ сабырлык бирәчәк. Беркемнең дә әле сабырлыктан яхшырак һәм юмартрак бүләк алганы булмады».*

Ислам югары кул түбән кулдан яхшырак дип белдерә. Ул шуның белән фәкыйрьләрнең сәдакадан башка да яшәүләренә ирешергә кызыктыра. Дөрестән дә, байлар мөлкәтенең бер өлеше хаклы рәвештә фәкыйрьләрнеке булса да, шул ук вакытта Ислам аларны төрле шелтә, үпкәләтү, кимсетүләрдән саклап калырга теләп, аларны хәергә, сәдакага гына карап калмаска өнди.

Мөхәммәд галәйһиссәләм әйткән:

*«Берегезнең бау алып, тауга барып утын җыюы, шуны китереп сатуы һәм шуннан сәдака бирүе – кешеләрдән сорап йөрүгә караганда хәерлерәктер».*

Рәсүлүллаһ бу хәдистә кул көче белән эшләп ашарга һәм бу юлдагы мәшәкатьләргә сабыр итәргә чакыра, чөнки кешеләрдән сорану – иң түбән бер эштер. Үз тырышлыгы белән көн күрү сәбәпле Адәм баласының кадере, хөрмәте арта.

## СӘЛАМЛӘШҮ

Сәлам – сәламәтлек, исәнлек яисә бер нәрсәнең яхшы һәм хәерле булуын теләү димәктер.

Мөселманнар бер-берләре белән очрашканда «Әссәләмү галәйкүм» дип сәламләшәләр. Сәламнән соң бер-берләренең кулларын кысалар, һәр икесе дә динебездә сөннәттер. Ләкин сәлам биргән кешегә «вә галәйкүмүссәләм» дип җавап кайтару фарыз кифаядер. Чөнки Аллаһы Тәгалә әйткән: *«Әгәр сезгә сәлам бирелсә, сез аннан да яхшырак рәвештә җавап кайтарыгыз, яисә аның биргән сәламе кебек җавап бирегез».* Коръән аяте: (Ниса - 86)

Сәламләшү – иң яхшы гадәтләребезнең берсе. Өйдә, урамда, эш урынында, кибеттә, юлда – кайда гына булмасын, бер мөселман икенче мөселман кардәше белән очрашканда аңарга сәлам бирү дини бер вазифадыр. Пәйгамбәребез әйткән: *«Арагызда өлфәт-мәхәббәт артуын теләсәгез, үзара сәлам таратыгыз».*

Әгәр бер кеше, җәмәгатькә сәлам биреп, җәмәгатьтән берсе аның сәламен алса, башкаларга җавап бирү кирәк түгел.

Ашаган вакытта өстәл тирәсендәгеләргә сәлам бирелмәс, аның урынына «Бәрәкәтле булсын» яисә «Ашыгыз тәмле булсын», дияргә кирәк.

Бер кеше аркылы җибәрелгән сәламгә дә «Вә галәйкүмүссәләм» дип җавап бирергә кирәк.

Кем дә булса берәр кешегә сәлам җибәрсә, ул сәламне иясенә тапшырырга кирәк, чөнки бу сәлам – бер әманәттер.

Ислам дине буенча, иелеп-бөгелеп сәлам бирү, яки сәлам алулар дөрес түгел. Без бары тик Аллаһы Тәгаләгә генә бөгелергә тиеш. Аллаһы Тәга-

лә кешенең кешегә бөгелүен теләми. Пәйгамбәребез дә: *«Бер-берегез белән сәламләшкәндә бөгелмәгез»,* – дигән.

Көндәлек тормышта сәлам урынына әйтелә торган сүзләр дә бар. Мәсәлән: исәнме, нихәл, хәерле иртә, хәерле кич, хәерле сәфәр, күрешкәнче, күрешкәнчегә кадәр һ.б. Боларны әйтүнең дә үзенә күрә савабы булса кирәк. Бу сүзләр дә халкыбызның матур, әдәпле сүзләре. Ләкин «Әссәләмү галәйкүм» дип сәламләшү бөтен мөселманнар өчен уртактыр. Шуның өчен иң элек шул рәвешчә сәлам бирелер, аннан соң гына исәнләшелер. Чөнки, сәлам барча сүзләрдән элек бирелә. Пәйгамбәребез бер хәдисендә болай дигән: *«Сүздән элек сәлам булсын».*

Аллаһ Илчесе әйткән:

*«Кече – олыны, атка атланган кеше – җәяүлене, баручы – утыручыны, аз санлы кешеләр төркеме – зуррагын сәламләргә тиеш».*

Сәламләү сүзләрен очрашканда да, аерылышканда да әйтергә кирәк.

Мөхәммәд галәйһиссәләм әйткән:

*«Сезнең берәрегез җыелышып торган кешеләргә кушылса, аларга сәлам бирсен, китәргә теләсә дә – сәламләсен, чөнки, икенчесе дә беренчесе кебек ук мөһимдер».*

## РӨХСӘТ СОРАУ

Үз диненең әхлак кануннарын яхшы үзләштергән мөселман рөхсәт сорамыйча, үз өеннән башка бер йортка да керми. Аллаһы Тәгалә әйткән:

*«Әй, мөэминнәр! Чит өйләргә рөхсәт сорамыйча һәм сәлам бирмичә кермәгез! Рөхсәт сора-*

*гыз һәм өйдә булган кешеләргә сәлам бирегез. Әгәр шулай эшләсәгез, ул сезнең өчен хәерле булыр, шаять, вәгазьләнерсез. Әгәр ул өйдә һичкем булмаса, яисә кеше була торып та, керергә рөхсәт бирелмәсә, ул өйгә кермәгез, әгәр сезгә «Китегез!» диелсә – китегез, чөнки сезнең кайтып китүегез сезнең өчен гөнаһлы булудан яхшырактыр. Аллаһы Тәгалә сезнең эшләрегезне белер, шуңа карата җәза бирер...»* Коръән аяте: (Нур - 27,28)

Пәйгамбәребез берәр кешенең өй ишекләре янына килгәндә, керергә рөхсәт сорарга теләп, нәкъ ишекләр каршында түгел, бәлки, ишекнең уң яки сул ягында басып тора торган була.

«Кем анда?» – дип соралганда, ишек артындагы кеше: «Мин», – яки шуңа охшаган җаваплар бирергә тиеш түгел, ә үзенең исемен әйтергә тиеш.

# أعوذ بالله من الشيطان الرجيم

***Әгуузү билләһи минәш-шәйтанир-раҗиим***

## НАЧАР ХӘЛЛӘР — ЯМАН ХОЛЫКЛАР

### ГӨНАҺ

Гөнаһ – дип кешенең ахирәттә газапка дучар булуына сәбәп булачак сүзләргә, эшләргә һәм хәрәкәтләргә әйтелә.

Гөнаһлар ике төрле була: зур һәм кечкенә гөнаһлар. Аллаһы Тәгалә әйткән:

*«Әгәр сез Аллаһ тарафыннан тыелган гөнаһларның зурларыннан саклансагыз, сездән кечкенә гөнаһларны да ерагайтырбыз һәм сезне шәрәфле бер урынга кертербез».* Коръән аяте: (Ниса - 31)

Аллаһы Тәгалә Үзенә тиң күрүдән (ширек) башка бөтен гөнаһларны гафу итә. Бу, әлбәттә, һичшиксез гафу ителер дигән сүз түгел. Аллаһы Тәгалә кешеләрнең гөнаһ эшләүләрен теләми. Әгәр, гөнаһ эшләгән булсалар, аларның тәүбә итүләрен көтә. Әгәр кеше Аллаһыга ялварып, гөнаһларына үкенеп, киләчәктә ул хатаны эшләмәскә Аллаһ каршында тәүбә итсә, иншә Аллаһ, Аллаһы Тәгалә аның гөнаһларын гафу итәр. Мөэмин-мөселман Аллаһының рәхмәтеннән һичкайчан өметен өзмәс. Аллаһы Тәгалә әйткән:

*«Аллаһының рәхмәтеннән өметегезне өзмәгез, Аллаһы Тәгалә бөтен гөнаһларны да кичерә бит»*

Коръән аяте: (Зөмәр - 53)

# ЯЛГАН ВӘ ХӘЙЛӘ

Башкаларны алдар өчен әйтелгән һәм дөрес булмаган сүзләргә ялган диелә. Динебездә хәрам кылынган зур гөнаһларның берсе – ялган сөйләү.

Аллаһы Тәгалә әйткән:

*«Ялган сүздән сакланыгыз».* Коръән аяте: (Хаж - 30)

*«Әй, мөэминнәр, Аллаһыдан куркыгыз! Сөйләгән вакытта чын дөресен сөйләгез».* (Әхзаб - 70)

Тормышыбыздагы бик күп күңелсез хәлләр ялган ярдәмендә килеп чыга. Хәйлә, алдау, золым, хаксызлык, гадәләтсезлек, ышанычсызлык, дошманлык, татусызлык, тынычсызлык кебек нәрсәләр барсы да ялган нәтиҗәсендә барлыкка килә.

Ялганчының үз-үзенә дә ышанычы юк, кешелеклелеге һәм иманы зәгыйфь. Пәйгамбәребез бер хәдисендә: *«Ялганнан сакланыгыз. Чөнки иман бер якта, ялган икенче яктадыр. Ялган белән иман икесе бергә бер үк кешедә булмас»,* – дигән.

Икенче бер хәдисендә әйткән: *«Тугрылыкны нык саклагыз, чөнки тугрылык кешене яхшылыкка, яхшылык җәннәткә илтә. Кеше һәрвакыт тугры сөйләсә, Аллаһ алдында бик тугры кеше дип язылыр. Ялганнан сакланыгыз, чөнки ялган кешене начарлыкка, начарлык җәһәннәмгә илтә. Бер кеше гел ялган сөйләсә, ул Аллаһ хозурында ялганчы дип язылыр».*

Ялганчы кеше, башкаларны алдаса да, Аллаһыны алдый алмас, чөнки Аллаһы Тәгалә кешеләр эшләгән һәрнәрсәне күрә, сөйләгән һәрбер сүзләрен ишетеп тора.

Ислам динендә кайбер хәлләрдә ялганларга рөхсәт ителә:

– бер-берсе белән арлары бозылган ир белән хатынны һәм ике мөселманны килештерер өчен;

– сугышта дошманны алдар өчен;

– кемнең булса да җанына, малына, диненә һәм намусына золым һәм хаксызлык белән зарар кылгәндә, аларны коткарыр өчен;

– хаста кешеләргә өмет һәм яшәү көче бирер өчен.

Пәйгамбәребез бер хәдисендә әйткән: *«Халыкның арасын төзәтер өчен изге максат белән сүз йөрткән яки изге ният белән ялган сөйләгән кеше ялганчы түгел».*

Хәйлә дә алдауның бер төре булып санала. Шуның өчен ялган кебек хәйлә дә хәрамдыр. Хәйләкәр кеше икейөзле була. Ул башкаларны алдар өчен үзен башкача күрсәтергә тырыша. Чын мөселман күренгәне кебек булыр, булганы кебек күренер, һәр көн башкача булып кылынмас. Ислам динендә кеше зур хөрмәткә лаеклы бер барлыктыр, әмма хәйләкәр кеше башкаларны хөрмәт итмәс. Үзеннән бүтәннәрне түбән күреп, үз файдасы турында гына кайгыртыр. Шуның өчен дә ялганчы белән хәйләкәрләрнең дуслары, иптәшләре, якыннары юк, чөнки аларга беркем дә ышанмый.

Пәйгамбәребез бер хәдисендә шулай дигән: *«Бер мөселманга зарар иткән һәм аны алдаган кеше бездән түгел».*

## ГАЙБӘТ СӨЙЛӘҮ

Динебез буенча, мөселманнар дуслык, тынычлык, үзара өлфәт һәм мәхәббәт эчендә яшәргә тиешләр. Кешеләр арасындагы дуслык, эчкерсезлек һәм кардәшлек хисләрен бетереп, капма-каршы

булган кенә һәм дошманлык китереп чыгара торган начар нәрсәләрнең берсе – гайбәттер.

Гайбәттән, сүз йөртүдән, кешеләрне рәнҗетә торган ямьсез һәм начар сүзләрдән тартынырга кирәк. Чөнки боларның барысы да тыелган, хәрам эшләрдәндер.

Беркөнне Пәйгамбәребез сәхабәләрдән сораган: *«Гайбәт нәрсә ул, беләсезме?»* Сәхабәләр: «Аллаһ һәм Аның Илчесе белер», – дигәннәр. Шунда Пәйгамбәребез г.с: *«Гайбәт дин кардәшеңнең гаебен аның артында сөйләүдер»,* – дигән. Сәхабәләр сораганнар: «Әгәр кардәшебезне яманлавыбыз дөрес булса, сөйләргә ярыймы?» Пәйгамбәребез әйткән: *«Әгәр сөйләгән сүзләрең дөрес булса, син гайбәт сөйләгән булырсың. Сөйләгән сүзләрең дөрес булмаса, яла яккан булырсың».*

Коръәндә Аллаһы Тәгалә гайбәт сөйләүне кеше ите ашауга тиңләгән һәм кешеләрне гайбәт сөйләүдән катгый рәвештә тыйган. Аллаһы Тәгалә әйткән: *«Әй мөэминнәр, занның күбесеннән сакланыгыз. Чөнки занның кайберләре гөнаһтыр. Башкаларның гаепләрен тикшермәгез. Бер-берегез турында гайбәт сөйләп йөрмәгез. Сезнең берәрегез вафат булган кардәшенең итен ашарга яратырмы? Җирәнәсез бит. Шулай булгач, Аллаһыдан куркыгыз».* (Хүҗүрат - 12)

Пәйгамбәребез гайбәт сөйләүчеләрне яратмаган. Әгәр бер кеше аның янында гайбәт сөйләргә тотынса, аңа гайбәтнең хәрам вә гөнаһ икәнен хәтеренә төшерә торган булган.

Пәйгамбәребез гайбәтне тыңларга да рөхсәт итмәгән. Бер хәдисендә ул болай дигән: *«Гайбәт сөйләүче белән гайбәт тыңлаучының гөнаһлары уртактыр».*

Гайбәт сөйләүчеләр куркыныч бер хасталыкка дучар булган кешеләрдер. Безнең яныбызда башкалар хакында гайбәт сөйләп торган кеше башкалар янында безнең хакта да ямьсез сүзләр сөйләргә һич тартынмас.

Мөселман кеше, башкаларның гаебен эзләп, ул турыда анда-монда сөйләп йөрмәс. Дөрес кеше мөселман кардәшенең хата һәм гаепләрен сер итеп сакларга тырышыр. Чөнки Пәйгамбәребез болай дигән: *«Кем дә кем бер мөселман кардәшенә ярдәм итсә, Аллаһ та ул кешегә ярдәм итәр. Кем дә кем бер мөселман кардәшенең кайгысын бетерсә, Аллаһ та Кыямәт көнендә аның кайгыларының берсен бетерер. Кем дә кем бер мөселман кардәшенең гаебен белдертмәсә, Аллаһ та ахирәттә аның гаебен белгертмәс».*

Һәркем башкаларның гаепләрен тикшергәнче, беренче чиратта үзендә булган кимчелекләрне бетерергә, үзен яхшы кеше итеп тәрбияләргә тырышсын. Пәйгамбәребез әйткәнчә: *«Яхшы мөселман, үзенең гаепләрен тикшергәнлектән, башкаларның гаепләрен тикшерергә вакыты калмас».*

Гайбәтнең дөнья тормышыбызда һәркем өчен зыяны күп булган кебек, ахирәт өчен дә зарары күптер. Гайбәт изгелекләр һәм гыйбадәтләрдән килгән савапларның югалуына сәбәп булыр.

Мөселман булган кеше бары тик гүзәл һәм файдалы сүзләр генә сөйләр. Пәйгамбәребез бу турыда болай дигән: *«Аллаһыга һәм ахирәт көненә ышанган кеше хәерле һәм файдалы сүзләр генә сөйләсен яисә авызын ачмасын».*

# УРЛАУ

Урлау – башкаларның малын яки акчасын рөхсәтсез һәм яшерен рәвештә алу, үзләштерүдер. Кешеләрнең малын урлаучыларга карак диләр. Караклар – бер эш эшләмичә, җиңел юллар белән көн күрергә тырышучы бәдбәхетләрдер.

Урлау ул кемнең дә булса акчасын яки малын хаксыз рәвештә үзләштерү генә түгел. Мәсәлән, ким үлчәү, ким сату, малның бәясен арттырып сатып, тиз вакытта күп акча эшләү, мылтык белән кешеләрдән, кибетләрдән, банклардан акчаны яисә малны көчләп, куркытып алу, безгә тапшырылган хөкүмәт яки кеше акчаларын үз эшләребездә куллану кебек нәрсәләр дә урлау дип санала. Әхлагы зәгыйфь булган кеше өчен иң мөһим нәрсә – акча һәм дөнья малыдыр. Шуның өчен ул урлауны үзенә хәрам эш дип санамый.

Урлау күп вакытта яшерен эшләнә. Һәр мәмләкәтнең кануннарында караклар өчен махсус җәзалар каралган. Каракны тотар өчен һәр өйгә, һәр кибеткә, һәр эш урынына сакчы куярга мөмкин түгел. Ләкин иманлы кешенең күз алдында һәрвакыт Аллаһы Тәгалә тора. Ул ниндидер сәбәпләр аркасында урларга мәҗбүр булса да, Аллаһыдан куркып, бу начар эштән ваз кичәр. Шуның өчен Пәйгамбәребез бер хәдисендә болай дигән: *«Аллаһыга ышанган кеше калебендә иманы булган хәлдә урламас».* Димәк, кешенең иманы һәм Аллаһыдан куркуы, аны бик күп начар эшләрдән тыеп кала.

## КЕШЕ ҮТЕРҮ

Кеше – Аллаһы Тәгалә яралткан иң өстен барлыктыр.

Кеше – Аллаһының иң зур иҗатларыннан берседер. Мөселман булсын, мөселман булмасын, Аллаһ яралткан һәр кешенең бу дөньяда яшәргә хакы бар. Адәм баласын бар итү дә, үтерү дә Аллаһ кулындадыр.

Кеше үтерү – гөнаһларның иң зурысыдыр. Хаксыз рәвештә кеше үтерергә ярамый, чөнки кеше үтерүчене Аллаһ гафу итми. Бу турыда Коръәндә Аллаһы Тәгалә әйткән: *«Кем дә кем һич сәбәпсез бер мөэминне үтерсә, ул үтерүченең җәзасы җәһәннәмдер. Ул җәһәннәмдә мәңге калыр. Үтерүчегә Аллаһ газап һәм ләгънәт кылыр. Ахирәттә ул кеше өчен бик каты газап булыр».*

(Ниса - 93)

Пәйгамбәребезнең хәдисләрендә тагын болай диелгән: *«Эшләнгән һәртөрле гөнаһларның гафу ителү мөмкинлеге бар. Ләкин кяфер булып үлгәннең һәм бер мөэминне үтерүченең гафу ителү ихтималы юктыр».*

*«Дөньяның җимерелүе бер мөселманның үтерелүеннән яхшырактыр».*

Кеше ничек туа? Нинди авырлыклар белән үсә? Ата-ана баласы өчен күпме борчу, мәшәкатьләр күрә? Дөньяда иң акрын үскән җанлы зат – адәм баласыдыр. Аны үстерер өчен ата-анадан чиксез фидакарьлек сорала. Димәк ки, бу кадәр авырлыклар белән үстерелгән кешене үтерергә, Аллаһы Тәгаләнең иң зур иҗатын юк итәргә беркемнең дә хакы юк.

Коръәндә Аллаһы Тәгалә бер генә кешене үтерүне дә бөтен кешелекне юк итүгә, бер генә кешене үлемнән коткаруны да бөтен кешелекне коткаруга охшаткан. (Мәидә - 32)

Динебездә катгый рәвештә тыелган нәрсәләрнең берсе – үз-үзеңә кул салу, үз-үзеңне үтерү. Югарыда әйтеп үткәнебезчә, җан кешегә Аллаһы Тәгалә тарафыннан әманәт итеп тапшырылган. Җанны бирүче дә, вакыты җиткәч кире алучы да Аллаһы Тәгалә Үзедер. Үз-үзен үтергән кеше Аллаһының әманәтенә хыянәт кылган өчен гөнаһлы була. Кеше нинди генә авыр хәлдә яшәсә дә, күпме кайгы, хәсрәт күрсә дә, сабыр итеп, үз җанын Аллаһ әманәте итеп сакларга, үз-үзенә һичкайчан кул салмаска тиеш.

Аллаһы Тәгалә әйткән:

*«Үзегезне үтермәгез, Аллаһ сезгә мәрхәмәт кылыр».* Коръән аяте: (Ниса - 29)

Ислам дине – шәфкать һәм мәрхәмәт динедер. Ул кешеләргә генә түгел, хайваннарга карата да шәфкатьле, мәрхәмәтле булырга, аларны үтермәскә куша.

## АРАКЫ ЭЧҮ

Ислам динендә хәрам кылынган һәм Аллаһы Тәгалә тарафыннан катгый рәвештә тыелган нәрсәләрнең берсе – исертә торган эчемлекләр эчү.

Халык арасында аракы дип аталып йөртелә торган мондый эчемлекләрнең төрле-төрле исемнәре булырга мөмкин. Исеменең нинди булуына карамастан, кешене исертә торган һәрнәрсә Ислам динендә хәрам кылынган. Чөнки Пәйгамбәребез

әйткән: *«Кешене исертә торган һәрнәрсә хәрамдыр».*

Моннан тыш Пәйгамбәребез бер хәдисендә болай дигән: *«Аракы – бөтен усаллыкларның анасыдыр».* Ягъни, Пәйгамбәребез әйткәнчә, һәртөрле усаллык һәм начарлык аракыдан туа. Чыннан да дөньяда эшләнгән бик күп явызлык һәм усаллыклар исерек кешеләр тарафыннан эшләнә. Юл казалары, янгыннар, кеше үтерүләр, һәртөрле ямьсез бәхәсләр, җәнҗаллар, орышлар һәм әхлаксызлыкларның күбесе исерек кешеләр тарафыннан эшләнә.

## ОТЫШ УЕННАРЫ УЙНАУ

Җиңел юл белән акча табу максатыннан отыш уеннарын уйнау Ислам динендә хәрам кылынган.

Отыш уеннары кешеләрне ялкаулыкка өйрәтә. Адәм баласы җиңел юл белән акча эшләп, тиз генә баерга омтыла. Белгәнебезчә, Ислам дине – намуслы хезмәт һәм тырышлык динедер. Тырышлык куймый табылган акчаны динебез дөрес дип санамый. Аллаһы Тәгалә Коръәндә: *«Кеше бары тик үзе эшләгәннән генә өлешләнер», – дигән.* (Нәҗем-39)

Димәк, мал һәм акчаны бары тик, тырышлык куеп кына табарга кирәк.

Кешелек тәҗрибәсе күрсәткәнчә, иң рәхәт, иң бәрәкәтле акча кешенең үзе эшләп тапкан акчасыдыр. Җиңел килгән акча, җиңел китәр, ди халык. Хәрам яисә шөбһәле акча кешене бәхетле итми. Хәрам акча кешенең тынычлыгын ала, тормышының тәмен боза. Тырышлык белән табылган хәләл акча кешене ике җиһанда да бәхетле итә һәм татулыкта яшәүгә нигез була.

Ислам динендә кешеләрнең җаннары һәм маллары кагылгысыз дип санала. Беркемнең дә икенче кешенең малына һәм җанына зарар китерергә хакы юк. Отыш уеннары уйнаучылар, бер-берләренең малларына һәм акчаларына зарар итеп, хәрам һәм гөнаһлы эшләр эшләүчеләр булып саналалар. Отыш уеннары кешеләр арасына кенә һәм дошманлык сала, җәмәгать арасындагы татулыкны боза. Коръәндә Аллаһы Тәгалә болай дигән: *«Әй, мөэминнәр, аракы эчү, отыш уены, потлар һәм отыш уены өчен ясалган уклар – шайтанның гамәлләреннән булган пычрак гамәлләрдер. Ул эшләрдән саклансагыз, дөнья һәм ахирәт бәхетенә ирешерсез. Шайтан аракы һәм отыш уеннары белән арагызга дошманлык салып, сезне гыйбадәттән, Аллаһы Тәгаләне зикер итүдән һәм намаздан тыярга тырыша. Шулай булгач, бу эшләрдән тыелырсызмы?»* (Мәидә - 90, 91)

Отышлы уеннар кешенең вакытын һәм көчен ала, сәламәтлеген боза, гаиләдәге тынычлык бозылуларга сәбәп була. Күп кешеләр отышлы уеннар уйнап барлык малларын югалталар, үзләрен, гаиләләрен, балаларын авыр хәлдә калдыралар. Отыш уеннары уйнау Аллаһ алдында да, халык арасында да кешенең дәрәҗәсен төшерә. Халык отыш уеннары уйнаучыга бервакытта да яхшы күз белән карамаган һәм хәзер дә карамый.

Уенда җиңелгән кеше, акчасын кире алыр өчен, җиңгән кеше тагын да күбрәк отар өчен, яңадан уйнарга тотыналар. Нәтиҗәдә икесе дә бу уенның тоткынына әвереләләр. Отыш уеннары уйнарга күнеккән кешегә мондый уеннарны ташлау бик авыр. Шуңа күрә иң яхшысы – бу уеннардан ерак тору.

Әлбәттә, отыш уеннары уен карталары белән генә уйналмый. Аңа хиресләнгән кеше аның төрле юлларын табарга тырыша. Бүгенге көндә кешеләрне отышка кызыксындырыр өчен аның нинди генә төрләре уйлап табылмый. Аларның нинди генә исемнәре юк. Ләкин нинди генә исем белән аталса да отыш уеннары Ислам динендә хәрам санала.

## ЗИНА КЫЛУ

Ислам дине гаилә тормышына зур әһәмият биргән. Гаилә тормышы никах белән башлана. Өйләнмичә, никахсыз тору динебездә хәрам санала. Бер ят ир кеше белән ят хатынның никахсыз якынлык кылулары – зина кылу дип атала.

Коръәндә Аллаһы Тәгалә болай дигән: *«Зина кылмагыз. Шик тә юк, ул бер әдәпсезлектер һәм начар бер юлдыр».* (Исра - 32)

Гаиләсез бер милләт тә үзенең үсешен дәвам итә алмый. Шуның өчен динебез зинаны зур гөнаһ итеп саный. Зина гаиләгә һәм җәмгыятькә бик күп зарар китерә.

Зина кешеләрнең һәм гаиләләрнең исемен һәм хөрмәтен пычрата, түбән төшерә, гаилә тормышын боза. Туачак баланың нәселе билгесез була, бала никахсыз ата-анадан туа. Ислам галимнәре никахсыз ата-анадан туган баланың шәфкатьсез, мәрхәмәтсез һәм каты күңелле булуы турында кисәтәләр.

Зина аркасында бик күп йогышлы авырулар тарала, кешеләрнең сәламәтлегенә зур зыян килә. Хәзерге көндә зина кылу нәтиҗәсендә дәвалап булмый торган авырулар барлыкка килде. Шуның нәтиҗәсендә җир йөзендә меңнәрчә кешеләр үлә.

Зина кешеләр арасында орышларга, җәнҗалларга, хәтта үтерешләргә сәбәп була.

Зина калебнең каралуына, иманның зәгыйфьләнүенә сәбәп була. Зина кылучы, үзе дә сизмәстән, мәгънәви яктан бик күп нәрсәләрне югалта. Иманы зәгыйфьләнгән кешенең гыйбадәтләре дә камил булмый, әхлагы да бозыла.

Ислам дине зинага илтә торган бөтен юлларга киртә куя. Ирләр һәм хатыннар арасындагы мөнәсәбәтләр, таныш, кардәш, якыннар һәм ят кешеләр белән мөнәсәбәтләр ничек булырга тиешлеген аңлатып бирә.

Ислам динендә зина кылган кеше өчен авыр җәзалар билгеләнгән, әмма зинаның ахирәттәге җәзасы дөньядагыдан күпкә катырактыр. Аллаһы Тәгалә бу җәһәттән әйткән: *«Аллаһының коллары Аллаһыдан башка тәңрегә ялвармаслар, Аллаһ хәрам кылган нәрсәләрне эшләмәсләр, кеше үтермәсләр. Үтерсәләр дә, хаклык белән үтерерләр, зина кылмаслар. Боларны эшләгән кеше өчен кыямәт көнендә кат-кат газап бардыр һәм ул кеше хур булган хәлдә мәңге газапта калыр».* (Фуркан – 68, 69)

Кешенең иң күп гөнаһларына сәбәп булган һәм аны җәһәннәмгә илтә торган ике әгъзасы бар. Болар теле белән җенси әгъзаларыдыр. Бу әгъзаларына хуҗа була алган кеше бөек дәрәҗәләргә ирешер. Аларга хуҗа була алмаган кешеләр дөньяда түбәнлекләргә, ахирәттә зур газапларга дучар булырлар. Пәйгамбәребез бер хәдисендә әйткән: *«Кем дә кем миңа ике ирене һәм ике аягы арасындагы әгъзасын хәрамнан тыярга вәгъдә бирсә, мин дә ул кешегә җәннәтне вәгъдә итәрмен».*

Ир белән хатын үзара фәкать никах аркылы гына кавышырга тиешләр.

Никах кешегә гөнаһсыз тормыш алып барырга мөмкинлек бирә.

Никах – кешенең хис-тойгыларын канәгатьләндереп тынычлыкка ирешүнең иң яхшы һәм иң табигый чарасы.

Әгәр кемдер никахланырга тели, ләкин җитәрлек мөмкинлеге юк икән, ул Аллаһының сүзләренә колак салсын:

*«Никахлану өчен мал таба алмаган ярлы кешеләр Аллаһ аларга биргәнгә чаклы сабыр итсеннәр, һәм зинадан саклансыннар».* Коръән аяте: (Нур – 33)

Мөхәммәд галәйһиссәләм әйткән: *«Әй, яшьләр, әгәр сез никахланырлык хәлдә икәнсез, никахланыгыз, чөнки ул сезгә тынычлык китерер. Кем никахка керерлек хәлдә түгел икән, ул кеше ураза тотсын һәм зинадан тыелсын».*

Ата кеше үзенең кызына тугрылыклы һәм дини ир табарга тиеш. Әгәр чыннан да шундый кияү табылса, ул аны кире борып җибәрергә тиеш түгел. Чөнки Мөхәммәд галәйһиссәләм әйткән: *«Әгәр сезгә сезнең өчен әхлагы һәм дине ягыннан яраклы кеше килгән икән, аны өйләндерегез. Әгәр сез моны эшләмәсәгез, җирдә бөек фетнә һәм бозыклык таралачак».*

Күп кешеләр бу мәсьәләдә төрле кыенлыклар, авырлыклар тудыралар. Шуңа күрә күп егетләр, кызлар үзара очраклы бәйләнешкә керә, моның өчен җаваплылык ата-аналары өстенә төшә.

# ЯЛА ЯГУ

Яла ягу – кешене урынсызга гаепләү, ялган сүзләр белән кешенең дәрәҗәсен төшерү, һич булмаган хәлләр сөйләп, халык алдында кешенең исемен пычратудыр.

Яла ягу Ислам динендә хәрам эшләрдән санала, чөнки яла ягу гөнаһсыз кешеләрне авыр хәлдә калдыра.

Кем турында булса да сөйләгәндә ул сүзләрнең иясенә барып ирешүе турында да уйларга кирәк. Белгәнебезчә, тел пычактан да үткен. Тикмәгә генә, пычак ярасы төзәлер, тел ярасы төзәлмәс, димиләр. Тел белән эшләнгән зур гөнаһлардан берсе – яла ягу. Әгәр телеңә хуҗа була белмәсәң, иң күп бәла һәм гөнаһларга сәбәп булырга мөмкин. Бик күп бәлаләр һәм һәлакәтләр кешегә теле аркылы килә. Шуның өчен бабаларыбыз, телчән теленнән табар, дигәннәр дә инде.

Пәйгамбәребез Мөхәммәт галәйһәссәләм бер хәдисендә болай дигән: *«Шик тә юк, адәм баласының хата һәм гаепләренең күбесе теленнәндер».*

Бу мәсьәләдә Исламның түбәндәге кисәтүләрен искә төшереп үтәргә кирәк.

Аллаһы Тәгалә әйткән:

*«Әй мөэминнәр, әгәр сезгә явыз бер кеше бер хәбәр китерсә, ул әшәке, ара бозучы кешенең хәбәрен тикшермичә, аңа ышанмагыз. Әгәр бу кешегә ышансагыз, үзегез дә белмичә бер кавемгә, бер җәмәгатькә усаллык кылган булырсыз. Аннан соң, дөреслекне аңлагач, бик нык үкенерсез».* (Хуҗурат - 6)

Бу аятьтән аңлашылганча, һәр ишеткән сүзгә ышанырга ярамый. Мондый очракларда булганнан

бигрәк булмаганны арттырып сөйләргә яраталар. Мондый сүзләрнең азагын табу кыен була.

Яла ягу һәрвакыт булган. Пәйгамбәребез исән вакытында булган бер вакыйганы китереп үтик. Әгәр Аллаһы Тәгаләнең аятьләре Гайшә анабызның гөнаһсыз булганын белгертмәсә, аларның тормышы ничек булыр иде икән? Әлбәттә, алар гомер буе кайгы-газапта яшәрләр иде. Ләкин Аллаһы Тәгалә, Пәйгамбәребезгә аятьләр җибәреп, бу хатаны үз вакытында төзәтергә мөмкинлек биргән.

Эшләнгән явызлык-усаллыклар беркемгә дә табыш булып кайтмый. Башкаларга зарар иткән кеше, бу җирнең өсте булганы кебек, асты да бар икәнен онытмасын иде. Башкаларга явызлык ясаганнарга бу дөньяда качып калыр өчен урын табылса да, ләкин ахирәт тормышында андыйлар беркая да качып котыла алмаслар. Ул көндә алар, «Кыямәт» сүрәсендәге аятьтә әйтелгәнчә, *«Кая качып котылырга?»* диячәкләр. Коръән аяте. (Кыямәт - 10)

## ТӘКӘББЕРЛЕК

Тәкәбберлек – үзен башкалардан өстен күрү, үзен олылап, башкаларны түбән күрү димәктер.

Исламиятнең иң зур максатларыннан берсе – кешеләрне бер-беренә якынайтып, татулыкта яшәтү, дөньяда һәм ахирәттә бәхетле итү. Ләкин Аллаһы Тәгалә үзенең колларын холык һәм табигать ягыннан төрле итеп яралткан. Кайбер кешеләр ихлас күңелле һәм түбәнчелекле, кайберләре исә каты күңелле һәм тәкәббер булалар.

Шайтан үзенең тәкәбберлеге һәм үзен һәркемнән өстен күргәне өчен Аллаһының рәхмәтеннән

мәңгегә сөрелде. Тәкәбберлек Ислам динендә хәрамдыр.

Аллаһы Тәгалә әйткән:

*«Аллаһы Тәгалә мактана торган тәкәббер кешеләрне яратмый».* Коръән аяте: (Ниса - 36)

*«Җир йөзендә тәкәбберләнеп йөрмә. Чөнки син җирне дә тишә алмассың, буең да тауларга җитмәс».* Коръән аяте: (Исра -37)

Мөхәммәт галәйһәссәләм әйткән: *«Тәкәбберләнгән кешене Аллаһ түбән төшерер, ихлас күңелле кешенең исә дәрәҗәсен күтәрер».*

Пәйгамбәребез һәрвакыт ихлас күңелле булган һәм безгә дә шундый булырга дип әйтеп калдырган. Пәйгамбәребезне беренче мәртәбә күргән бер гарәп, аннан куркып, калтырый башлаган. Шулвакыт Пәйгамбәребез: *«Әй иптәш, курыкма! Мин дә Корәеш тармагыннан арпа икмәге ашаган бер хатынның баласымын»,* – дип эчкерсезлеген күрсәтеп, ул кешене юаткан. Ул үзенең пәйгамбәрлеге белән бер вакытта да мактанмаган.

Миңа тәкәббер кеше димәсеннәр, мине ихлас күңелле кеше дисеннәр, дип, һәрнәрсәгә риза булу да дөрес түгел. Мөселман вәкарь иясedeр. Вәкарь тәкәбберлек тә түгел, аның киресе дә түгел, ә бәлки төгәл урта бер юлдыр.

## КӨНЧЕЛЕК

Көнчелек – кемнең дә булса байлыгыннан, эшләреннән сәбәпсез көнләү, аның юкка чыгуын, югалуын теләүдер.

Көнчелек – Ислам динендә гаеп күрелгән һәм хәрам кылынган эшләрдән санала.

Мөхәммәт галәйһиссәләм әйткән: *«Бөтен кешеләрдә көнчелек бар. Ләкин, кулы һәм теле белән көнләүне күрсәтмәсә, ягъни тышка чыгармаса, бу көнчелек кешегә зарар итмәс».*

Димәк, кешенең табигатендә көнчелек булса да, әгәр ул аны эчендә саклап тотса, башкаларга аның зарары тимәс.

Көнчелек җәмгыятьтә һәрвакыт кенә һәм дошманлык китереп чыгара, кешеләр арасында хөрмәт, сөю һәм мәхәббәтне бетерә. Шуның өчен Пәйгамбәребез әйткән: *«Әгәр кешеләр көнләшмәсәләр, тынычлык һәм яхшылык эчендә яшәрләр иде».* Шуңа күрә мөмкин кадәр көнчелектән ерак торырга, мондый зарарлы еланның койрыгына басмаска кирәк. Чөнки аның көнченең үзенә дә, башкаларга да зарары тия.

Көнче кеше күңелендәге начар уйлары аркасында һәрвакыт тынычсыз була. Көнчелек хасталыгы көнченең үзен ашап бетерә. Ләкин көнче моны үзе сизмәс. Шуның өчен дә бер хәдистә: *«Хөсет шул кадәр гадәләтледер ки, беренче итеп көнченең үзен яндырыр»,* – диелгән.

Пәйгамбәребез бер хәдисендә бу турыда түбәндәгечә әйткән: *«Ут ничек утыннарны ашап бетергәне кебек, көнчелек тә эшләнгән изгелекләрне, савапларны ашап бетерер».*

Пәйгамбәребез көнчелекне ике нәрсәдә – белемдә һәм байлык теләүдә дөрес дигән. Болар асылда хөсет, көнчелек түгел, кызыгудыр. Бу турыда Пәйгамбәребез түбәндәгечә аңлаткан: *«Көнчелек ике нәрсәдә булыр. Аллаһы Тәгалә бер кешегә белем бирер, ул кеше бу белеме белән хәләлне, хәрамны белеп, Аллаһ кушканча яшәр. Аллаһ бер кешегә мал, байлык бирер, ул кеше малы һәм бай-*

*лыгы белән изгелекләр эшләр, сәдакаларын, зәкятләрен бирер. Менә бу кешеләргә кызыгып, алар шикелле булырга теләү көнчелектән саналмас».*

Бу хәдистән аңлашылганча, башкаларның белеме һәм байлыгына кызыгу көнләшү түгел, ә бары тик шул нигъмәтләрнең үзебездә дә булуын теләүдер. Бу уй кешеләрне тырышлыкка өндәгәне өчен мөбахтыр, гөнаһ түгелдер. Икенче яктан, хөсетлек Аллаһының язмышына риза булмаудыр. Чөнки һәр нәрсә Аллаһының теләге, Аллаһының язмышы белән була. Кешеләргә мал-мөлкәтне, байлыкны, саулыкны, нигъмәтне һәм шуларга охшаган барча нәрсәләрне бирүче – Аллаһы Тәгаләдер. Дөньядагы барлыкларның һәммәсен Аллаһы Тәгалә туендыра, Аллаһының биргән ризыклары, нигъмәтләре өчен көнләшү дөрес түгел.

Хөсетнең көнчеләргә дә зарары зур. Шайтан үзенең тәкәбберлеге, хөсетлеге һәм сәҗдә кылмаганы өчен мәңгегә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтеннән куылды. Дөньяда иң беренче эшләнгән зур гөнаһ хөсет аркасында булды. Адәмнең улы Кабил туганы Хабилне көнләшү аркасында үтерде. Шулай итеп, кешелек тарихында иң зур гөнаһларның берсе эшләнде.

Туганнары, Йосыф пәйгамбәрдән көнләп, аны коега салдылар. Ләкин Аллаһы Тәгалә Йосыф пәйгамбәрне бу бәладән коткарды, аның дәрәҗәсен үстереп, үзен патша кылды.

Кайбер Ислам галимнәре көнчелек турында болай дигәннәр: «Көнчелек – шифасы табылмаган бер хасталыктыр».

Бу хасталыктан котылыр өчен, Аллаһының язмышына риза булып, бер-береңнән көнләшмәскә генә кирәк.

Пәйгамбәребез көнчелек турында түбәндәгеләрне әйткән: *«Бер-берегездән көнләшмәгез, бер-берегездән бизмәгез, арагызга суыклык кертмәгез, бер-берегездән аерылмагыз, сезне бер-берегезгә бәйләгән сөю бауларын өзмәгез. Әй, Аллаһының коллары, кардәш булыгыз».*

Мөхәммәд галәйһиссәләм әйткән:

*«Кешенең күңелендә дин белән көнчелек бергә була алмый».*

Ялганнан, хыянәттән, көнчелектән һәм явызлыктан азат, эчкерсез һәм саф күңелле булу – чын мөселман булуның билгеләре менә шулар. Нәкъ менә шундый кешеләр генә Ислам җәмгыятен төзи ала. Ә инде кешеләргә карата нәфрәтле, алардан көнләшеп һәм аларны алдап йөрүчеләрнең Исламдагы бәяләре – күп вакытларын гыйбадәттә уздыруларына карамастан – бер тиен.

## ИКЕЙӨЗЛЕЛЕК

Ислам җәмгыятендә һәрвакыт үзара мәхәббәт һәм эчкерсезлек хөкем сөрә, ә аның әгъзалары үзләренең тәкъвалыклары һәм тугрылыклары белән аерылып торалар. Шуңа күрә хәрәмләшүчеләргә, алдакчыларга, хәйләкәрләргә, яхшылыкның кадерен белмәүчеләргә һәм хыянәт итүчеләргә анда урын юк. Мондый сыйфатлар икейөзле кешеләргә генә хас. Мөхәммәд галәйһиссәләм әйткән:

*«Дүрт төрле сыйфат кемдә булса, шул кеше чын мәгънәсендә икейөзле була: әманәткә хыянәт итсә, сөйләгәндә алдашса, сүзендә тормаса һәм бозык сүзләр әйтеп тарткалашса».*

Икейөзле кешеләрнең чын йөзләрен Мөхәммәд галәйһиссәләм үзенең бер хәдис-шәрифендә фаш

иткән: *«Иң явыз адәм – икейөзле кешедер. Ул, бирәүләр янына барса, бертөрле, икенчеләр янына барса, икенче төрле күренеп йөрүче кешедер».*

Чын мөселман икейөзлелектән һәм ялагайлыктан ерак тора, чөнки аның иманы бу куркыныч упкынга төшүдән аны һәрвакыт саклап йөри.

## ИСРАФ

Исраф – акча, мал һәм Аллаһ тарафыннан безгә бирелгән нигъмәтләрне сәбәпсез туздыру яки әрәм итүдер.

Икътисад – дип ризык һәм малны дөрес һәм сакчыл куллануга әйтелә.

Аллаһы Тәгалә исраф кылучыларны сөйми.

Исрафның киресе саранлыктыр. Исраф та, саранлык та Ислам динендә хәрамдыр. Чөнки боларның беренчесе ризыкны, акчаны һәм малны әрәм-шәрәм итү булса, икенчесе, киресенчә, бу нигъмәтләрне, акчаны, малны үзеннән һәм башкалардан кызганып, кирәгенчә файдаланмау. Бу ике якның уртасы икътисадтыр.

Ислам дине бөтен эшләрдә урта юлны тотарга киңәш итә. Пәйгамбәребез дә: *«Эшләрнең хәерлесе – урта юлдыр»*, – дигән.

Коръәндә Аллаһы Тәгалә юмарт кешеләрне мактап сөйләгән вакытта шулай әйткән: *«Аллаһының коллары арасында шундыйлары бар, алар малларын сарыф иткән вакытта исраф кылучылар белән сараннар арасында урта бер юлны эзләрләр».* (Фуркан - 67)

Димәк, алар малларын исраф кылмаслар, саран да булмаслар.

Исрафчылык һәрбер эштә хәрам. Мәсәлән, бер шәкерт, үзенә кирәкле мәктәп әйберләрен: каләм, бетергеч кебек нәрсәләрне артыгы белән алып, кайберләрен кулланмыйча яисә бераз кулланып ташласа – бу исрафчылыктыр. Бер кешегә берничә костюм яки аяк киеме җитеп тә, ул бик күп яңа киемнәр алып, аларны һич кулланмаса, бу да исрафчылыктыр. Ашханә яки рестораннарда ике савыт аш белән туклanырга мөмкинлек булган хәлдә дә, биш-алты төрле аш китерергә кушып, аларның бер өлешен ашамыйча калдыру да исрафчылыктыр. Намаз һәм госел тәһарәтен алганда суны артык куллану, кирәкмәгән хәлдә өйдә, кибеттә, эш урынында утларны яндыру, ашларны, җимешләрне артыгы белән алып, ашамыйча калдыру һәм чүпкә түгү дә исрафчылыктыр. Менә шундый кешеләр хакында Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дигән: *«Хакыйкатьтә, артыгы белән туздыручылар – шайтан кардәшләредер...»* ( Исра - 27)

Һәрнәрсәдә исрафтан тартынырга кирәк. Хәтта гыйбадәт кылганда да безгә урта юлны тотарга кушылган. Бер сәхабә көне-төне намаз һәм Коръән укыган, көндезләрен дәвамлы ураза тоткан. Беркөнне бу кешенең хатыны, Пәйгамбәребезгә килеп: «Әй, Аллаһының илчесе, минем ирем дәвамлы гыйбадәт кыла. Мине һәм балаларны карарга вакыты юк, безне авыр хәлдә калдырды», – дигәч, Пәйгамбәребез, әлеге сәхабәне чакыртып, гыйбадәтләрен һәм уразасын бераз азайтырга һәм гаилә, балалары өчен вакыт табарга кушкан.

Кайбер кешеләр акча һәм малларыннан тыш вакытларын да исраф итәләр. Вакыт та Аллаһы Тәгаләнең нигъмәтләрдәндер. Аны яхшы һәм файдалы эшләр өчен генә кулланырга кирәк. Мөхәммәд

галәйһиссәләм көнне өч өлешкә бүлә торган булган. Бер өлешен гыйбадәт белән, икенче өлешен гаилә, өченче өлешен халык эшләре белән үткәргән. Халык эшләре өчен бүленгән вакыты җитмәсә, гаиләсе өчен бирелгән вакытны кулланган. Гыйбадәт өчен бүленгән вакытын киметми торган булган.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә: *«Заман белән ант итәм»,* – дип, вакытның кешеләр өчен никадәр әһәмиятле икәнен аңлаткан. Пәйгамбәребез дә бер хәдисендә түбәдәгеләрне әйткән: *«Ике нигъмәт бар, кешеләрнең күбесе аларның кыйммәтен аңламыйлар. Беренчесе – саулык, икенчесе – вакыт нигъмәте».*

Димәк вакытларын юкка уздырган кешеләр дә, вакытны исраф кылып, гөнаһ эш эшләгән булып саналалар. Кыямәт көнендә кешегә гомерен ничек һәм нинди эшләр белән уздырганы турында да сорарлар. Ашау-эчүдә, киемдә, өй кирәк-яраклары алганда да исрафчылыктан тартынырга кирәк. Кирәгенчә генә алып, артыгын әрәм-шәрәм итмәскә кирәк.

Коръәндә Аллаһы Тәгалә болай дигән: *«Әй адәм балалары, мәчеткә барган вакытта яхшы киемнәр киеп барыгыз. Ашагыз, эчегез, ләкин исраф итмәгез, чөнки Аллаһ исраф кылучыларны сөймәс».* (Әгъраф - 31)

Димәк, ару-пакь киенергә, хәләл нәрсәләрдән теләгән кадәр ашарга, эчәргә ярый, ләкин беркайчан да исраф кылырга ярамый.

## ҮЗЕҢ ЯХШЫЛЫК КЫЛГАН КЕШЕНЕ БИТӘРЛӘҮ

Аллаһы Тәгаләдән куркучы хак мөселман үзе яхшылык кылган кешене битәрләми, чөнки ул битәрләүнең һәм кылган игелегемне онытасың дип үпкәләүнең игелекле гамәлләрне файдасыз итүен һәм сәдаканың савабын юкка чыгаруын яхшы белә.

Аллаһы Тәгалә әйткән:

*«Әй мөэминнәр! Биргән сәдакаларыгызның әҗерен, шуны алган кешенең гел исенә төшереп тору һәм битәрләү белән юкка чыгармагыз!»* Коръән аяте: (Бәкара-264)

Мохтаҗлык аркасында башкалардан нәрсә дә булса алырга мәҗбүр булган кешегә әйтелгән шелтә сүзләре аның кешелек дәрәҗәсен кимсетә, намусына тия һәм аны түбәнсетү булып торалар. Боларның барысы да шәригать тарафыннан тыелган. Кешеләр арасындагы бердәнбер аерма фәкать диндарлык дәрәҗәсе белән була. Шуңа күрә ул үзенең дин кардәшен шелтәләмәскә, рәнҗетмәскә һәм дәрәҗәсен төшермәскә тиеш.

## ТӘҮБӘ

Тәүбә – хатадан, гөнаһтан кайту, эшләгән гөнаһлар өчен Аллаһыдан гафу сорау димәктер.

Иманлы бәндә дә кайвакыт үзенең битарафлыгы аркасында бер гөнаһ эш эшләп ташлый, яки тиешле гамәлләрен үтәмичә калдыра. Ләкин ул тиз арада үзенең ялгышларын танып, үзен гафу итүен сорап, Аллаһыга ялвара.

Аллаһы Тәгаләне чын күңелдән яраткан кешенең йөрәген битарафлык биләп ала алмый. Алла-

һының әмерләреннән һәм җитәкчелегеннән баш тарткан кешеләрнең генә йөрәге тулаем гафиллектә. Хак мөселманның йөрәге һәрвакыт Аллаһы Тәгаләнең мәгъфирәтенә, ярлыкавына омтыла, Аннан үзен туры юл белән алып баруын, изгелеккә ирештерүен ялвара.

Тәүбәнең кабул булуы өчен түбәндәге шартларның үтәлүе кирәк:

– тәүбә иткән кеше эшләгән гөнаһлары өчен үкенергә тиеш;

– тәүбә иткән гөнаһларын яңадан кабатламаска тиеш;

– гөнаһлы эшләрен Аллаһыдан куркып ташларга тиеш. Аллаһ өчен гөнаһтан ваз кичмәсә, тәүбә кабул булмый. Мәсәлән, дәвамлы аракы эчкән кеше бу эшне сәламәтлеген саклау максатында гына ташласа, бу тәүбә кабул булмас, чөнки ул моны Аллаһыдан куркып түгел, бәлки сәламәтлеген саклау өчен генә эшли.

Тәүбә итү өчен билгеле бер вакыт билгеләнмәгән. Һәркем теләгән вакытта тәүбә итә ала. Тәүбәне тәүбә догалары белән итү дә шарт түгел. Кеше кайчан теләсә, шул вакытта гөнаһлары өчен Аллаһыга ярлыкау сорап ялварыр. Иң мөһиме – тәүбә иткәннән соң ул гөнаһны яңадан эшләмәү.

Түбәндә язылган вакытларда тәүбә кылу яхшырак дип санала:

Җомга көнне догалар кабул булу сәгатендә. Бу сәгатьнең нинди сәгать икәне билгеле түгел.

Пәйгамбәребез әйткән: *«Җомга көнне бер вакыт бар, ул вакытта мөселманның кылган догасы кабул булыр».*

Сәхәр вакытында. Иртәнге намаздан әүвәл уянып, кешеләр йоклаган вакытта хата вә гөнаһлы эшләр өчен Аллаһыдан гафу итүен сорар.

Бәйрәм көннәрендә һәм кичәләрендә. Мәсәлән, Кадер кичендә, җомга һәм гает көннәрендә.

Тәүбәне соңга калдыру дөрес түгел, чөнки әҗәлнең кешегә кайчан киләчәген беркем дә алдан белә алмый. Ул яшькә, картка карамый, вакыты җиткәч һәркем бу дөньядан китеп бара. Әле мин яшь, картайгач тәүбә итәрмен, Аллаһының гафу итүен сорармын, хәзер тәүбә кылсам, шул ук гөнаһны тагын эшләргә туры килер, дип үзеңне алдарга ярамый. Чөнки Пәйгамбәребез әйткән: *«Әҗәл җиткәнче тәүбә итәргә ашыгыгыз»*. Икенче бер хәдисендә болай дигән: *«Җәһәннәмдәге кешеләрнең күбесенең газабы тәүбәне кичектерүдәндер»*.

Тәүбәне сәламәт вакытта кылырга кирәк. Үләчәген белгәннән соң гына кылынган тәүбә кабул ителмәс.

Мөхәммәд галәйһиссәләм әйткән:

*«Гөнаһ кылудан тәүбә иткән кеше, бернинди гөнаһысы юк кеше кебектер».*

*«Әгәр бәндәчелек белән берәр гөнаһлы эш эшләсәң, аның артыннан ук берәр яхшы эш эшлә, шул яхшы эш әүвәлге эшеңнең гөнаһысын юкка чыгарыр».*

*«Үзенең гаебен күреп, шуны төзәтү белән мәшгуль булганлыктан башкаларның гаепләрен күрергә вакыты булмаган, малының хаҗәтеннән артканын тиешле урыннарга биргән, сүзенең артканын үзендә калдырган, шәригатькә муафикь рәвештә гамәл кылган, аннан үтеп, бидәгать эшләр кылмаган кешегә сөенеч булсын!»*

بِسْمِ اللّٰهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

***Бисмилләһи-р-рахмәни-р-рахим***

# КҮРКӘМ ҮРНӘКЛӘР

Ислам динен һәм аның рухын яхшы итеп аңлау һәм чын мөселманның нинди булырга тиешлеген белү өчен Мөхәммәд галәйһиссәләм һәм аның сәхабәләренең тормыш юлларын да белергә кирәк. Бер кеше, мөселман булып та, әгәр Мөхәммәд пәйгамбәрнең һәм аның сахәбәләренең тормыш хәлләрен, дин һәм дөнья эшләрен яхшы белмәсә, ул кешенең динне аңлавы һәм гамәл кылуы кимчелекле булыр. Бөек затларның, бигрәк тә, хөрмәтле сәхабәләрнең тормыш юлларын өйрәнү – әхлак һәм тәрбия ягыннан иң файдалы гыйлемнәрдәндер.

## МӨХӘММӘД ГАЛӘЙҺИССӘЛӘМ

Мөхәммәд галәйһиссәләмнең әхлак чыганагы – Коръән булган. Шуңа күрә, Рәсүлебезнең холкы нинди иде соң? – дигән сорауга Гайшә анабыз: «Аның холкы – Коръән иде», – дип җавап биргән.

Аллаһ Раббыбыз Коръән Кәримендә Мөхәммәд галәйһиссәләмне мактап: *«Хакыйкатьтә, син – югары әхлак иясе»,* – дигән.

Мөхәммәд галәйһиссәләм үзе дә: *«Мин күркәм әхлакны камилләштерү өчен җибәрелдем»,* – дип, пәйгамбәрлегенең максатын бәян иткән.

Мөхәммәд галәйһиссәләм югары дәрәҗәдә намуслы һәм ышанычлы кеше булган; шулай ук, ул үзенең мөнәсәбәтендә йомшак һәм дустанә булган.

Ул гүзәл әхлаклы һәм фикер йөртергә яратучан булган. Аңа тупаслык, әдәпсезлек һәм оятсызлык ят булган. Ул беркайчан да явызлыкка явызлык белән җавап бирмәгән, ә үзенең дошманнарын кичерә белгән. Әгәр кемдер аннан берәр нәрсә сораса яки берәр нәрсә белән кызыксынса, ул һәрвакыт йомшак һәм төпле итеп җавап биргән, тупас һәм ихтирамсыз бер сүз дә сөйләмәгән. Ул беркайчан да әңгәмәдәшен ярты сүздә бүлдермәгән. Әгәр берәрсенең сүзләре мөмкин булганның чигеннән чыкса, Мөхәммәд галәйһиссәләм аларны я кире каккан, я торып киткән.

Мөхәммәд галәйһиссәләм күршеләрен хөрмәт иткән һәм кунакларын ихтирам белән кабул иткән. Аның Аллаһ өчен хезмәт итмәгән яки яхшы гамәлләр кылмаган бер генә минуты да булмаган. Ул киләчәккә өмет белән караган, ә төшенкелеккә бирелүне яратмаган. Ике эшнең берсен башларга кирәк булса, аларның файдалырагын сайлаган. Ул бәлагә төшкәннәргә ярдәм итәргә һәм изелгәннәрне коткарырга ашыккан.

Мөхәммәд галәйһиссәләм үзенең сәхабәләрен бик нык яраткан, алар турында һәрвакыт кайгыртып торган. Әгәр берәрсе авырып китсә, ул аларны күрергә бара торган булган. Берәрсе вафат булса, ул аның хакына дога кылган. Ул һәрвакыт башкаларның гафу үтенүен кабул иткән, чөнки аның өчен көчле дә, көчсез дә үзләренең хокукларында бертигез булган.

Ул бик мәрхәмәтле булган, кысан җирдә һәрвакыт башкаларга күбрәк урын калдырган. Берәрсен күрсә, һәрвакыт беренче булып сәлам биргән. Кеше белән исәнләшкәндә беркайчан да кулын беренче булып тартып алмаган.

Мөхәммәд галәйһиссәләм бик тыйнак кеше булган. Кешеләр җыелган җиргә яки җыелышка килгәч, ул урын бар җиргә утырган һәм моның белән барысының да бертигез хокуклы икәнлеген белдергән. Әңгәмәдәше белән утырганда, беркайчан да аннан алда торып басмаган. Ашыккан вакытта һәрвакыт гафу үтенгән.

Мөхәммәд галәйһиссәләм беркайчан да ярлыларга, ярлылыклары өчен, түбәнсетеп карамаган, ә байлар алдында, ялагайланып һәм куштанланып, үзенең дәрәҗәсен төшермәгән. Ул һәрвакыт иминлекне өстен куйган.

Хуш исләрне яраткан; суган, сарымсак кебек начар ис таратучы нәрсәләрне сөймәгән.

Мөхәммәд галәйһиссәләм үзенең сәхабәләреннән киеме белән дә, мәҗлесләрдә утырган урыны белән дә аерылып тормаган. Тубык сөягенә кадәр житүче озын күлмәк кияргә яраткан. Ул кием-салымда да, ризыкта да бернинди артыклыкны кабул итмәгән.

Мөхәммәд галәйһиссәләм кешеләрнең иң камиле булган. Аның хөрмәтле сәхабәләре дә башкаларга күркәм үрнәк булып торалар. Алар бөек табигатьле, саф йөрәкле, гүзәл әхлаклы камил шәхесләр булганнар.

*«Сез халыкларның иң хәерлесе булдыгыз»,* – дип, Аллаһы Тәгалә аларны дөньядагы халыкларның иң хәерлесе, иң яхшысы дип атап, башкаларны аларга иярергә чакырган.

*«Мөһаҗирләргә яхшылыкта ияручe ансарлардан һәм аларга ияргән башка мөселманнардан Аллаһ разый булды, һәм алар да Аллаһыдан разый булдылар»,* – дип, аларга ияргән кешеләрнең туры

юлда булып, Аллаһының алардан, аларның исә, Аллаһыдан разый булуларын белдерә.

Мөселманнар, Коръән һәм Сөннәт белән гамәл кылып, Аллаһ Илчесе һәм сәхабәләр юлы белән йөргән вакытларында, дөнья халыклары арасында әхлак һәм кешелек сыйфатлары буенча иң югары дәрәҗәдә булганнар. Соңрак, мөселманнарның наданлыклары һәм игътибарсызлыклары аркасында, тырышлыклары сүлпәнәюгә, рухлары төшенкелеккә, диндарлыклары зәгыйфьлеккә, тормышлары түбәнгә таба юл тотты.

## ӘБҮ БӘКЕР ӘС-СЫЙДДИКЪ

Әбү Бәкер, разыяллаһү ганһү, Мөхәммәд галәйһиссәләмнән соң булган беренче хәлифә, сәхабәләрнең, шулай ук, «тугры» исемен алган хәлифәләрнең иң мәртәбәлесе, дөньяда ук җәннәткә керү белән сөендерелгән ун кешенең берсе һәм Ислам динен беренчеләрдән булып кабул итүче заттыр.

Әбү Бәкер Корәеш кабиләсенең олуг затларыннан, гарәпләрнең нәсел-нәсәпләрен һәм тарихларын иң яхшы белүчеләрдән булып, араларында иң ышанычлы һәм иң абруйлы бер зат була. «Хәмер эчү тәртипле, кешелекле булуга зарар китерә», – дип, жаһилият вакытында ук ул хәмер эчүне үзенә хәрам иткән була.

Мөхәммәд галәйһиссәләм дингә чакыра башлагач, Әбү Бәкер, һич кичекмәстән, иманга килә, хакыйкатьне бик тиз аңлап, динне кабул итә. Ислам динен кабул иткәннән соң, ул бөтен байлыгын, бөтен көчен дин юлына сарыф итә башлый. Дөнья һәм Ахирәт бәхетенең шул юлда гына икәнен аңлап, үзенең дусларын, Корәеш халкының инсафлы,

тугры фикерле кешеләрен Исламга чакыра башлый. Бу юлда ул бик күп хезмәт итә. Никадәр зур авырлыклар күрсә дә, Ислам өчен тырышуына һичбер кимчелек китерми. Мөхәммәд галәйһиссәләмгә иң авыр вакытларда юлдаш һәм дошманнарына каршы калкан була. Рәсүлуллаһка үзеннән дә артык игътибар биреп, күбрәк аны кайгырта.

Бервакыт Мөхәммәд галәйһиссәләм: «Әбү Бәкернең яхшылыклары өчен Аллаһ аңа, һичшиксез, әҗерен бирер. Моңа кадәр әле һичкемнең малы Әбү Бәкернең малы китергән кадәр файда китермәде», – дигән. Әбү Бәкер, бу сүзләрне ишеткәч, күз яшьләре белән: «Йә, Рәсүләллаһ! Үзем дә, малым да сиңа фида булсын!» – дигән.

Мөхәммәд галәйһиссәләм вафат булгач, сәхабәләр, жыелышып киңәшләшкәннән соң, Әбү Бәкерне хәлифә итеп сайлыйлар.

Әбү Бәкер хәлифә булган заманда кайберәүләр Исламның кайбер хөкемнәрен үзләренә авыр санап: «Намаз укысак та, зәкят бирмибез», – дип, зәкят түләүдән баш тарталар. Шунда Әбү Бәкернең камил акылы, эшкә тиешле чара күрә белүе, нинди генә зур фетнә булса да, аптырап, каушап калмавы, сәясәттә оста булуы ачыклана. «Хәтта ялгыз калсам да, кулымда кылыч тотарлык хәл булганда алар белән сугышачакмын», – дип, ул шул мөртәтләргә каршы сугыш игълан итә. Унбер сәхабә җитәкчелегендә һәр тарафка гаскәр жибәреп, һәртөрле каршылык һәм фетнәләрне бастырып, Ислам дөньясын тынычландыра.

Хәлифә булганчы Әбү Бәкер сәүдә белән көн күрә. Ул зәкят һәм сәдака малларын ашауны, башкаларга йөк булып яшәүне сөймәгән. Ул хәлифә булгач та сәүдә белән шөгыльләнүен дәвам итә.

Әмма, сәүдә белән мәшгуль булганда җәмәгать хезмәтенә кимчелек килү ихтималы булганлыктан, олы сәхабәләрнең киңәше белән, аңа үзе һәм гаиләсе тора алырлык микъдарда, хезмәт хакы билгеләнә.

Ул бик рәхимле, зирәк акыллы, олы җанлы, эшне уңыш белән ахырынача җиткерүче, мәрхәмәтле, нечкә күңелле, киң холыклы, хуш мәҗлесле, түбәнчелекле, гаять тугры, урынына күрә йомшаклык, урынына күрә катылык һәм гайрәт күрсәтүче була. Сүз сөйләргә оста булып, сүзләрен бик уйлап сөйли, һәм әйткән сүзе шулкадәр дәлилле була ки, бөтен халыкны шау китерерлек мәсьәләләрне дә берничә сүз белән хәл итә торган була.

Берәр эш хакында хөкем итәргә туры килсә, ашыгып хөкем чыгармый, әүвәл тикшерә: әгәр шул вакыйга хакында Коръәндә берәр хөкем булса, шуның белән хөкем итә; аннан тапмаса, Рәсүлуллаһның Сөннәтләрен тикшерә һәм шуның белән хөкем итә; аннан да тапмаса, сәхабәләрдән: «Фәлән төрле мәсьәләне Рәсүлуллаһның ничек хөкем иткәнен белмисезме?» – дип сораша; әгәр алай да тапмаса, сәхабәләрнең олугларын һәм галимнәрен җыеп: «Ошбу вакыйгада ничек хөкем итәргә?» – дип киңәш сорап, шуннан сон гына хөкем итә торган була.

Әбү Бәкер Коръән укырга бик ихласлы була. Коръән укый башласа, анда булган хикмәтләрдән ләззәтләнеп, кыямәт хәлләреннән әсәрләнеп елыйелый укыган, һәм Коръәннең һәртөрле хөкемнәрен аңларга тырышкан.

Ул сүзендә һәм эшендә бик тугры булып, һәрвакыт тугрылыкка омтылган; бу кеше яхшы, дип,

аңа башкалардан артык игътибар бирмәгән, бу кеше яман, дип, һичкемгә золымлык кылмаган. Бәйтел малдагы казнаны бик нык саклап тоткан, анда булган акчаларның урынсыз сарыф ителүеннән, бигрәк тә үз файдасына тотылуыннан бик нык курыккан. Вафат булыр алдыннан, кызы Гайшәне чакырып: «И, кызым! Мин вафат булгач, малыбызның хисабын ал. Әгәр мин хәлифә булганнан соң безнең малыбыз арткан булса, шуны һәм бәйтел малдан алган акчага алынган әйберләрне дә миннән сон хәлифә булган кешегә тапшыр. Мөселманнарның хезмәтләре белән мәшгуль булганда файдаландык, шул җитәр», – дигән.

Аның инсафлылыгы, тыйнаклыгы шулкадәр көчле була ки, хәлифә булгач беренче хөтбәсен: «И, җәмәгать! Мин сезгә әмир булып сайландым. Шулай да, мин сезнең арада иң яхшысы түгелмен. Әгәр яхшы юл белән барсам, мина ярдәм итегез. Әгәр яман юлга керсәм, кисәтегез, төзәтегез!» – дип башлаган.

Бервакыт, бер кеше килеп: «Әссәләму галәйкүм, и Аллаһ Илчесенең хәлифәсе!» – дигәч, Әбү Бәкер: «Бу кадәр кеше арасыннан нигә бер миңа гына сәлам бирәсең?» – дип, әлеге кешене шелтәләгән.

Әбү Бәкернең иң әһәмиятле васыяте һәм мөселманнарга ясаган зур хезмәтләренең берсе – сәхабәләр арасыннан иң булдыклы, иң эшлекле булган Гомәрне танып, сәхабәләр белән киңәш иткәннән соң, аны үз урынына хәлифә итеп билгеләп калдыруыдыр.

# ГОМӘР ӘЛ-ФАРУК

Гомәр, разыяллаһү ганһү, сәхабәләрнең олугларыннан һәм җәннәт белән шатландырылган ун сәхабәнең берсе.

Җаһилият вакытында Гомәр Корәеш кабиләсенең танылган җәмәгать эшлеклеләреннән була. Мәккә халкы тарафыннан илче булып, чит илләр белән сөйләшүләр алып бару һәм сугыш игълан итү аның вазифасы була. Мөхәммәд галәйһиссәләм дингә чакыра башлагач, әһле Исламга гаять дошман булып, иманга килүчеләрне газаплый, мөселманнарга күп зарар ирештерә торган була. Ләкин Мөхәммәд галәйһиссәләм аннан өметен өзми, бәлки, шундый гайрәтле затның Исламга килеп, мөселманнар файдасына хезмәт итүен өмет итеп: «Йә, Раббым! Исламны Гомәр белән өстен һәм куәтле ит», – дип, дога кыла торган була.

Соңыннан Гомәргә Аллаһыдан һидәят ирешеп, ул Исламны кабул итә. Әһле Ислам аның мөселман булуына гаять шатлана, ул көн алар өчен зур бәйрәм була. Гомәр Исламга килгәнче, мөселманнар Мәккәнең бер читендә яшеренеп кенә гыйбадәт кыла торган булсалар, хәзер инде алар Ислам динен ачыктан-ачык тота башлыйлар.

Хак белән ялган арасын аера белүе, гаделлек һәм хаклык тарафында булганлыгы өчен, Рәсүлүллаһ Гомәрне «Фарук» дип атый. «Фарук» – хак белән батылны аеручы дигән сүз. Гомәр Исламга килгәч, үзенең гайрәте белән мөселманнарга зур таяныч һәм калкан була, аларны үз яклавы астына алып, мөшрикләрнең зарарыннан саклый. Мөселманнар Мәдинәгә һиҗрәт кылган вакытта, башка сәхабәләр мөшрикләрнең җәзаларыннан куркып,

яшеренеп киткәндә, Гомәр, коралларын тагып, Кәгъбәтуллаһ янына бара һәм ашыкмыйча гына, җиренә җиткереп, ике рәкәгать намаз укый; соңыннан, Кәгъбәтуллаһны таваф кылгач, шунда җыелган мөшрикләргә карап: «Мин хәзер һиҗрәт кылам. Әгәр кем үзенең балаларын ятим, хатынын тол калдырырга, ата-анасын елатырга теләсә, артымнан чыксын һәм фәлән чокырның артында миңа юлыксын», – дип кычкыра, һәм Мәккәдән чыгып китә. Мәдинәгә һиҗрәт кылганнан соң, ул, Мөхәммәд галәйһиссәләм белән күп сугышларда бергә булып, бик зур батырлыклар күрсәтә.

Хәлифә булганнан соң, Гомәр Ислам дошманнарының, монафыйкларның эшләрен һәрвакыт тикшереп, күзәтеп тора. Кирәк булганда, һичкемнең хәтерен сакламыйча, үз фикерен әйтә, тиешле җәзасын бирә, һәр яктан Ислам өчен гаять зур хезмәтләр башкара торган була. Үзе сәүдә белән шөгыльләнгәнгә күрә, байлыгы да күп була һәм малы белән дә бик күп ярдәм итә.

Гомәр ун ел ярым хәлифәлек итә. Бу вакытта ул үзенең бөтен барлыгын әһле Ислам файдасына корбан итә һәм мөселманнарның һәр яктан алга китүләре, күтәрелүләре өчен күп тырышлык күрсәтә. Һәр җиргә эшлекле, тугры әмирләр билгеләп, идарә эшләрен тәртипкә куя. Гомәрнең гайрәте, гаделлеге, кирәкле чаралар күрә белүе аркасында, мәмләкәтнең һәр почмагында тынычлык урнаша. Ислам дәүләте шул вакытта дөньяның иң олуг бер дәүләтенә әверелә.

Гаделлек, тигезлек, дуслык кагыйдәләре камил рәвештә үтәлеп, башка милләтләрнең дин, тел, гореф-гадәтләренә һәм башка хокукларына ирек бирелгәнлектән, патшаларының золымнарыннан

аптыраган бик күп халыклар үз ихтыярлары белән Ислам хәлифәсе җитәкчелеге астына керәләр. Мөселманнарның гадел, күркәм мөгамәләләрен күреп, яу белән алынган мәмләкәтләрдәге халыкларның күбесе Исламны үз теләкләре белән кабул итәләр.

Гомәр хәлифәлек иткән дәверендә халык өчен файдалы булган бик күп тәртипләр һәм кагыйдәләр кертә. Төрле шәһәрләргә һәм авылларга дин өйрәтер өчен мөгаллимнәр җибәреп, өйрәнгәннәрне имтихан кылу өчен махсус кешеләр җибәрә. Халык арасында гыйлем таратырга, укыйяза белүчеләрне күбәйтергә тырыша, укучы балаларга җомга көннәрендә ял итәргә әмер бирә. Мәсҗид Хәрам һәм Рәсүлүллаһның мәчете зур итеп бина кылына.

Рамазан аенда кичәләрдә җыелып, тәравих намазы укыла башлый. Ел саны һиҗри белән исәпләнә башлый. Почта йөртелә башлый. Халык санын хисаплап, байлыкларына карап, түләү билгеләнә. Ислам мәмләкәтен вилаятьләргә бүлеп, һәркайсына җаваплы әмирләр, казыйлар, бәйтел-малны карап торучылар, махсус язучылар куела; һәм, аларның эшләрен тикшереп тору өчен, махсус кешеләр билгеләнә. Суга мохтаж булган байтак урыннарга елгалар агызыла, коелар казыла. Базарлардагы үлчәүләрне, мөгамәләләрдәге тугрылыкны, чисталыкны тикшереп торыр өчен махсус кешеләр билгеләнә.

Яулап алынган җирләрдә хәмер сатыла торган урыннар ваттырыла. Беренче мәртәбә төрмә төзелә. Читтән килгән мосафирлар өчен кунакханәләр, авырулар өчен махсус хастаханәләр салына. Сәүдә яки төрле эш башларга теләүчеләр өчен, хәзинәдән бурычка процентсыз акча бирелә башлый.

Гомәрнең хәлифәлек вакытында Гарәбстанда каты ачлык була. Ачлыктан бик күп хайваннар һәлак була. Гомәр, мохтаҗларга ярдәм йөзеннән, гомуми ашлар хәзерләтә. Һәркөнне егерме дөя бугазлатып, фәкыйрьләрне ашата. Үзе ачлык беткәнче ит, май кебек нәрсәләр ашамый, сөт эчми. «Халыкка килгән авырлык миңа да килмәсә, халыкны кайгыртуым булмас», – ди ул.

Ул фәкыйрь кешеләр ашый торган ризыкларны ашап гомер итә.

Эчке серләрне гаять тиз аңлый алучы, тирән фикерле булып, күп эшләрнең кайда барып чыгачагын, кемнең нинди фикердә булганлыгын белеп, чамалап тора. Мөселманнарның төрле фиркаларга бүленүләрен сөйми. Хәзинәдә һәртөрле маллар тулып торса да, дөнья малына кызыкмый, аз нәрсә белән канәгать була, җыелган малларны әһле Ислам файдасына, фәкыйрь һәм мохтаҗларга сарыф итеп, үзе дәрвишләрчә гомер сөрә: кайвакыт хәтта өстендәге киемнәре дә ямаулы була.

Гомәрнең гайрәте, Исламга булган хезмәте, залимнарга һәм дин дошманнарына карата каты куллы булуы, тугрылык өчен бөтен дөньяны корбан итү дәрәҗәсендәге ихласы, гаделлеге һәм болардан башка бик күп яхшы сыйфатлары киләчәк буыннарга мисал һәм күркәм үрнәк булып, Ислам тарихында калдылар.

Бервакыт ул, шәһәрдән читтә йөргәндә, бер көтүчегә очрап: «Фәлән урында азык күбрәк, хайваннарыңны шунда алып барып ашатырга кирәк. Көтүче булган кеше хайваннар файдасын кайгыртырга тиеш, Кыямәттә һәр көтүчедән көтүе хакында сорау булачак», – дигән.

Гомәр мөселманнар арасында кәсеп-һөнәрнең таралуын сөйгән; эшләмичә, башка кешеләр өстендә йөк булып торуны, бигрәк тә теләнчелекне, сөймәгән, һәм мөмкин кадәр теләнчелекне бетерергә тырышкан.

Бервакыт Гомәр бер кешенең агач утыртканын күргәч: «Бик яхшы эшкә керешкәнсең! Бу сиңа динеңне саклар өчен дә, дәрәҗәңне саклар өчен дә файда итәр», – дип, бакча хезмәтенә кызыктырган.

Бер адәмнән: «Күпме малың бар?» – дип сорагач, әлеге кеше: «Ике мең биш йөз дирһәм»,– дигән. Гомәр: «Аңа гына канәгатьләнеп торма, кәсеп ит, хайваннарны да тәрбия ит», – дип, кәсеп итәргә өндәгән.

Бәдәне сәламәт, таза егетләрне күргәндә: «Ни белән кәсеп итәсең?» – дип сораштырган. Әгәр берәрсенең һөнәре, кәсебе булмавын белсә, аның каршында ул кешенең дәрәҗәсе төшкән, игътибары калмаган. Әгәр берәр төрле кәсеп белән мәшгуль булганын белсә, аның ул кешегә карата илтифаты һәм игътибары арткан.

Бер кешенең күп вакытларда мәчеттә гыйбадәт белән генә мәшгуль булганын күреп: «Намаздан тыш вакытларда мәчет почмакларында утыруга караганда, гаиләң өчен ризык кәсеп итү – синең өчен яхшырактыр», – дигән.

Гомәр, бер урында эшсез торучыларны күреп: «Болар кемнәр?» – дип сораган. «Алар Аллаһыга тәвәккәл итүчеләр», – дигәнгә каршы Гомәр: «Ялган сөйлиләр. Тәвәккәл кылучылар дип – болай эшсез торучыларга түгел, ә җирләрне сөреп, орлык чәчеп, соңыннан: "Без үзебезнең кулдан килгәнне эшләдек", – дип, нәтиҗәсен Аллаһыга тапшырып, өмет итеп торучыларга әйтелер», – дигән.

Кулына капчык тотып, хәер сoранып йөрүче бер кеше Гомәр хозурына да килеп сорангач, Гомәр аның икмәк тутырган капчыгын күреп: «Гаиләң бармы?» – дип сораган, ул: «Юк», – дигәч, Гомәр: «Алай булгач, син сoранып йөрүче түгел, ә икмәк җыеп кәсеп итәргә керешкән кеше икәнсең», – дип, капчыгын бушаттырып, икмәкләрен чын мохтаҗларга бирдергән, һәм: «Моннан соң теләнчелек итсәң, катырак җәза бирермен», – дигән.

Бервакыт Гомәр Мәдинәдә читтән килгән сатучыларны күргәч, халыкка карап, болай дигән: «И, җәмәгать! Байлыкның яртысы – сәүдәдәдер. Базарларда читтән килгән кешеләрнең хуҗа булуларыннан сакланыгыз, сәүдәне үз кулыгызда тотарга тырышыгыз!»

Гомәр диндә уртача булуны сөйгән. Динсезлеккә чын дошман булганы кебек, диндә чиктән чыгуга, артык суфилык, урынсыз тәкъвалык күрсәтүләргә дә каршы булган. Шуның өчен өстенә йөкләнгән хезмәтләрен ташлап, гыйбадәт белән генә вакыт үткәрүчеләрне шелтәли, хәтта, кайберләренә җәза да бирә торган булган. Бигрәк тә, Рәсүлүллаһ вакытында һич булмаган, яки савабы булуы аның тарафыннан бәян ителмәгән нәрсәләрдән савап эзләп йөрүчеләрне бер дә яратмаган; халыкны һәртөрле бидгатьләрдән һәм дин исеменнән берәр нәрсә боерудан тыйган.

Һәр эшендә Аллаһыны һәм Аның хозурына баруны уйлап хәрәкәт иткән.

Һидәят һәм хикмәтнең Коръәндә булуын яхшы аңлап: «Безгә Аллаһының китабы җитә», – дип әйтә торган булган; күп вакытларда Коръән укып йөргән; кичләрен Коръән укып, мәгънәсен камил

аңлап, гаять әсәрләнеп, йөрәге янып, гайрәт белән укый торган булган.

Кайвакыт, Коръәндә булган хикмәтләрдән, Кыямәт хәлләреннән әсәрләнеп, авыруга да сабышкан. Аның Коръәннән Бәкара сүрәсен ятлагач, дөя суеп, мәҗлес ясаганлыгы хәбәр ителә. Коръән өйрәнүгә гаять зур әһәмият биргән, хәтта әмирләрне эш урыннарына җибәргәндә: «Халыкка хәдисләрдән бигрәк Коръәнне өйрәтергә тырышыгыз», – дип боера торган була.

Гыйбадәткә бирелеп китү – җәмгыять хезмәтенә зарар китерә дип, ул көндез фарыз гыйбадәтләрне генә үтәп, нәфел гыйбадәтләрне кичләрен үтәгән.

Бервакыт, мәчеттә иртә намазын җәмәгать белән укыганнан сон: «Фәлән кеше кайда? Мәчеттә күренмәде?» – дип сораган. «Ул кичәләрне гыйбадәт белән үткәрә, шуның өчен иртә намазыннан йоклап калган булса кирәк», – дип әйткәч, Гомәр: «Әгәр ул төн буенча йоклап, иртә намазына торып, җәмәгать белән укыса, саваплырак һәм артыграк булыр иде», – дигән.

Гомәр суфилар шикелле күренергә тырышып йөрүчеләрне бер дә сөймәгән. Башын бөгеп утырган бер егетне күреп: «И, кардәш! Башыңны күтәр! Суфилык – башта түгел, бәлки, калебтәдер. Сез – динне тергезүчеләр түгел, ә, киресенчә, динне үтерүчеләр», – дигән.

Гайшә анабыз, бер кешенең зәгыйфь кешеләр кебек бөгелеп, акрын гына йөргәнен, акрын гына сөйләшкәнен күреп: «Гомәр дә чын заһид иде, ләкин ул болай йөрми иде, әгәр сөйләсә – сүзен ишеттереп сөйли, йөрсә – ашыгып йөри, җәза бирсә – авырттырырлык итеп бирә иде», – дигән.

Бервакыт, Гомәр тәһарәтсез килеш яттан Коръән укый башлагач, бер кеше: «Тәһарәтсез Коръән укыйсыңмыни?» – дип сораган. Гомәр, аңа каршы, ачуланган тавыш белән: «Тәһарәтсез Коръән укырга дөрес түгел, дип сиңа ялганчы Мөсәйләмә фәтва бирдеме әллә?» – дигән.

## ГОСМАН ЗИННУРАЙН

Госман разыяллаһү ганһү сәхабәләрнең олугларыннан, җәннәт белән шатландырылган ун кешенең һәм Ислам динен иң элек кабул итүчеләрнең берседер.

Госман, хәлифә булганнан соң, тирә-яктагы әмирләргә халыкка карата гадел һәм тугры булырга боерыклар җибәреп, аларга яхшы мөгамәлә күрсәтергә, һәртөрле халык арасында тигезлекне сакларга, ятимнәрне һәм башка диндә булган кешеләрне яклау астына алырга боера.

Ул Ислам мәмләкәте белән Гомәр вакытында булган тәртип белән идарә итә башлый.

Госман үзе дә зур байлардан, оста сәүдәгәрләрдән булганлыгы өчен, аның заманында сәүдә, байлык, тормыш дәрәҗәсе бик нык үсә. Халык арасында төрле кәсеп һәм һөнәр ияләре, сәнгать һәм игенчелеккә әһәмият бирүчеләр арта. Мөселманнар арасына Фарсы һәм Рум илләрендә булган бик күп файдалы сәнгать һәм һөнәрләр тарала. Мөселманнар арасында зур байлар, яхшы тормышка әһәмият бирүчеләр, гомумән, әһле Ислам һәм фәкыйрьләр файдасына зур ярдәм күрсәтүчеләр күбәя.

Мәдинәдә Рәсүлуллаһның мәчетен зур итеп, бизәкләп төзетә. Мәчетне беренче мәртәбә зин-

нәтләп төзүче дә Госман була. Җомга намазына беренче азан әйтүне дә ул кертә; аңа кадәр азан мөнбәр алдында гына әйтелә торган була.

Госманның олы хезмәтләреннән берсе – Коръәнне нөсхәләргә күчереп яздырып, тирә-яктагы зур шәһәрләргә, мәмләкәтләргә таратуыдыр.

Ул гаять дәрәҗәдә инсафлы, юаш, миһербанлы, олы йөрәкле, киң күңелле, гүзәл холыклы булган; янына килгән кешеләрне үзеннән разый итеп җибәрергә тырышкан; аның җаһилият вакытыннан ук Корәеш һәм башка гарәп кабиләләре арасында хөрмәте зур була.

Һәркемгә ригаялы, гадел мөгамәләле, башкаларга золым, хыянәт итүдән, өстендә кеше хакы калудан бик курыккан, хәтта, үзенең гаиләсе һәм хезмәтчеләренең дә хәтерләрен калдыруны сөймәгән. Якын һәм ерак кардәшләренең һәммәсен үзеннән разый итәргә тырышкан. Аллаһ исеме белән ант итүдән бик нык сакланган.

## ГАЛИ КӘРРАМӘЛЛАҺҮ ВӘҖҺӘҺҮ

Гали разыяллаһү ганһү – сәхабәләрнең бөекләреннән, җәннәт белән шатландырылган ун кешенең берсе, тугры хәлифәләрнең дүртенчесе һәм Рәсүлүллаһның кече кызы Фатыйманың ире була.

Гали гаять дәрәҗәдә куәтле, баһадир, арыслан йөрәкле була, сугыш һәм көрәшләрдә аңа һичкем чыдамаган, һәммәсе аның алдына килүдән, хәтта исеменнән дә куркып торганнар. Галинең батырлыгы, сугышларда күрсәткән гайрәте – халык арасында мисал һәм үрнәк булып калган. Гали һичнәрсәдән курыкмаганга һәм шикләнмәгәнгә, Рәсүлүллаһ аңа гарәпләрдә булган сыннарны ватып

йөрергә, гыйбадәт кылу урынына әйләнгән кабер-ләрне җир белән тигезләргә боерган.

Гали – сәхабәләрнең иң галим һәм туры фикерлеләреннән, юмарт, миһербанлы, киң күңелле, гүзәл холыклы, ачык йөзле, хуш мәҗлесле, вәгазь сөйләргә оста, бик үткен, тиз җаваплы, кыскасы, ул бик аз кешеләрдә генә табыла торган яхшы сыйфатларның күбесен үзенә җыйган була. Коръәнне аңлауда, тәфсир һәм дин гыйлемен белүдә беренче затлардан саналып, атаклы сәхабәләр дә авыр мәсьәләләрдә аңа мөрәҗәгать иткәннәр. Гарәп телен һәм аның кагыйдәләрен белүе дә бик яхшы булып, гарәп теленә беренче мәртәбә нәхү кагыйдәләрен төзүче дә Гали була.

Гали гаять динле, гыйбадәткә һәм Коръән укырга ихласлы булган. Көндезләрен дәүләт эшләре белән үткәрсә, төннәрен елый-елый гыйбадәт белән үткәргән. Ул намаз укуны бик зур эшкә санаган: намаз укый башласа, Аллаһының бөеклеге хәтеренә килеп, төсләре үзгәрә, бөтен тәне калтырый башлый торган була.

Гали гаять саф йөрәкле булган, кенә, хөсет кебек сыйфатлар анда һич булмаган; гаделлек һәм хаклыктан аерылмаган; шомлану, вәсвәсәләнүләргә иярмәгән; үзе өчен үч алмаган; дусларына гына түгел, хәтта кирәк булганда, үзенең дошманнарына да ярдәм иткән. Бер сугышта Галинең гаскәре суга мохтаҗ булып, су буенда урнашкан Шам гаскәреннән су сорагач, алар бер тамчы да су бирмиләр. Соңыннан, Гали гаскәре суга хуҗа булгач: «Аллаһы Тәгалә хайваннарын, төрле җан ияләрен судан тыймаган вакытта, без ничек инде кешеләргә су бирмик?! Һичкемне судан тыймагыз», – дип, дошман гаскәренә дә су алырга мөмкинлек биргән.

Гали үзенең кул астында булган бөтен кешегә дә тигез караган; тугры хөкемнәрне, үзенең зарарына булса да, авырсынмыйча кабул иткән.

## ХӘДИЧӘ АНАБЫЗ

Хәдичә, разыяллаһү ганһә, – Мөхәммәд галәйһиссәләмнең иң беренче хатыны һәм аңа иң элек иман китерүчеләрнең берсе.

Хәдичә хатыннар арасында нәселе, акылы, әдәбе, матурлыгы белән мәшһүр булып, «таһира» (чиста, пакь) дигән кушамат белән дә йөртелгән.

Байлыгы һәм сәүдә эшләре белән дә башкалардан өстен булып, ире Әбү Йәгълә вафат булганнан соң, Шам һәм Йәмән тарафларына кәрван йөртеп, сәүдә эшләрен алып барган һәм исәп-хисапларын да үзе күзәтеп, тикшереп торган.

Бервакыт, Мөхәммәд галәйһиссәләмнең күркәм холыклы, тугры сүзле, ышанычлы икәнлеген ишеткәч, аннан үзенең малы белән Шамга барып сәүдә итүне үтенгән. Мөхәммәд галәйһиссәләм бу тәкъдимне кабул итеп, Хәдичәнең Мәйсәрә исемле колы белән, Шам тарафына барып, уңышлы сәүдә итеп кайткан.

Хәдичә Мөхәммәд галәйһиссәләмнең акылын, холкын яратып, берникадәр вакыттан соң, әгәр кабул итсә, аңа хатын булырга теләгәнен хәбәр итә. Мөхәммәд галәйһиссәләм үзенең кардәшләре белән киңәш иткәч, тәкъдимне кабул итә. Ул вакытта Рәсүлүллаһка егерме биш, Хәдичә анабызга кырык яшь була.

Хәдичә акыллы, изге бер хатын булып, Рәсүлүллаһ белән никахлашканнан соң бөек бер тормыш башлануын сизә; аның һәрбер хәрәкәтеннән

зур бәхет өмет итеп, аңа хезмәт итүдән җаны рәхәтләнеп, рухани бер ләззәт ала башлый. Шуның өчен ул үзенең бөтен эшләрен һәм мал-мөлкәтен Мөхәммәд галәйһиссәләмнең ихтыярына тапшыра. Аның бөтен максаты – Рәсүлүллаһның ризалыгын табып, күңелен шатландырырга тырышу була.

Мөхәммәд галәйһиссәләм, пәйгамбәр булудан элек, Хира тавына барып, гыйбадәт белән мәшгуль булганда, Хәдичә анабыз да балаларын җитәкләп барып, Рәсүлүллаһ янында була, кайвакытларда аның белән бергә үзе дә гыйбадәт кыла.

Мөхәммәд галәйһиссәләмгә Җәбраил фәрештә аркылы беренче мәртәбә вәхи килеп, тетрәп, куркып, Хәдичә янына кайткач: «И, кардәшем! Һич курыкма! Аллаһ сиңа зарар китермәс, чөнки син мосафирларга хөрмәт, ятимнәргә, гарипләргә, мохтаҗларга, бәла-казага очраганнарга ярдәм итәсең, гел дөресен генә сөйлисең», – дип, аны юата.

Мөхәммәд галәйһиссәләм Мәккә кәферләреннән һәртөрле мыскыл, җәфалар күреп, ачы сүзләр ишетеп, күңеле төшеп, хәсрәтләнеп кайтканда, Хәдичә аны каршы алып, хәлләрен сорашып, күңелен юата торган сүзләр сөйләп, кайгысын бетерә, аңа гайрәт бирә, күңелен күтәрергә тырыша. Малы, җаны белән ярдәм итеп, иң авыр, хәсрәтле вакытларында юатып, гайрәт биреп торучы бу хатыннан Рәсүлүллаһ та бик риза һәм канәгать була. Анын хакында ул: «Хатыннарның хәерлесе – Хәдичәдер», – дигән, һәм аңа җәннәтле булуы белән сөенечле хәбәр биргән. Бервакыт аңа Җәбраил аша Аллаһ тарафыннан җибәрелгән сәламне дә тапшырган.

Хәдичә анабыз Мөхәммәд галәйһиссәләм белән бергә егерме биш ел яши. Һиҗрәттән өч ел

элек, алтмыш биш яшендә Мәккәдә вафат булып, Рәсүлүллаһ тарафыннан җирләнә. Мөхәммәд галәйһиссәләм Хәдичәнең вафатыннан бик нык хәсрәтләнә. Шул елны агасы Әбү Талиб та вафат булганга, ул ел – «кайгы елы» дип атала. Вафатыннан соң, Мөхәммәд галәйһиссәләм Хәдичәне һәрвакыт искә төшереп, сагынып сөйли; берәр хайван бугазласа, ит кисәкләрен Хәдичәнең дусларына җибәрә; үзләре аның янына килсәләр, аларга махсус хөрмәт күрсәтә торган була. Бервакыт, бер карчыкны хөрмәт итеп, хәлен сорашып озатканнан соң, Гайшә анабызга: «Ул хатын безгә Хәдичә исән вакытта килә иде. Дусларны хөрмәт кылу– иман галәмәтедер», – дигән.

Бервакыт, Мөхәммәд галәйһиссәләм Хәдичәне искә төшереп мактаганда, Гайшә анабыз: «Хәдичә тешләре коелып беткән бер карчык иде, аннан соң Аллаһ сиңа аннан хәерлесен бирде бит», – дигәч, Мөхәммәд галәйһиссәләм: «Юк, аннан хәерлесен бирмәде. Чөнки бөтен халык мине ялганчы дигәндә, ул минем пәйгамбәрлегемне раслады, иман китерде; бөтен халык мине мыскыл иткәндә, ул миңа ярдәмче һәм яклаучы булды, минем хакка бөтен малын Аллаһ юлына сарыф итте. Һәм миңа Аллаһ аннан балалар насыйп итте», – дигән.

## ФАТЫЙМА РАЗЫЯЛЛАҺҮ ГАНҺӘ

Фатыйма – Мөхәммәд галәйһиссәләмнең иң кече һәм иң сөекле кызы булып, анасы – Хәдичәдер.

Мөхәммәд галәйһиссәләмгә утыз биш яшь булганда дөньяга килеп, төсе ак һәм нурлы булганы өчен «зәһра» дип тә йөртелгән.

Фатыйма Мәдинәгә һиҗрәт кылганнан соң, икенче елны Галигә кияүгә чыга. Ул килен булып төшкәндә Галинең анасы Фатыйма бинте Әсәд бин Һашим да исән була. Фатыйма килен булып берникадәр торгач, йортларындагы хезмәт күплегеннән аның куллары кабара, күтәреп су ташуыннан иңбашлары авырта башлаган. Бервакыт, ул шуларны уйлап, бер хезмәтче бирмәсме дип, Мөхәммәд галәйһиссәләм янына барган, ләкин, Рәсүлуллаһны өйдә очрата алмаганлыктан, йомышын Гайшә анабызга әйтеп, кайтып киткән. Мөхәммәд галәйһиссәләм үзе кич белән өйләренә барып, рөхсәт сорап кергәч, кияү белән кызының араларына утырып, йомышларын сораганнан соң, эш эшләп гыйбадәт кылуның, эшсез гыйбадәт кылуга караганда артыграк булуын аңлаткан. Соңыннан, «И, Фатыйма! Аллаһыдан куркып эш ит! Фарызларыңны вакытында үтә, йорт эшләреңне эшлә, авырлыкларга сабыр ит, хатыннарның хәерлесе – җәмәгатьләренә күбрәк файда китергәнедер», – дигән.

Бервакыт Мөхәммәд галәйһиссәләм Фатыйма хакында: «Фатыйма җәннәт хатыннарының сәидәседер», – дигән.

Фатыйма йөреш-торыш һәм мөгамәләдә Мөхәммәд галәйһиссәләмгә бик охшаган була. Гаять гүзәл холыклы, яхшы мөгамәләле, фәкыйрьләргә, мескеннәргә мәрхәмәтле, һичбер вакыт олугланып тормый, үз янына килүчеләрне үзеннән риза итеп җибәрергә тырыша һәм гаять тугры сүзле була. Гайшә анабыз: «Фатыймадан да тугры кешене күргәнем юк», – дигән. Акылы, динлелеге, тәкъвалыгы куәтле, гыйбадәткә ихласлы булып, гомерендә бер мәртәбә дә намазны калдырмаганлыгы турында сөйләнә. Чыгымны күп чыгармый, кием-са-

лымда, бизәнүдә чама беләгә, дөнья малына исе китми, канәгатьле, пакьлеккә бик ригаяле, йорт эшләрен үзе эшли, балаларын үзе тәрбияли, киемнәрен үзе тегә торган була.

Фатыйма саф күңелле, сүзгә оста һәм вәгазьләре бик әсәрле булганга күрә, Мәдинә хатыннары һәрвакыт аның янына җыелып, вәгазьләреннән файдалана һәм белмәгән мәсьәләләрен сорый торган булалар. Аның әсәрле вәгазьләре белән Мәдинә хатыннарының дингә мәхәббәтләре артып, дөрес әхлаклы, динле, тәрбияле, Ислам файдасына тырышучы, балалар тәрбиясенә нык әһәмият бирүче бик күп кызлар һәм хатыннар җитешкән.

Рәсүлүлланың аңа мәхәббәте камил булып, һәрвакыт аның турында кайгырта; сәфәргә чыкканда, иң соңыннан аның белән саубуллаша, сәфәрдән кайтканда, иң элек аның белән күрешә, аны зиярат кыла торган була.

Мөхәммәд галәйһиссәләм Фатыйманы никадәр нык сөйсә дә, бервакыт: *«И, Фатыйма! Әгәр мал кирәк булса, минем малымнан теләгәнеңчә сора. Ләкин Кыямәт көнендә сиңа пәйгамбәр кызы булуың гына файда бирмәс, үзең өчен үзең тырыш»*, – дигән.

## ГАЙШӘ АНАБЫЗ

Әбү Бәкернең кызы – Гайшә анабыз – Рәсүлүлланка пәйгамбәрлек килгәннең бишенче елында дөньяга килә. Хәдичәнең вафатыннан соң өч ел үткәч, Рәсүлүлланка никахлана. Гайшә анабыз, Рәсүлүлланка никахлы булу сәбәпле, гаять күп гыйлем ала. Мөселман хатыннары арасында иң зур галим булып, дингә бик күп хезмәт куя. Хәдис китапла-

рында исеме иң күп искә алынган хатын да Гайшә анабыздыр.

Гайшә анабыз бик матур, акыллы, эшлекле, гүзәл холыклы булганлыктан, Рәсүлүллаһның аңа мәхәббәте бик көчле була. Хәтта, вафат булганда да, үзенең мөбарәк башын Гайшә анабызның итәгенә куйган хәлдә җан биргән.

Рәсүлүллаһның шәхси тормышы, хатыннар хакындагы хәдисләрнең күбесе Гайшә анабыз тарафыннан риваять ителгән. Кайбер галимнәр: «Шәригать хөкемнәренең дүрттән бере Гайшә анабыз аркылы риваять ителде», – диләр.

Гайшә анабыз Коръән укырга бик ихласлы булып, үзенә махсус Коръән яздырып, күбрәк шул Коръәннән укыган һәм Рәсүлүллаһтан соң бөтен Коръәнне ятлаган.

# ЭЧТӘЛЕК


**ТӘРБИЯЛЕ БАЛА** ........ 3
*АТА – АНА* ........ 10
*ТУГАННАР* ........ 14
*КАРДӘШЛӘР* ........ 15
*КҮРШЕЛӘР* ........ 16
*ӨЙ ЭЧЕНДӘ* ........ 16
*МӘКТӘП ӘДӘПЛӘРЕ* ........ 18
*ГЫЙЛЕМ* ........ 21
*КИТАП УКУ* ........ 24
*УКЫТУЧЫ* ........ 24
*УКУЧЫ БАЛАЛАР* ........ 25
*ДУСЛЫК ӘДӘПЛӘРЕ* ........ 26
*ЙӨЗ ӘДӘПЛӘРЕ* ........ 28
*КҮЗ ӘДӘПЛӘРЕ* ........ 29
*БОРЫН ӘДӘПЛӘРЕ* ........ 29
*КОЛАК ӘДӘПЛӘРЕ* ........ 30
*КУЛ ӘДӘПЛӘРЕ* ........ 31
*БАШ ӘДӘПЛӘРЕ* ........ 31
*УТЫРУ ӘДӘПЛӘРЕ* ........ 32
*ЙОКЫ ӘДӘПЛӘРЕ* ........ 32
*ЙӨРҮ ӘДӘПЛӘРЕ* ........ 34
*СӘФӘР ӘДӘПЛӘРЕ* ........ 35
*АШАУ-ЭЧҮ ӘДӘПЛӘРЕ* ........ 36
*МӘҖЛЕС ӘДӘПЛӘРЕ* ........ 38
*КУНАК ӘДӘПЛӘРЕ* ........ 40
*АВЫРУНЫҢ ХӘЛЕН БЕЛҮ* ........ 42
*КАЙГЫ УРТАКЛАШУ* ........ 43
*КИЕМ ӘДӘПЛӘРЕ* ........ 43
*ЗИННӘТ ӘДӘПЛӘРЕ* ........ 45
*СӨЙЛӘШҮ ӘДӘПЛӘРЕ* ........ 45
*ХӘРӘКӘТЛӘНҮ ӘДӘПЛӘРЕ* ........ 48

**ДИН ӘДӘПЛӘРЕ** ........ 49
*ИМАН НИГЕЗЛӘРЕ* ........ 53
*ИМАН КӘЛИМӘЛӘРЕ* ........ 54
*ИСЛАМ НИГЕЗЛӘРЕ* ........ 55
*ШӘҺАДӘТ КӘЛИМӘЛӘРЕ* ........ 56
*НАМАЗ* ........ 57
*ЗӘКЯТ* ........ 58
*УРАЗА* ........ 59
*ХАҖ* ........ 60
*НИЯТ* ........ 60
*ДӘГЪВАТ* ........ 61
*КОРЪӘН* ........ 63

**ГЫЙБАДӘТ КИТАБЫ**
*ТӘҺАРӘТ АЛУ ТӘРТИБЕ* ..... 65
*ТӘҺАРӘТНЕ БОЗА ТОРГАН НӘРСӘЛӘР* ..... 65
*ГОСЕЛ* ..... 66
*ГОСЕЛ АЛУ ТӘРТИБЕ* ..... 66
*НАМАЗ УКУ* ..... 67
*АЗАН* ..... 67
*КАМӘТ* ..... 68
*НАМАЗ УКУ ШАРТЛАРЫ* ..... 68
*НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ* ..... 69
*НАМАЗЛАРДАГЫ РӘКӘГАТЬ САННАРЫ* ..... 69
*КАЙБЕР КАГЫЙДӘЛӘР* ..... 70
*СӘҺҮ СӘҖДӘСЕ* ..... 71
*ИРТӘНГЕ НАМАЗ* ..... 72
*ЗИКЕР-ТӘСБИХЛӘР* ..... 75
*ӨЙЛӘ НАМАЗЫ* ..... 76
*ИКЕНДЕ НАМАЗЫ* ..... 79
*АХШАМ НАМАЗЫ* ..... 80
*ЯСТҮ НАМАЗЫ* ..... 81
*ВИТР-ВӘҖЕП НАМАЗЫ* ..... 83
*ҖОМГА НАМАЗЫ* ..... 84
*ГАЕТ НАМАЗЛАРЫ* ..... 86

**РАМАЗАН ҺӘМ КОРБАН БӘЙРӘМНӘРЕ** ..... 87
*КОРБАН ЧАЛУЛАР* ..... 88
*ҖОМГА КӨН* ..... 89
*ИЗГЕ АЙЛАР* ..... 90
*КАДЕР КИЧЕ* ..... 90
*БАЛАЛАРГА ИСЕМ КУШУ* ..... 92

**КҮРКӘМ ХОЛЫКЛАР** ..... 94
*ДӨРЕСЛЕК* ..... 96
*ТУГРЫЛЫК* ..... 97
*ТЫРЫШЛЫК* ..... 99
*МӘРХӘМӘТЛЕЛЕК* ..... 101
*ОЯТ-ХӘЯ* ..... 102
*САБЫРЛЫК* ..... 103
*ШӨКЕР ИТҮ* ..... 106
*ОЛЫЛАРНЫ ХӨРМӘТ ИТҮ,*
*САБЫЙЛАРНЫ СӨЮ* ..... 109
*ХАКЛАР* ..... 111
*ГАДЕЛЛЕК* ..... 112
*ӘМАНӘТ* ..... 114
*ВӘГЪДӘДӘ ТОРУ* ..... 116
*ЮМАРТЛЫК* ..... 117
*ҺӘР ИГЕЛЕК СӘДАКА* ..... 118
*ИГЕЛЕККӘ КАРШЫ ҖАВАП БИРҮ* ..... 120
*БУРЫЧ ХӘЛЕ* ..... 121
*КЕШЕ КАЙГЫСЫНА СӨЕНМӘҮ* ..... 121
*КАНӘГАТЬЛЕЛЕК* ..... 122
*СӘЛАМЛӘШҮ* ..... 123
*РӨХСӘТ СОРАУ* ..... 125

**НАЧАР ХӘЛЛӘР — ЯМАН ХОЛЫКЛАР**
*ГӨНАҺ* ........ 126
*ЯЛГАН ВӘ ХӘЙЛӘ* ........ 127
*ГАЙБӘТ СӨЙЛӘҮ* ........ 128
*УРЛАУ* ........ 131
*КЕШЕ ҮТЕРҮ* ........ 132
*АРАКЫ ЭЧҮ* ........ 133
*ОТЫШ УЕННАРЫ УЙНАУ* ........ 134
*ЗИНА КЫЛУ* ........ 136
*ЯЛА ЯГУ* ........ 139
*ТӘКӘББЕРЛЕК* ........ 140
*КӨНЧЕЛЕК* ........ 141
*ИКЕЙӨЗЛЕЛЕК* ........ 144
*ИСРАФ* ........ 145
*ҮЗЕҢ ЯХШЫЛЫК КЫЛГАН КЕШЕНЕ БИТӘРЛӘҮ* ........ 148
*ТӘҮБӘ* ........ 148

**КҮРКӘМ ҮРНӘКЛӘР** ........ 151
*МӨХӘММӘД ГАЛӘЙҺИССӘЛӘМ* ........ 151
*ӘБҮ БӘКЕР ӘС-СЫЙДДИКЪ* ........ 154
*ГОМӘР ӘЛ-ФАРУК* ........ 158
*ГОСМАН ЗИННУРАЙН* ........ 165
*ГАЛИ КӘРРАМӘЛЛАҺҮ ВӘҖҺӘҺҮ* ........ 166
*ХӘДИЧӘ АНАБЫЗ* ........ 168
*ФАТЫЙМА РАЗЫЯЛЛАҺҮ ГАНҺӘ* ........ 170
*ГАЙШӘ АНАБЫЗ* ........ 172

**БАЛАЛАРГА ҮГЕТ-НӘСЫЙХӘТ**

Нәшриятка 0258 нче номерлы лицензия
1999 елның 19 апрелендә бирелде.

Форматы $60\times90^1/_{16}$. Офсет басма. Шартлы басма табагы 11,0.
Заказ Б-82.

ДУП "Полиграфия-нәшрият комбинаты".
420503, Казан шәһәре, Бауман ур., 19.